1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2020 МАЙ № 5

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

КИЛЕН
кыз булмый
кайнанага ничек
ярарга

тозак
ИР-АТКА
бездән ни кирәк

җир артындагы
җир
мин ачкан
ДӨНЬЯ

Мөршидә БӘДЫЙГОВА: «Рейхстаг диварына мин дә исемемне язып калдырдым!»

75 ПОБЕДА! 1945–2020

Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Әтиебез Галиев Хәсән Газимҗан улы Кызыл Армия сафларына 1942 елның маенда алына. Шул ук елның 20 июнендә яшь солдат 313 нче артиллерия полкында хәрби ант кабул итә. Сугыш турында сөйләргә яратмый иде ул. Без аның Суслонгерда булуын, аннан качып, кабат үзе теләп фронтка киткәнен сирәк истәлекләрдән, кызылармеец кенәгәсендәге язулардан һәм архив белешмәләре аша ачыкладык. Беренче сугышчан чыныгуны ул Белоруссия фронтында ала. Бу хакта Бүләкләү битендәге юллар сөйли. Әлеге документта язылганнар буенча, 86 нчы авыр гаубица артиллерия бригадасының 1 нче дивизион бүлеге лаборанты – кызылармеец Галиев Хәсән Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим ителә. 1944 елның апрелендә Белоруссияне азат итү өчен һөҗүм башлана. «Багратион» операциясе Икенче Бөтендөнья сугышы тарихында иң уңышлы гамәл буларак бәяләнә. 1944 елның 31 июнендә Белоруссия фронты Варшаваны азат итү өчен көрәшкә күтәрелә. Әтинең дә хәрби бүләкләре арасында «Варшаваны азат иткән өчен» медале саклана.

Ә Бүләкләү битен аның вафатыннан соң 18 ел узгач, Оборона министрлыгының үзәк архивыннан табып алдык. 1 нче дивизия командиры капитан Смирнов кул куйган документта әтинең күрсәткән батырлыклары тасвирлана: «...Особенно отличился в боях за город Берлин с 28.04.1945г. по 02.05.1945 года. Батарея была выдвинута на прямую наводку и подвергалась сильному воздействию пулеметного огня... На батареи иссякали снаряды... Тов. Галиев вдвоем с шофером рискуя жизнью, под обстрелом, подвезли снаряды и сгрузили их... Удостоен правительственной награды – ордена Красной Звезды 19 мая 1945 года».

Әнзия ӘХМӘДИЕВА.
Чаллы шәһәре.

Наградной лист 104

1 Фамилия Имя Отчество Галиев Хасан
2 Звание красноармеец 3. Должность часть лаборантист 1 дивизиона 86 Тяжелой Гаубичной Артиллерийской Краснознаменной бригады
Представляется к правительственной награде орден „Красная звезда"
4 Год рождения 1923 5 Национальность татарин 6. Партийность беспартийный
7 Участие в гражданской войне и последующих боевых действиях по защите СССР в отечественной войне (где когда)
В Отечественной войне с 15 мая 1943г. 1 Белорусский фронт
8 Имеет ли ранения, контузии в отечественной войне не имеет
9 С какого времени в Красной Армии 1.06.42г.
10 Каким РВК призван Алексеевский РВК Татарской АССР
11 Чем ранее награжден не награжден
12 Постоянный домашний адрес представляемого к награждению или адрес его семьи
[redacted]

В боях за нашу родину проявляет образцы мужества и отвагу. Особенно отличился в боях за город Берлин с 28.04.1945г. по 2.05.1945 года. Батарея была выдвинута на прямую наводку и подвергалась сильному воздействию пулеметного огня и фаустов противника. На батареи иссякали снаряды и требовалось быстро подвезти их на огневую позицию. Тов. Галиев вдвоем с шофером рискуя жизнью под обстрелом подвезли снаряды и сгрузили их. Батарея продолжала вести огонь, огнем которой в этот день было уничтожено 3 пулемета в зданиях, и гнезда фаустников, последнее способствовало успешному продвижению подразделений 171 Стрелковой дивизии.

Достоен правительственной награды орден „Красная звезда"

Командир 1 дивизиона
капитан Смирнов
19 мая 1945 г.

ЦАМО фонд 33 опись 687572 единица хранения 258

Наградной лист Хасана Газимзяновича

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Мөршидә Бәдыйгова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 23.04.2020 ел.
Заказ А-881
Тираж 5455

16+

PRESSA

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ «ҮЛЕМСЕЗ ПОЛК»Ы





1. Анна АРАХАМИЯ: «Штыцко Егор Никитович (1905–1943) – әбиемнең әтисе. Сугышның иң беренче көннәрендә үк үзе теләп фронтка китә. Сталинград янында барган сугышларда катнаша. Яраланып, госпитальгә эләгә. Ә бер көнне ул яткан госпитальне бомбага тоталар... Бабабыз «хәбәрсез югалган» дип санала. Гаиләсенә аның ордены һәм медальләре генә кайтып җитә...»

2. Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА: «Бабакаем Галиәхмәтов Фәтхелбаян Галиәхмәт улы (1903–1980) Калинин районы (Актаныш районы) Иске Кадермәт авылында туган. Сугышка аны 1944 елда алалар. Икенче Балтыйк буе фронтының танкистлар бригадасы кызылармеецы. Латвиянең Мадонский өязендә сугышканда әсирлеккә эләгә. Туган җиренә 1946 елда гына кайта ала».

3. Резеда ГАЛИУЛЛИНА: «Әтием Галиуллин Зәки Гали улын (1926–1978) сугышка 1942 елның 6 июнендә алалар. Норлат районы (Яшел Үзән) Зур Ширдан авылыннан чыгып китә ул. Кара диңгез флотында механик булып хезмәт итә. Новороссийск, Севастополь шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Туган ягына 1950 елның октябрендә генә әйләнеп кайта».

4. Сөмбел ГАФФАРОВА: «Әтиемнең әтисе Гаффаров Габдрахман Гаффар улы (1907–1962) сугышка Балык Бистәсенең Олы Әшнәк авылыннан чыгып китә. Калинин фронтына эләгә. Мәскәү янындагы сугышта мина кыйпылчыгы тиеп, кулбашы чәрдәкләнә. Алты ай госпитальдә ятканнан соң өенә кайта. «Германияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнә. Кайткач, «Кызыл юл» колхозында хуҗалык мөдире, ревизия комиссиясе рәисе булып эшли».

5. Лилия ГӘРӘЕВА: «Әниемнең әтисе Вәлиев Бакый Гатаулла улы (1918–1978) сугышка 1942 елны алына. Мәскәү өчен аяусыз көрәш барган көннәр бу. Бабам фронтта авыр яралана. Култык таякларына калган солдатны тылга озаталар. Яралары җөйләнүгә, ул кабат тракторына утыра һәм соңгы көненәчә Арча районы Кышкар авылының алдынгы тракторчысы була».

6. Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА: «Мөбарәков Салихҗан Мөбарәкҗан улы (1916–2019) – әтиемнең дәү әтисе. Сугыш аның өчен 1942 елда хәрби училищеда укудан башлана. Аннары – Беренче Белоруссия фронты. Минск шәһәре өчен сугышта контузия алган. Медальләр һәм орденнар белән бүләкләнгән».

7. Эльмира ЗАКИРОВА: «Әтиемнең бертуган абыйсы Мәҗитов Миргазиян Габит улы 1919 елда Татарстанның Калинин районы (Мөслим) Әмәкәй авылында туган. 46 нчы укчы дивизиянең 314 нче укчы полкында өлкән лейтенант булган. 1945 елның 23 февралендә Ленинград өлкәсе Колпинск районы Торфяник бистәсе туганнар каберлегендә җирләнгән».

8. «Әтиемнең бертуган апасы Җәмилә апабызның ире, җизнәбез – Бөек Ватан сугышының башында ук беренчеләрдән булып Советлар Союзы Герое исемен алган Илдар Маннан улы Маннанов (1921–2010) Мөслим районы Бүләк авылы егете. Ленинград өлкәсе Тихвин шәһәре янында күрсәткән батырлыклары өчен СССР Верховный Советы Президиумының Указы белән аңа Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла. Тихвин, Чаллы шәһәрләре, Мөслим районының почетлы гражданины».

9. Фирдәвес ИСМӘГЫЙЛЕВА: «Әнием ягыннан бабам Ибраһимов Хәсән Хәйрулла улы (1906–1943) чыгышы белән Кама Тамагы районы Сатлыган авылыннан. Сугыш башланыр алдыннан гына авылдан берничә гаилә Сталинград якларына чыгып киткән була. Бабам сугышның беренче көннәреннән үк шуннан алына. Ленинград блокадасын өзү өчен унтугыз көн барган бәрелешләрнең берсендә – 1943 елның 23 гыйнварында, яраланып, чолганышта кала. Немецлар аягында булганнарны әсирлеккә ала, ә яралыларны штык белән кадап


6


7



13


14

китә... Ленинград өлкәсенең Киров районы Синявино-1 бистәсендә туганнар каберлегендә җирләнгән. Мин бабайдан күпкә олы инде...»

10. Рәмзия КАШАПОВА: «Әниемнең әтисе Мөбарәкҗанов Госман Мөбарәкҗан улы (1901–2001) белән әбием 1939 елны Сахалинга күчеп китәләр. Сугыш башланыр алдыннан бабамны шуннан хәрби сборга алалар. Красноярскида аны су асты разведкасына әзерлиләр. Сугышка ул беренче көннән үк барып керә. 1943 елда икенче тапкыр каты яралана һәм аны туган ягына озаталар. Гомер буе Сабада, колхозда эшләде».

11. Лариса МАЛИКОВА: «Әхмәтов Закирҗан Әхмәт улы (1907–1980) – әнкәемнең әтисе. Сугышка 1942 елда китә. Беренче көннән үк Сталинград фронтына эләгә. Аннары – Курск дугасы, Ленинград... Күрсәткән батырлыгы өчен күпсанлы медальләр һәм орденнар белән бүләкләнгән».

12. Олег СЕРДЮК: «Бабам Кондратьев Александр Константинович (1924–1982) сугышка 1941 елда алына. Беренче Украина фронтына эләгә, снайпер була».

13. Гөлнур ХӘСӘНШИНА: «Әнием ягыннан бабам Гайнуллин Лотфулла Гайнулла улы (1903–1943) сугышка киткәндә әбием ике айлык авыры белән кала. Әни тугач, бабайдан нибары бер хат килә: «Кызым минем бәхеткә тугандыр...» Аңардан бердәнбер хатирә – шушы... Тагын – Сталинград сугышында катнашканы мәгълүм. Апас районы Шыгай авылында яшәүче гаиләсе алган кара кәгазьгә: «Хәбәрсез югалды», – дип язылган була».

14. Раилә ХӘЯЛИЕВА: «Бабам Сәмигуллин Газиз Миңнулла улы (1924–2003) Апас районы Олы Бакырчы авылында туган. Сугышка ул 1943 елны китә. Телеграфчы була. Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. Туганнары аның кайтуын сугыш тәмамлангач та ике ел көтә әле».

Баш мөхәррир сүзе



Бөек Җиңү... Юк, ул безгә җиңел бирелмәгән! Миллионлаган гомерләрне корбан иткән мең ярымнан артык көн һәм төн... Батырлык, нәфрәт, өмет, кайгы, күз яше тулы мең ярымнан артык көн һәм төн...
Сугыш турында бабам һәм әнием сөйләгәннәрдән беләм. Әтисе сугышка киткәндә әниемә нибары 4 яшь була. Ә бераздан әби бабайга: «Кызың зур үсте инде, миңа утын кисәргә булыша», – дип хат яза... Пычкының бер башына ике куллап ябышкан әниемне күз алдыма китерәм дә, аны жәлләп йөрәгем өзгәләнә... Әни хатирәләреннән: «Украинадан эвакуацияләнгән гаиләне йортка керттеләр безгә. Матур яшәдек, әни алардан клецки белән аш пешерергә өйрәнеп калды... Җиңү турында хәбәрне ишетүгә бөтен тирә-күрше урамга чыкты. Олысы, кечесе һәммәсе сөенә һәм... барысы да елый: кемдер – шатлыктан, кемдер сугыш кырында ятып калган ирен, әтисен инде кайтарып булмаганнан... Без – балалар ул көнне төрле чүпрәк-чапрактан туп ясап, футбол уйнаган идек»...
Бабай сугыш турында сөйләргә яратмады. Сугыш турында тыңлыйсыбыз килә дип аптырата башлагач: «И-и, балалар, сезгә аны күрергә язмасын», – дип кенә әйтә иде... Безнең арада сугыш афәте кагылмаган гаиләләр юк ул. Бу санибызга кергән һәр язмада диярлек сугыш белән бәйле язмышлар. Хатын-кыз язмышлары... Уйландыра, тетрәндерә, җаннарны сыкрата...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта



«Барысы да хәрби сер! Төп таләп – төгәллек! Берсендә, радиодулкын артыннан барып, фашистлар территориясенә килеп кергәнбез...»



6

Морзе әлифбасында җиңү тарихы
Раилә Хәялиева

Заман һәм без



12

Ева-Мөслимә
Гөлнур Сафиуллина



16

Исәнме, солдат!
Лилия Гәрәева



18

«Татарочкалардан үрнәк алыгыз!»
Раилә Хәялиева

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы

20

Уйна әле, тальян!
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш


24
Хуҗабикә
Әхтәм Зарипов

30

Кем жырлады?
Әмирхан Еники

Яшәеш

36 SOS! Җанымны коткарыгыз!
Эльмира Закирова

Җан ярасы 40
Чулпан Галиәхмәтова


44
Бер мәхәббәт һәм нәфрәт тарихы
Эльвира Шакирова

Җир артындагы җир 52
Алсу Хәлимова

Хатын-кыз галәме


60
Аджарча хачапури



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

МОРЗЕ ӘЛИФБАСЫНДА ҖИҢҮ ТАРИХЫ



Кара төнме ул, юеш окопмы, шомлы урманмы – мөһим түгел. Хәлиткеч приказларны, яшерен хәбәрләрне, дошман тылын тармар итәрлек төгәл мәгълүматны вакытында хәбәр итеп өлгерергә кирәк! Бөек Ватан сугышында элемтәчеләр бүлегенең 80 проценты хатын-кызлар булган. Язмамның герое – Морзе әлифбасы белән фронтның алгы сызыгыннан атлаган, Берлиннан җиңү хәбәрен җиткергән элемтәче Мөршидә БӘДЫЙГОВА. Ул маршал Рокоссовский җитәкчелегендә Белоруссия, Польша җирләрен азат итүдә катнашкан, партизаннар командиры легендар Ковпак белән очрашкан...

•––• ––– –•• ––– •–•• –••– ••• –•–
(Подольск)

Әгәр Мөршидә апа язмышы турында кино төшерелсә, һичшиксез, менә шулайрак башланыр иде: илгә дошман кергән чор. Подольск шәһәре. Завод эшчеләре яши торган гади генә фатир. Стена сәгате текелдәп минутлар саный. Өйдә бөтен гаилә җыелган булса да, ниндидер шомлы тынлык хөкем сөрә. Ишек төбендә чемоданнар, төенчекләр өелеп тора. Әни кеше Хәдичә апа ишекле-түрле йөренә, тәрәзә пәрдәсен ачып юлга күз ташлый. Аннан тагын бер кат, нидер онытылып калмасын дигәндәй, шкаф эчләрен барлап чыга, балаларын, ирен күздән кичерә.

– Күренмиме? – дип сорый әти кеше.

– Юк, – дип өзгәләнеп җавап бирә ул, янәдән сәгатькә карап ала. Келт-келт килеп, сәгате дә пошаманда текелди. Башка балалар, тавыш чыгармаска тырышып, әкрен генә үз эшләренә чумган. Гаилә кемнедер көтә... Югалтудан, калдырып китүдән куркып... Хәтта инде өметсезлеккә күчә барып...

– Вакыт, балалар! Кузгалыйк!


Иренең бу сүзләрен ишеткән Хәдичә апа утырган җиреннән сикереп тора, борчылып әрлебирле йөренә башлый, кабат тәрәзәгә күз төшерә, балаларының өс-башын барлый, һәрберсенең муенына тукымадан үзе тегеп ясаган кечкенә янчыклар кидертә. Янчык бик җиңел: анда бары балаларның метрикалары язылган кәгазь бите дә бераз акча гына... Менә ул соңгы янчыкны бөтереп күкрәгенә кыса да авыр сулап өстәлгә куя. Гаилә, дәррәү кузгалып, ишек төбендәге чемоданнар, төенчекләрне барлый башлый, чыгып китәргә әзерләнә. Шул вакыт ишек ачылып китә!.. Каһәгать елмаеп, аркасына ипи тутырылган капчык аскан олы кыз Мөршидә кайтып керә!..

Бүгенге көндә Мөршидә апа Биектау районында кече кызы

Хәрби кием кигәч кенә үзенең
кая килеп эләккәнен чын-чынлап аңлый башлый.







Әнисә гаиләсендә кадер-хөрмәттә яши. Аның белән очрашуга баргач та беренче тарих итеп менә шушы вакыйганы – ипигә дип иртүк Мәскәүгә чыгып китүен, чак кына гаиләсеннән аерылып берүзе Подольскида калмавын сөйләде. Юкка гына түгелдер. Бүген 95 яшен тутырып килгән сугыш ветеранының язмышы менә шул ипигә чыгып киткән көннән башлап икегә бүленә бит. Әнисе – станокта, әтисе мастер булып эшләгән Подольск механика заводы, илдә сугыш башлану сәбәпле, ул көнне Чиләбе өлкәсенә эвакуацияләнә. Мөршиданең ипидән кайтканын көтә-көтә, завод эшчеләрен Чиләбегә алып китә торган поездга чак соңга калмый алар! Шулай да өлгерәләр, бөтен гаилә белән!

...Пошкырып, пар болытларын күккә чөя-чөя, поезд алга ыргыла. Вагоннар – билгесез киләчәккә нинди өмет өлгесен тәңгәл китерергә дә аптыраган гаиләләр белән тулы. Алданиләр көтә? Кайларга урнашырлар? Ә сугыш? Сугыш озакка сузылырмы? Кире әйләнеп кайтып булырмы?.. Поездның тизлеге кими төшә. Берничә сәгатькә сузылачак озак тукталыш була икән. Тәрәзәдән үрелеп карасалар – зур итеп «АРЧА СТАНЦИЯСЕ» дип язылган! Әтиләре Гарифҗан абзыйның йөрәге күкрәгеннән сикереп төшәрдәй булып тибә башлый. Арчага туктаганнар! Аның туган җире, әти-әнисе яшәгән Арча бит ул! Поездның төгәл кайчан кузгаласын белешә дә, Бәрәзәдән килгән авылдашлары очрамасмы дип, туган җир һавасын суларга төшеп китә. Тирә-юньне урап йөри торгач, тәки очрата ул авылдашын. Сугыш башлангач, авылда җиңелрәк булыр дигән өмет белән күпләр авылга күченгән икән. Әллә соң?.. Кире поездга йөгерә әти кеше. Барысын да җайлый, сөйләшә һәм гаиләсен поезддан төшереп калдыра. Алар Олы Бәрәзәгә (хәзер Әтнә районына керә – *Р. Х.*), әти-әни йортына кайтып урнашалар, бер йортта унтугызау булып яши башлыйлар. Абыйсы да гаиләсе белән, сеңлесе дә балаларын алып туган нигезгә кайткан икән...

«Чит җирләрдә каңгырып йөргәнче, авылда гаиләмә җиңелрәк булыр, тамаклары ач



Алар үзләренә бирелгән шифрларны җибәрер өчен, бертуктаусыз радиодулкыннар эзли.

булмас дип уйлагандыр әткәй, – ди Мөршидә апа. – Кайтып урнашкач, күрше авылда кибетче булып эшли башладым. Рус телен әйбәт белгәнгәме, мәктәпкә укытучы итеп чакырдылар. Шулай итеп, ярты көн укытам, ярты көн кибеттә эшлим. Гаиләдәгеләрнең берсен дә сугышка алмадылар. Әти-әнием олы иде инде, энесеңелләремнең яше җитмәгән. Алар барысы да колхозга эшкә урнашты. Ә миңа 18 яшем тулгач повестка килде... 1943 ел иде бу. Беренче көнне районда комиссия уздым, икенче көнне комиссия кәгазе белән Казанга чыгып киттем. Хәтеремдә, юлда тамак ялгарсың дип, әни өшегән бәрәңге боламыгына он кушып пешергән ике күмәч бирде. Сеңлем белән икәүләп мине Кече Әтнә янындагы җил тегермәненә кадәр озата бардылар. Шунда саубуллаштык... Әниләр кире борылып авылга таба китте, ә мин тегермәнгә сарылдым да алар күздән югалганчы еладым да еладым... Аннан капчыктагы бер күмәчне алып, ашый-ашый Чыпчыклы станциясенә таба атладым..

··–· ·–· ––– –· –

(Фронт)

– Казанга беренче килүем иде, Татвоенкоматны да сораша-сораша гына эзләп таптым. Безне – 50 кызны – Бишбалтадагы елга портыннан баржага утыртып Горький шәһәренә җибәрделәр. Шәһәрдән тагын 12 чакрым ара узып, калын урман эченә урнашкан хәрби базага алып килделәр. Юынып чыккач, хәрби киемнәр тараттылар.

Икенче көнне безгә Морзе әлифбасын өйрәтә башладылар. Сызык-нокта-сызык-нокта... Алдагы көннәремдә инде бу аваз-ноктаrange нокталарны миңа бик еш куллануга туры килде. Ә бу хәрби базада безне биш ай укыттылар. Кай ягым белән аерылып торганмындыр, белмим, әмма беркөнне минем үземне генә чакырып алдылар да, фронтка җибәрелүем турында кәгазь бирделәр. Мин башта Сталинградка барып җитәргә тиеш идем. Юлым Мәскәү аша уза. Башкалада әнинең апасының кызы яши иде. Аңарда туктадым. Туганым белән озын толымнарымны кисеп, киемнәремне хәрби формага алыштырдым. Өс-башымның искеләрен һәм толымнарымны авылга посылка итеп җибәрдем, анда да хәерчелек бит, кирәге чыгар әле дип уйладым...

Мөршидә апаның аннан соңгы истәлекләре Икенче Белоруссия фронты сугышлары белән бәйле. Күчеп йөрүче радиостанциядә элемтәче була ул. Разведчиклар алып кайткан информацияне шифрлар аша элемтәчеләргә тапшыралар. Элемтәчеләр – Морза әлифбасы аша кирәкле урынга хәбәр җибәрә. Кая, нинди хәбәр тапшырганнарын алар үзләре дә белми хәтта. Барысы да хәрби сер! Төп таләп – төгәллек! Берсендә, радиодулкын артыннан барып, фашистлар территориясенә килеп кергәннәрен дә абайламый калалар. Аһ итеп, үзебезнекеләргә кайдалыкларын хәбәр итәләр. Тиз генә барлык документларын җиргә күмәргә, иң мөһиме – ашыгыч рәвештә дошман ягыннан чыгарга диган боерык килә. Дошман нидер сизенгәнче, чыгып өлгерәләр, барысы да хәвеф-хәтәрсез тәмамлана.

Нокта-сызык-нокта... Якты көнме, мөһим хәбәрләр йөрергә тиешле төнме – Мөршидә апаларның радиостанция төягән машиналары һәрвакыт алгы сызыкта. «Бервакыт, – дип ачынып искә төшерә ул, – алгы сызыкка штрафникларны китерделәр. Төрмәдән үзләре теләп фронтка китәргә гариза язучылар. Барысы да шундый ябык, хәлсез. Төймәсез шинельләр биргәннәр. Безгә боларга якын бармаска, кулларыннан берни алмаска диган приказ булды. Тик мин ала идем, җаныем. Башкалар абайламаганда кулыма тоттырган кечкенә кәгазь кисәкләрен сары конвертларга салып, үзләре язып биргән адресны күрсәтеп, почтальоннарга тапшыра идем. Аларның да бит кадерле кешеләренә үзләренең исән икәнлекләрен, башкалар белән бергә туган ил өчен көрәшүләрен белгертәсе килгәндер! Ә бәлки, снарядлар шартламый торган арада хат язарга өлгереп, алгы сызыкта дошман белән көрәшкән кешенең соңгы гозере булгандыр ул? Белмим, көткән кешеләренә барып җиттеме икән ул хатлар?!»

Элемтәче Мөршидә апа өчен сугышның иң ачы мизгелләре – Белоруссия җирләрендә күргәннәре. Дошман чигенә, әмма үзе артыннан явызлык агуы чәчеп калдыра. 1944 елны алар Белоруссия авылларына килеп керәләр. Кешеләр сарайларда тереләй яндырылган, коелардагы су агуланган... Өйләргә аяк бассаң – идән ярыгыннан мөлдерәп, бәлки, исән калып өйгә кайтканнардыр дип, әти-әнисен көтүче сабыйлар карап тора... «Үзебез дә ач, – дип искә төшерә Мөршидә апа. – Аптырагач, бәрәңге бакчаларына кереп, буразналардан бәрәңге казып алып ашый башладык. Бер-ике тапкыр казыгач, әллә ничек булып китте: бу бит балалар өлеше! Ятим калган сабыйларның тамагын туйдырырга тиешле бәрәңге бит ул! Бакчаларга кереп, бәрәңге казып йөрмәдек инде бүтән...»

–··· · ·–· ·–·· ·· –·

(Берлин)

Берлинга барып җиткәнче яралана Мөршидә апа. Җилкә турына снаряд кыйпылчыклары

эләгә. Гомумән, Польша белән Германия арасын узу шактый катлаулы була. Немецлар камалышында калмас өчен качып йөрергә дә туры килә. Берлин эчендә дә каты сугышлар, бәрелешләр була. Безнең элемтәчеләр Берлин шәһәре кырыендагы куаклыклар арасында радиодулкын көйлиләр. Һәм менә!!! Сызык-нокта-нокта-нокта... Төп радиостанция урнашкан машинадан үзләренә яңа хәбәр килә: «Берлин – наш!» Җиңү!!! Берлин тирәсендә булган барлык роталардагы радиостанцияләрдән илнең төрле якларына – «Берлин – наш!» дигән нокта-сызыклар – куанычлы хәбәр тарала! Яшь һәм батыр йөрәкләренә сугыш чынбарлыгын сыйдырган элемтәче кызларның шатлык күз яшьләре аша алгы сызыктан юллаган соңгы хәбәре – җиңү турында!

«Җиңү хәбәрен ишеткәч, Берлинга ашыктык. Шәһәрне әллә ни җимерек дип хәтерләмим. Рейхстаг нык ишелгән, ватылган иде. Бөтен кеше шунда исемен язарга тырыша. Бер солдатның иңсәсенә басып, мин дә үз исемемне язып куйдым. Шатлык, бәхет иде безнең анда! Күпме газап, михнәтләрдән соң! Май аенда әле Берлинда булдык, патрульдә йөрдек. Аннан куркыныч була башлады: җиңелүләре белән килешмәгән яшүсмерләр, шәһәр эчендәге каберлекләргә качып, утлы кораллардан ата-ата, һөҗүмнәр оештыра башлады. Аларның көтмәгәндә һөҗүм итүләре җиңү шатлыгы белән йөргән күпләрнең гомерен өзде. Безне Берлиннан 12 чакрым ераклыктагы Кольздорфка җибәрделәр. Анда казармада яшәдек. Бик озак кайтармадылар әле. Казанга мин 1945 елның ноябрендә генә кайтып җитә алдым. Әтнәдә яшәүче туганыбызга телеграмма суктым, ул безнекеләргә хәбәр иткән. Әти ат җигеп мине каршы алырга килгән иде. Әни, өс-башын карасын дип, киемнәр алырга акча биреп җибәргән. Беркая да кермәдем! Төне буе өйгә кайттык! Мин шундый сагынган идем!!!»

•– •–• –––• •–

(Арча)

– Мин сугыштан кайткач, гаиләбез белән яңадан Подольскига китәргә җыендык. Әмма мине Тәлгать тиз арада үзенә кияүгә чыгарга күндерде. Тәлгать үзе дә сугыштан күп җәрәхәтләр алып кайткан фронтовик егет иде. Берничә тапкыр авыр яраланып авылга кайта, кабат фронтка китә. Мин аны беренче тапкыр күргәндә ул култык таякларыннан иде әле. Минем арттан сеңлем дә кияүгә чыкты. Шулай итеп, әниләр авылда төпләнеп калды. Без Тәлгать белән 56 ел бергә бик матур гаилә булып яшәдек. Дүрт бала үстердек. Ирем 34 ел мәктәп директоры булып эшләде. Һәрвакыт мактаулы, хөрмәтле кеше булды. Кайнанам белән кайнатам да укытучылар иде. Мин дә курслар тәмамлап, башлангыч классларны укыттым. Тыныч тормышның һәр көнен шатланып, кадерен белеп яшәдек без. Бүген менә бәхетле дәвамчыларым – өч кызым, сигез оныгым, унбер оныкчыгым янымда...

Мөршидә апанын бу тарихы инде якты киләчәк, ышанычлы дәвамчылар, аяз күк, тыныч тормыш турында.

Озын-озак яшәргә язсын Сезгә, Ил кызы! Батырлыгыгыз каршында баш иябез...

6 нчы биттәге фотода: Мөршидә Бәдыйгова *(уңда)* фронтташ дусты белән *(фотолар гаилә архивыннан алынды).*



Фото: Анна Арахамия


ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ИҢ КИРӘКЛЕ ҺӨНӘР ИЯСЕ































Фото: Гүзәл Гомәрова

Нурҗиһан МӨХӘММӘТШИНА: «Чехов хаклы: кешенең бар нәрсәсе гүзәл булырга тиеш. Уйлары да, гамәлләре дә, киеме дә... Без үзебезнең эшебез белән шушы гыйбарәне тормышка ашырырга омтылдык. Теккән киемнәребез матур да, сыйфатлы да иде».

16 яше дә тулмаган килеш Чистай тегү фабрикасына эшкә килгәндә ярты гасыр гомерен шушы оешмага багышлармын диган уй килде микән аңа? Тегүче-мотористка, бригадир, мастер, технолог, цех җитәкчесе – 50 ел эчендә язмабыз герое узган юл бу.

Нурҗиһан Мөхәммәтшина – Нурлат районы Бикүле авылыннан. Сигезенчедә укыганда ук кечерәк классларга дәрес биргән кызга күпләр укытучы булуны юрый. Ә ул менә башка юлны сайлый – иптәш кызларына ияреп, Чистайның тегү фабрикасына юл тота. Сеңелләрен үзе тегеп киендерергә яраткан Нурҗиһан бу шөгыльне хатын-кыз өчен иң кирәкле һөнәр дип саный, һәм әлеге фикеренә бүгенгәчә тугрылыклы. Фабриканың тегү машинкалары артына утырганчы, училищеда бер ел укыйсы була, билгеле.

1971 елның 1 августы – аның иң беренче эш көне. Фабрика аны яңа тукыма исе, тегү машиналарының тигез теркелдәве, тегүче кызларның үзара шаярып-көлешүе, күмәк җыр белән каршы ала (фабриканың үз агитбригадасы яз-көз авылларга чыгып, механизаторларга концертлар оештырып йөргән еллар бу). Үзе дә җырларга, биергә яраткан Нурҗиһанны – дүртенче разрядлы тегүче-мотористканы шунда ук үз сафларына кабул итә алар. Дүрт катлы бинаның һәр этажында бер цех. Беренче катта кисүчеләр цехы урнашкан, ә калганнарында – тегүчеләр. Нурҗиһан эшләгән цехта ир-ат күлмәкләре тегәләр.

«Мин эшкә килгән елларда фабрикада ике меңгә якын кеше эшли, ә бер цехта көненә бер мең күлмәк тегелеп, складка тапшырыла иде, – дип искә ала Нурҗиһан ханым. – Кайларга гына таралмый иде без теккән киемнәр?! Бергә эшләгән хезмәттәшебез чит илгә чыккач, бер күлмәк сатып алган. Этикеткасына «Чистополь» дип язылган ул күлмәкнең үзебезнең Чистай тегү фабрикасында тегелгәнен өйгә кайткач кына абайлаган». Кулы эшкә ятып торган тырыш кызны өч елдан бригадир итеп билгелиләр. 1987 елда ул цех җитәкчесе вазыйфасына керешә. Бу вакытта фабрика тагын да үсә, ассортимент киңәя, яңадан-яңа машиналар кайтарыла. «Мин эшкә килгәндә 97 нче класслы гади генә машиналар иде. Цех җитәкчесе булып эшләгәндә Англиядән зур заказ кабул иттек: укучы балаларга чалбарлар тектек. Менә шул чакта бик күп төрле яңа автомат машиналар алынды, – дип сөйли Нурҗиһан апа. – Ул елларда фабрика якын-тирә авылларда яшәүче хатын-кызларны да эш белән тәэмин итеп торды. Өйдән эшләүчеләр күп иде безнең».

«Үзегез теккән киемнәрне кешеләрдә күрү куандыра идеме?» – дип сорыйм. «Әлбәттә! – ди ул. – Фабрикабызга рәхмәт хатлары язалар иде. Үзем дә, кая гына барсам да, киемнәр кибетенә кереп үзебез теккән күлмәкләрне барлыйм, сыйфатын тикшерә идем».

Бүген исеме Чистайның «Мактау китабы»на кертелгән Нурҗиһан Мөхәммәтшина (ул вакытта әле Әхмәтова) – «Азат хатын» журналының 1976 елгы декабрь саны тышлыгы героинясы.

Быел җәй аның эштән туктаганына – бер ел. Юк, дөрес әйтмәдем, эштән туктарга җыенмый әле ул, һаман да яраткан эше белән мәшгуль. «Йөрәгем текелдәгәндә тегү машинам теркелдәр», – ди ул шаяртып.

Лилия ГӘРӘЕВА

ЕВА-МӨСЛИМӘ



Фото: Анна Арахамия

– Бер аягым белән генә басарга иде туган якка!.. Мөслимә апаның кызлары әниләренең бу сүзен барысы да хәтерли. Әрнеп, өзгәләнеп, бик-бик сагынып әйтелгән булгандыр ул. Үзен чит-ят туфракта адашып калган кош баласыдай хис иткән чакларда әйтелгәндер.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Сөйләшкәндә мин аңа исеме белән дәшмәскә тырыштым. Чөнки кем дип эндәшергә дә белмәдем. Ева Федоровна дисәм... Авылдашлары аның паспортында исеме шулай язылуын ул лаеклы ялга чыгып, пенсия ала башлагач кына ишеткән. Бу исем аның инде үзенә дә ят тоелуы бар. Мөслимә апа дисәм... Хәтер – карурман, ул күп нәрсәне оныттырып, аны соңгы вакыт яшьлегенә, туган якларына алып киткән. Украинага, Карпат итәгенә, Дунай ярына... Телендәге җырларына кадәр үз халкыныкы әнә:

Ты ж мене пидманула,
Ты ж мене подвела,
Ты ж мене, молодого,
С ума-разума свела.

Бөек Ватан сугышы башланганда Евага 16 яшь кенә була. Беренче көннәрдән үк оккупациядә калалар. 1943 елны аларны товар вагоннарына төяп Германиягә озаталар. Юлга чыгар алдыннан кызларның чәчләрен төбенә кадәр кыралар...

Хатирәләр өзек-өзек кенә.

Бертуган апалары белән юллары бик тиз аерыла: башка күрешүләр инде насыйп булмый – алар әйләнеп кайтмый.

Шәһәрләрнең, концлагерьларның исеме генә алышына: шартлар шул ук кала. Башта – Гдыня (Польша). Монда кара көзгә кадәр бер поляк панында эшлиләр, җир эшкәртәләр. Аннан – Щецинек (Нойштеттин, Польша). Бу шәһәрдә тимер юл салалар, авыр шпаллар ташыйлар. Аннан инде – Бранденбург (Германия). Үзләренең бу заводта самолетлар эшләп чыгаруларын алар белми дә. Монысы соңрак, әсирлектән азат ителеп, үзебезнекеләр сорау ала башлагач ачыклана. Ева белән янәшә станокларда 12-13 яшьлек балалар эшли: ябык бармаклары белән иң кечкенә детальләрне алар гына тота ала.

1945 елның 23 апрелендә безнекеләр концлагерьны бомбага тоталар. «Бер бункерга яшеренеп кенә исән калдык, – дип сөйли Ева. – Янәшәдәге лагерьда власовчылар булган икән. Ә без белмәдек тә... Андагы солдатларны пулеметлардан атып кырып бетерделәр.

«Әнинең беркайчан безнең белән русча сөйләшкәне булмады. Без белмәгән татарча сүзләрне дә белә иде ул».



Йөзләгән власовчы солдатның җан бирә алмыйча әрнешеп-тартышып яткан гәүдәләрен үз күзләрем белән күрдем. Бу коточкыч күренеш бик озак төшләргә кереп йөдәтте».

Сорау алулар башлана. «Ниһаять, котылдык! Өйгә кайтабыз!» – дип сөенгән, тиздән ап-ак чәчәккә күмелгән Украинаны күрәбез дип хыялланган кызларны поезд туп-туры салкын Себергә алып китә. Совет хәрби суды Еваны җиде елга хөкем итә. Нәрсәгә икәнен кем аңлаткан? Үзе: «Хәрби заводта эшләгән өчендер, мөгаен», – ди.

Мөслимә-Ева сөйли:

– Себердә безнең исем «фашистская подстилка» гына булды... Тел белән дә кыерсыттылар, кул белән дә... Ачлыктан интектек... Берсендә дус кызымны өч бәрәңге һәм бер телем ипи урлаганда тоттылар. Астылар... Өч көн буе бауда эленеп торды. Арабызда иң чибәре иде. Башкаларга сабак булсын, диделәр.

Вышкага менеп тәмәке төпчеге алган ике әсир егетне исә ат койрыгына тагып, үлгәнче лагерь ишегалдында сөйрәп йөрделәр...

Бервакыт көзге салкын яңгыр астында эшләргә туры килде. Көне буе койды гына! Фуфайкам сыгып алырлык булып чыланды. Киптерергә куйган идем, бераздан нинди ис чыга дип барсам, ярты фуфайкам янып бетә язган! И-и, еладым шул чакта... Кышка кергәндә яланөс калдым бит.

Немец әсирлегеннән котылуына, тагын сигез елга Сталин лагерена озатылган татар егете Исламгәрәйне дә Себер көтә. 1940 елның 17 мартында армиягә алынган була ул. Фин сугышын кичә. Бөек Ватан сугышы башланганда Эстониядә хезмәт итә торган була. Чолганышта кала. 300 көн буе тигезсез көрәштән соң, немецларга әсирлеккә төшә. Латвия, Польша концлагерьларында утыра. Иң яманы аның өчен дә сугыш беткәч башлана...

Алар шунда – лагерьда, урман кискәндә танышалар.

1954 елны Исламгәрәйнең туган ягына – Норлат районы Югары Норлат авылына Әхмәтсафиннар дүртәү кайтып төшәләр. Кулларында ике кечкенә бала – Сания белән Гарифулла. Улларының бусагадан исән-сау атлап керүе барысын да оныттыргандыр. Беравыз татарча белмәгән киленгә карап, йортта: «Ә бу марҗаны нигә алып кайттың?» – диюче булмый. Мулла чакырып, шул көнне үк никах укыталар. Евага яңа исемне килендәше Мәрьямгә якынрак булсын дип кушалар: икенче көнне иртән алар капкасыннан суга барырга Мөслимә исемле яшь килен чыга.

Кайнатасы бигрәк тә яраткан Мөслимәне. «Ул Мәрьямгә караганда да җитезрәк», – дия торган булган. Килененең башкалар торганчы Кондырчадан су алып кайтып, иртән иртүк комганнарны тутырып куюына бик шатлана торган булган ул.

Бер-бер артлы тагын биш бала туа: Шәрифулла, Зәйдулла, Фәния, Сәҗидә, Минзаһир.

Кызы Фәния сөйли:

– Татарчаны әни авыррак өйрәнгән. Әмма без үскәндә ул инде бик әйбәт сөйләшә иде. Аның еракта кайтканын белә идек, әлбәттә. Авылда андый нәрсәне онытмыйлар. Безнең кушамат «марҗа» булды. Марҗа Фәниясе, Марҗа Саниясе... Әни миннән гел туганнарына, сеңлесе Фросяга хат яздыра иде: ул әйтеп тора, мин язам. Әни үзе бер класс та укымаган. Нигә укырга туры килмәгәндер аңа, белмим. Алар биш бала үскәннәр, сеңелләре укый да, яза да белә иде. Дүрт гектар җиребез бар иде, шунда атлар, сыерлар тоттык, дип сөйли иде әни. «Муеннарына кыңгырау тага идек тә сыерларны тауга җибәрә идек», – дия иде. «Әни тукыманы үзе тукыды, безне бик матур киендерде», – дип сөйләгәнен дә хәтерлим. Конверт тышына язган адреслары әле дә истә: Скадовский район, село Красное. Әбиләр сугыштан соң диңгез буендагы шушы авылга күченәләр. Әбиебез 88 яшенә җитеп вафат булды. Без аны бер тапкыр да күрмәдек.

Мөслимә әбинең безнең кулдагы фотосурәтләргә карап йөзе балкып китә:

– А это моя мать – Анастасия Яковлевна! Это тоже наша семья. Аня – сестра моя. Вот Фрося. Вот Аня и Васенька...

Әнисен һәм иң кечкенә энесе Василийны сугыштан соң Ева бер тапкыр гына күрә. Балалар азмы-күпме үскәч, тормышлар берникадәр рәтләнгәч, Исламгәрәе белән алар Украинага кунакка баралар. Калган бөтен гомер эчендә – бер тапкыр! Нишләтәсең, ишле гаилә белән мөмкинлек тә, җай да булмагандыр инде. Югыйсә Исламгәрәе дә төшеп калганнардан түгел – алтын куллы балта остасы була. Норлат шикәр заводында эшли, колхозның балта осталары бригадасында иң оста балтачы санала. Башка чыгалар – йортны үзе сала. Энесе Галимулла бер бозау бирә.

Кызы Фәния сөйли:

– Әниләр кунакка бер атнага бардылар. Алтмышынчы еллар ахыры булгандыр бу. Кыш ахыры, яз башы дип хәтерлим. Әнинең туганнары да әтине якын иткән. Аксыл кеше иде безнең әти, «Саша руска охшаган», – дигәннәр. Күп итеп күчтәнәчләр алып кайтканнар иде. Безгә Украинадан гел посылкалар килеп торды. Бала-чага күп булгач, булышканнардыр, кием-салым, җиләк-җимеш җибәрәләр иде.

Ә берсендә әнинең сеңелләре кунакка кайтты безгә! Алар да шул берәр атна торып киттеләр. Күрше Миннасыйх абзыйлар аларны мунчага дәштеләр. Ул чакта кара мунча иде әле. «Нинди мунча бу сезнең, корымга буялып беттек», – дип чыктылар...

Балаларының барысына да чын татар тәрбиясе биреп, никах укытып, башлы-күзле иткән Мөслимә апа.

Бөек Ватан сугышы елларында Германия СССРның 5 миллионга якын кешесен ирексезләп үзенә алып китә. Остарбайтерлар завод-фабрикаларда, авыл хуҗалыгында эшли. Аларның 70 проценты – украиннар, ә яртысыннан күбрәге – хатын-кызлар. Рейх җиренә аяк басканда көчләп китерелгәннәрнең 30 процентына әле 16 яшь тә тулмаган була. Ева Федоровнаның әниләре сугыштан соң килеп урнашкан Красное авылыннан гына да (Херсон өлкәсе, Скадовский районы) 150 егет һәм кызны шушы язмыш көтә. Ашау-эчү – ачтан үлмәслек кенә, эш – коточкыч авыр. Бу шартларга күпләр чыдамый... Остарбайтерларның байтагы кире әйләнеп кайтмый...

Соңгы вакытта элемтәләр өзелде шул. Берсенең дә язмышын инде белмибез...

Кызы Сания сөйли:

– Концлагерьда утырган чаклары турында әни ялгышып та сөйләми иде дисәм дә була. Ул вакытны искә төшерергә яратмый иде бит алар. «Германиядә эшкә иртән алып киттеләр, кич алып кайттылар. Нәрсә кушсалар, шуны эшләдем. Эш авыр иде, әмма җаныбызны газапламадылар. Бер тапкыр кырда черек бәрәңге ашаган өчен генә кыйнаганнар иде... Ә лагерьда бик рәнҗеттеләр, Себердә кыерсытылуны күбрәк күрдек», – дип әйткәне генә булды. Әти кул астында эшләгән ул. Әти агачны еккандыр, ә ул ботакларын кискәндер... «Беравыз татарча сүз белмәгән килеш нигә татар авылына кайттың, әни?» – дип сораганым булды. «Сугыштан соңгы еллар иде бит, кызым. Безнең сайлау мөмкинлеге булмады. Урманда нарат агачына кияүгә чыга алмый идем лабаса», – дип җавап бирде ул. Шаяртып кына әйткәндер, хатын-кыз күзе төшәрлек кеше иде безнең әти. Әни белән алар бик матур яшәделәр. Бөтен ир белән хатын да шулай тату яши алса иде әле ул! Әти аны шундый ярата иде, кочаклап кына торды. Алардагы мәхәббәт! Ул әнигә беркайчан кул күтәрмәде, авыр сүз әйтмәде. Эчкән килеш тә әнигә каты бәрелгәнен белмим... Әтинең аңа «Ева», дип дәшкәнен ишеткәнебез булмады, «карчык», дия иде. Әни дә әтине хөрмәт итеп яшәде. Исемен бервакытта да кыскартмады, гел тутырып «Исламгәрәй» дип дәшә иде. Әти үз кулы белән ясаган бернәрсәгә кагылдырмый әнә өйдә. «Минем Исламгәрәемнеке!» – дип кенә тора. «Кирәк булса, мин үлгәч кузгатырсыз, алыштырырсыз», – ди.

Мөслимә апа авылдагы хатыннарның берсеннән дә аерылып тормаган. (Район үзәгенә – Норлатка барырга туры килгәндә кия торган кызыл күлмәге белән кызыл туфлие башкаларда булмаса гына.) Алар белән бергә колхоз басуында чөгендер утаган. Алар кебек үк токмач кискән, бәлеш салган, якмыш (аларда кыстыбыйны шулай атыйлар), кабартма пешергән. Ят ризыклардан өстәлендә вареники гына булган: анысын кызларына да пешерергә өйрәткән. Украиннарның милли ашына – борщка исе китмәгән. Йортка дуңгыз итен – хәрамне кертмәгән, үзе аны авызына алмаган. Башкалар кебек үк Коръән ашлары үткәргән. Ире белән бергә парлап ураза тоткан. Догалар ятлаган. («Авыз ачканда укый торган догаларны миңа әни өйрәтте», – ди кызы Сания.) Дөрес, Олы көндә – Пасха бәйрәмендә балаларына суган кабыгы суында буялган йомырка пешереп ашаткан. Кечкенә чакта бу көнне атка утырып чиркәүгә баруларын искә төшергән.

Кызы Фәния сөйли:

– Әти безгә гел: «Сезнең әниегез авылдагы иң пөхтә хатын!» – дия иде. Башкалар да аның турында шулай дип әйттеләр. Булганлыгы, тырышлыгы бар иде әнинең. Әле беркемдә дә булмаганда безнең бакчада кыяр, помидор үсте. Суган, петрушка, сарымсак... Нишләп болар кешедә юк дип аптырый идем... Чәчәкләр яратты әни! Хәзергә кадәр өй тирәсе җәен чәчәккә күмелә аның.

Һәр яз саен 9 Майда – Җиңү көнендә бәйрәмнән читтә калган өчен күңелләре елавын балаларына белгертми алар. Андый еллар да бик озакка сузылган шул... Авылда алар кебек бәйрәм саен кыенсынып калучы Мәүлет абый була әле тагын. Ул да «тамгалы» – Франциядә тоткынлыкта булган. Районга бер атаклы комбайнер, ә 9 Майга чакырмыйлар үзен... Әле Исламгәрәй абзый исән чакта ук Әхмәтсафиннар икесе дә акланган: ире дә, хатыны да. Димәк, күп булса, 25 ел элек. Сугыш ветераннарына тиеш булган өстенлекләрдән дә шул вакыт кына файдалана башлыйлар.

– А вы эту песню помните? – Быел көз 95 яшен тутырачак Мөслимә апа Әхмәтсафина тагын җыр башлый. (Гомер буе өйдә дә, урамда да татарча гына сөйләшеп яшәгән әниләренең кинәт үз туган теленә күчүенә кызлары әле һаман ияләшеп җитә алмый.)

...Ночь коротка, спят облака,
И лежит у меня на ладони
Незнакомая ваша рука...

....В этом зале пустом
Мы танцуем вдвоем...

Сугыш елларында туган атаклы җырларның берсе бу – Евгений Долматовский һәм Марк Фрадкинның «Случайный вальс»ы.

Еваның моннан меңнәрчә чакрым ераклыкта дөньяга килеп, гомерен шушында – татар авылында Мөслимә булып уздыруы очраклы түгелдер, анысы – язмыштыр.

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

...Ә КҮҢЕЛ ҺАМАН КӨТӘ



Фото: гаилә архивыннан

Әтием сугышка чыгып киткәндә, мин яшь ярымлык сабый булганмын. Әни янына әле миннән башка әтинең өч сеңлесе дә сыенган. Миңа 3 яшь тулганда әтинең хәбәрсез югалуы турында кайгылы хәбәр килгән. Әнинең сулыгып-өзгәләнеп елаулары мине сабыйлыктан тиз чыгарды. Тамак бик нык ачса да, ашарга сорап елаганымны хәтерләмим. Кечкенә булсам да, әниемнең: «Өйдә өреп очырырлык та он калмады», – дигәнен аңлый башлаган идем инде. Җәй көннәрендә төп ризыгыбыз – кычыткан ашы, юа, әнис, карга күзе, песи борчагы, кәҗә сакалы... Язын кырда калып өшегән бәрәңгедән пешерелгән кәлҗемә безнең өчен кунак сые кебек булыр иде. Әле бит аның өс-башка кияренә юк. Безнең әби киндер сукканлыктан, миңа күлмәк-ыштанлык кына кала иде анысы.

Сугыш тәмамлану белән генә тормышлар алай тиз җайланып китмәде. Типсә тимер өзәрдәй ир-егетләр яу кырыннан әйләнеп кайтмады. Сугыш тәмам бөлдергән авыл, хәерчегә калган колхоз һаман да шул карт-коры, сугыш елларында тәмам йончыган хатын-кыз, гарипләнеп кайткан ир-ат иңендә булды. Без, үсмер балалар да, булдыра алган кадәр басуда өлкәннәргә булышабыз. Барлык эшләр кулдан башкарыла бит. Урак өсте җиткәч, әниләргә борчак йолкышырга барабыз. Аның бер куанычы бар: куллар яргаланып бетсә дә, туйганчы борчак боткасы ашаталар. Әни, даими эш булыр дип, колхоз сарыкларын карарга алынды. Мин аның янына барам да мал өендә бәрәннәр белән алабута оны ялыйм. Сабый чаклар әнә шулай мәхрүмлекләргә уралып, үксез узды.

1947 елда укырга кердем. Әни киндер букча тегеп бирде. Ләкин шул букчага салырлык китап-дәфтәрләр генә юк. «Әлифба»ны берничә балага берне бирәләр. Тырышабыз, бер-беребезгә барып, бергәләп өйрәнәбез. Берара мәктәптә кайнар аш та оештырганнар иде, тик ул озакка бармады. Икенче сыйныфка күчкәч, җәйге каникулларда безне башак җыярга йөртәләр. Аякка кияргә юк, ялан аяклар басуда камылга тырналып канап бетә иде. Өченче сыйныфта яшьтәшләрем белән фермага, әни-апаларга булышырга йөри башладык. Без басу буенда гына яши идек. Игеннәр өлгергәч, күрше кызы белән арыш, бодай башаклары уып ашыйбыз. Шуның белән тамак туйган кебек була. Әни аякка чабата да алып биргәч, дөнья рәхәтенә чыккандай булдым. Әниләр урак урганда без дә басуда – көлтә бәйләү өчен учма әзерлибез, җирдә коелып калган башакларны җыябыз.

Август ахырларында басуга йөрү кайгысы бетә, мәктәпкә җыенырга кирәк. Тик ничек җыенырга менә? Китап-дәфтәр алырга акча юк. Ул чагында колхозчыларга хезмәт хакы бирмиләр – «таяк»ка эшләтәләр, көзен шуңа карап ашлык бирәләр. Еш кына ул ярты ел ашарга да җитми.

Авырлыклар барысына да өйрәтә икән ул. Без дә кечкенәдән дәфтәр-каләм алырлык акчаны үзебез таба идек. Башта сәрби кузагын җыеп тапшырабыз, аңа аз гына акча бирәләр. Аннары гөлҗимеш җыябыз. Бик тә авыр иде ул еллар. Шуңа күрә күбебезгә укуны дәвам итүләр насыйп булмады – тормыш тәртәсенә бик иртә җигелдек.

Дүртәр-бишәр сабыен кочаклап тол калган авылдашларның күз яшьләрен онытырлык түгел. Әле бит хөкүмәт җыя торган түләүләре күпме?! Балаларының авызыннан өзеп соңгы икмәген түләүгә биреп җибәргән, икенче көнне ачлыктан тилмергән сабыйларын кочып елаган аналар,囲 эштә изелеп, күптән инде бакыйлыкка күчте. Без, сугыш ятимнәре дә, 80 яшькә җиттек. Ә сугыш чорында күргәннәрнең кара шәүләсе гомер буе озата килә. Әле дә төшләргә кереп газаплый.

Әтиләре исән кайтканнарның тормышы җиңелрәк барды. Күбесе югары уку йортларында укыды. Ата терәген тоеп яшәү үзләренә дә көч бирде. Ә менә сугыш ятимнәренә тормыш ачысы нык эләкте. Югыйсә без дә ил азатлыгы өчен башын салган солдат балалары бит. Тик моны искә алучы гына юк. Үзебезне хөкүмәткә һаман да артык кашык итеп тоеп яшибез.

Әллә Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан берәр төрле ярдәм булырмы дип өметләнгән идек... Күңел көтә бит ул.

Тукай районы Күзкәй авылында яшәүче Хәнифә әби ВӘҖИЕВА сөйләгәннәрне Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА язып алды.





Исәнме, солдат!



Лилия ГӘРӘЕВА

«Бәлки, аларны тынычсызламаскадыр? Ничә ел ятканнар бит инде...» Ә җавапны бары алар – әтиләре хакында һичьюгы бер хәбәр булса да ирешүен тилмереп көткән сугыш ятимнәре генә бирә ала. Ул җавап – мөлдерәмә күзләрдә... Артык дулкынланудан яшь аралаш пышылдап кына әйтелгән (хисләр комачаулый!) «рәхмәт» сүзендә... Ниһаять, ничә еллардан соң, хыяллары чынга ашып, әтиләренең каберенә булса да барып баш ия алуда... Менә кемнәрдән сорарга ул җавапны!

...Иң беренче сәфәренә 16 яшендә кузгала Ольга. Романтика эзләп элми иңнәренә биштәрен, юлның теге очында «Үлем үзәне» көтә. Новгород өлкәсенең Мясной Бор авылы янындагы үзәнлек әнә шулай атала. Немецлар тар-мар иткән Икенче удар армия сугышчыларының сөякләре дистәләрчә чакрымнарга чәчелгән... 14 яшеннән «Голубые молнии» хәрби-патриотик клубына йөреп чарланган, парашюттан гына да сигез тапкыр сикергән кызны көненә ничә чакрым юл узып, ничә метр җир казу да, палаткаларда бөгәрләнеп йоклап, иртән тагын эшкә керешү дә – берсе дә куркытмый. Икенче елны да тутыра юл биштәрен.

«Нефтехимик» эзләнү отряды командиры Ольга Ланцованың гел әйтә торган сүзе бар: «Мондый җиргә кеше үз гомерендә яки бер генә бара, яки гомере буе йөри». Укыган, балалар үстергән (сүз уңаеннан, ире белән дә эзләнү отрядында танышалар) елларда тәнәфес ясалса да, 2004 елда «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятендә оешкан отрядның иң беренче эзләнүчеләреннән ул. 2007 елда аны командир итеп билгелиләр.

Мондый экспедицияләргә йөрүчеләр гади генә кешеләр түгел. Югыйсә елга бер тигән җәйге ялыңны үз тормышыңа багышламыйча, өеңнән читтә – Смоленск, Волгоград, Ленинград үзәннәрендә, Карелия, Белоруссия урманнарында уздырыр идеңме? Дөрес, хәзер шартлар күпкә уңайлы, ди отряд командиры. Һәркемгә аерым чатыр, мунча, электрогенератор, су помпасы, бензин пычкысы, металл эзләгеч, яңа автобус – болар «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыяте һәм Түбән Кама шәһәре хакимиятенең ярдәме.

Отрядның даими составында егерме бишләп алар. Күбесе «Түбән Кама Нефтехим»нныкылар. Сергей Сергеев, Олег Зиннәтуллин, Ринат Юмаев, Игорь Трошин, Николай Соловьев һәм Рәсимә Булатова (аларны да отряд кавыштырган), Илдар Хәкимуллин, Рафаэль Лотфуллин (командирның урынбасары), Денис Рудаков, Рафаэль Нуриманов – отрядның тоткалары, командир әйтмешли – «үзәге». «Сизгерлеге бар безнең Нуримановның, – ди Ольга Николаевна. – Першинның Кызыл Йолдыз орденын да ул тапты!»

Смоленск өлкәсенең Глинковский районына экспедициягә килгән отряд урнашырга да өлгерми, егетләр разведка уздырырга ниятли. Лагерьдан 500 метр читтәрәк Рафаэль Нуримановның металл эзләгече тавыш бирә. Казу эшләре башлана. Башта снаряд ярчыгы табыла, ә аның астында – орден! Ике көн казу эшләре алып барсалар да, егетләр ул чакта орден иясен таба алмый. Бәлки, шул урында төшереп кенә калдыргандыр?! Экспедициядән соң дәүләт бүләгенең кемгә бирелүен ачыклау эше башлана. Эзтабарларның күмәк тырышлыгы белән 264090 нчы номерлы Кызыл Йолдыз орденының танк командиры Першин Василий Давыдовичныкы булуы ачыклана. 1916 елгы Василий Першин үзе дә Смоленск өлкәсендә туган. 1943 елның 13 сентябрендә кылган батырлыклары өчен аңа орден бирелә, ә ике көннән – 15 сентябрьдә, үз өеннән 200 метр гына читтә танк эчендә янып һәлак була.

Отряд елга ике тапкыр юлга кузгала. Беренчесе – яз көне, чәчү башланганчы, икенчесе – игеннәр җыелгач. Ольга ханым сөйләгән истәлекләрдән күңел тетрәнә, яу кырыннан кайта алмый калганнарны әле бүген дә көтүчеләр барын белеп үзәк өзгәләнә.

2018 елның 23 апрелендә Ярцев шәһәреннән «Прорыв» эзләү отряды бер сугышчыны таба. Янында медальоны бар, һәм ул яхшы сакланган. Татарстан егете Фатих Вәлиев булып чыга ул солдат. Ольга шунда ук Казанга хәбәр сала – туганнары бармы? «Хәтер вахтасындагы һәркем күңеленнән берничә газаплы этап уза, – ди командир. – Беренче уй – кемне дә булса таба алырбызмы? Егетләр кулындагы металл эзләгеч тавыш бирә. Озын щуп белән тикшереп, чикләрне билгелибез. Бәлки, ул гап-гади бер тимер кисәгедер... Ә бәлки, билгесез солдатның башындагы каскасыдыр... Археология ысулы белән, туфрак катламын сантиметр арты сантимер гына күтәреп казыла бу урын. Иң дулкынландыргыч мизгелләр алда. Исәнме, солдат! Ниһаять, без сине таптык! Ә күңелдә уйның икенчесе – янында медальонның яки исемең язылган шәхси әйберең булырмы? Кем икәнлегеңне ачыклый алырбызмы?»

Сугыш тәмамланганга – 75 ел. Ә үзәннәрдә, урманнарда, яланнарда тын гына көткәннәр әле исәпсез...

75 ПОБЕДА! 1945–2020

1941 елны сугышка алынучыларга медальоннар тапшырыла. 1942 елдан аны Кызыл Армия кенәгәсенә алыштыралар. 75 ел эчендә кәгазьдән ни генә кала соң?! Менә шуңа күрә дә табылган һәр солдатның исемен ачыклау мөмкин түгел.

Өченче этап – сугышчының туганнарын табу. Хәтер вахтасына басучыларның күңелендәге өченче газаплы уй да шул – көтүчең бармы, солдат?

...2018 елның апрелендә күтәрелгән Фатих Вәлиевнең туганнары өч көндә барлана. «Әтием табылдымы?» – дип өзгәләнә улы – инде үзе дә 80 яшен тутырган чал чәчле бабай. 9 Май көнне туган туфрагына җирләнә солдат. 30 яшьлек әтисенең сөякләре салынган табут өстенә 80 яшьлек улының күзләреннән яшь тама. Хәтер вахтасындагыларның күңелен газаплаган уйның дүртенчесе шушы – сине алырга килерләрме, солдат? Күтәрелгән сугышчының җәсәден туган ягына алып кайтып җирләү хокукы якын туганнарга яки шул җирлекнең администрациясенә генә бирелә.

2011 елны Смоленск өлкәсенең Жеребцово авылы янындагы каенлыкта отряд ике сугышчы күмелеп калган кабергә юлыга. Берсенең балтыр сөяге янында кашык табыла. Кашык сабында язу – Чалых. «Мемориал» берләштерелгән мәгълүмат базасыннан карап, Чалых фамилияле солдатның Алтайдан фронтка киткәне һәм Смоленск өлкәсендә һәлак булганы ачыклана. «Нефтехимик»ка күрше генә лагерь булып урнашкан Алтай отряды шул ук көнне өйләренә шалтырата. Берничә көннән алар инде Чалыхның туганнары белән телефоннан сөйләшә. 1918 елгы Павел Пантелеевичның 1941 елны дөньяга килгән кызы әтисенең җәсәде артыннан килергә теләк белдерә. Павел Чалых 2011 елның 20 маенда Алтай өлкәсе Новичиха авылы зиратына – хатыны янәшәсенә иңдерелә. Икенче солдатның кемлеген ачыклап булмый. Әһ, үзәкләр өзелә дә соң шундый вакытларда. Менә бит ул, еллар узса да, табылды. Тик кем соң син, билгесез солдат?

Узган ел Волгоград өлкәсендә эзтабарлар ун кызылармеецны күтәрә. Дүртесенең медальоны бар, ләкин өч медальон начар ябылган, эчендәге вкладышны танырлык түгел. Ун солдатның нибары берсе – 1942 елны хәбәрсез югалган Бочарев Михаил Юрьевичның гына исеме ачыклана. Август аенда Тула өлкәсеннән Бочаревлар бабаларын соңгы юлга озатырга килә. «Сестренка! – ди аңа сугышчының 60 яшьлек оныгы, – Без синең белән хәзер туганнар кебек».

Шушы 15 елда отряд утыз биштән артык экспедициядә булган, сигез йөздән артык совет солдатын һәм командирны күтәргән, егерме өчесенең исемен ачыклаган, ундүртенең туганнарын тапкан.

«Быел кыш Смоленск егетләре татар сугышчысын күтәрде. Аны фронтка озаткан Байгол авылы Түбән Камадан 16 чакрымда гына. Туганнарын табышуны сорадылар. Гомумән, иң кыены да – солдатларның туганнарын табу, – дип сөйли Ольга. – Ярый интернет бар, төрле төркемнәргә хәбәрләр юллыйбыз, районына, авылына чыгабыз. Бу солдат әле өйләнергә дә өлгермәгән булган. Авылда аның йөргән кызы калган. Ул шулай сөйгәнен көтеп, ялгызы гына картайган. Без шул кызның сеңлесенең балаларын эзләп таптык. Башта югалып калды... Безнең хәбәрдән соң күпләр югалып кала. «Телевизордан югалган солдатларны тапканнарын күрсәткәндә бу сиңа бер дә кагылмас кебек. Ә үзеңнең туганың, авылдашың, райондашыңны гына тапсалар да күңелне бик тетрәндерә икән шул», – диләр.

Тиздән «Түбән Кама Нефтехим»да Бөек Ватан сугышына багышланган музей ачылырга тиешлеге берәүгә дә сер түгел. Залдагы экспонатларның да күбесе «Нефтехимик» эзләү отряды яу кырыннан алып кайткан табылдыклар.

...Менә быел да 9 Май – Бөек Җиңүнең 75 нче язы килер. Ольга ханым Ланцовага рәхмәт хисе тулы хатлар явар. Ә август аенда «Нефтехимик» кабаттан юлга кузгалыр. Үзәннәрдә аларны көткәннәр барда, отряд өйдә кала алмый әлегә...











Фото: Рафаэль Лотфуллин

«ТАТАРОЧКАЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ!»





Раилә ХӘЯЛИЕВА

Ладога күленең ачы җиле йөзне кисә. Дошман күзе төшмәсен өчен киелгән ак бөркәнчек эченә үтеп кергән суык тәнне калтырата. Тез, терсәкләр әчетеп сызлый. Алда – ак киңлек, билгесезлек. Кая барганыңны, кайчан барып җитәсеңне аңлый торган түгел. Ладоганың рәхимсез җиле, салкын бозы өстеннән тәүлеккә якын шуышалар инде. Торып басып тән язарга да ярамый! Атачаклар!

Тәтешкә окоп казырга китеп, ике ай ярым зәмһәрир суыкта эшләгәннән соң, күтәрәмгә калган әтисен авыр агач чанага төреп салып, 150 чакрым араны тәпиләп узу – чандыр гәүдәсенә төшкән иң авыр шул сынау булыр дип уйлаган иде Хәтирә. Кар салган ул юлны ачлы-туклы килеш нинди мәшәкатьләр белән уздылар бит: очраган бер авылда төн кунып, ипи теләнеп... Әмма ничек итсә итте, әтисен башта Казанга, аннан Кукмарага алып кайтып җиткерде 18 яшьлек кыз. Инде менә абына-сөртенә, шуыша-шуыша ут эченә кереп бара...

Авылдан Әсма, Нәсимә, Сәрби һәм Хәтирәне военкоматка чакыралар. Ул үзенең сугышка алынасына һич тә ышанмый. «Буем кечкенә, миңа кем автомат тоттырсын!» – ди. Дус кызы Сәрби дә шул чама гына, аны да алмаслар. Арчада комиссия узалар. Буем җитмәс дип барган Хәтирә белән Сәрбине иягеннән тартып булса да «үстерәләр» военкоматта. «Кружка-ложка-сухари, завтра к восьми приходи!» – дип, аркаларыннан сөеп чыгаралар. Авылга елый-елый кайтып керә алар. Икенче көнне ике дус кыз сугышка чыгып китә. Арчадан туп-туры Мәскәүгә җибәрәләр. Монда радистлыкка укыйлар да, Химки шәһәренә хәрби өйрәнүләргә китәләр. Аннан менә мәхшәрнең эченә үк барып керәләр...

Тезләнеп басарга да ярамаганны белгән хәлдә тәүлектән артык Ладога өстеннән шуыша кызлар отряды. Шул рәвешле блокадага ябылган Ленинградка килеп керәләр. Аларны ач-ялангач шәһәр каршы ала. Шәһәр халкына көненә 125 г, эшчеләргә 250 г блокада ипие бирелә торган көннәр бу. Кызларны ике частька бүлеп, башта танклар, аннан сугыш кораллары җитештерә торган Киров исемендәге заводны сакларга куялар. «Бик хәлсезләндек, ябыктык. Урамда мәетләр аунап ята... Без яши торган җирдә генә траншея. Анда ачтан үлгән кешеләрне олаулап китереп ташлыйлар... Яз җитте. Җирдә ник бер яшел чирәм булсын! Чыккан бер үләнне кыркып ашап баралар. Каргалар, чыпчыклар да юк хәтта...» – дип, күз яшьләренә буылып искә ала ул көннәрне Хәтирә апа.

Могҗиза бит! Авылдан бергә чыгып киткән Сәрби белән юллары аерылмый аларның – кая барсалар да гел бергә! «Татарочкалардан үрнәк алыгыз!» – дияргә ярата командирлары. Юкка гына әйтелгән сүз булмагандыр!

Сугышны кичкәннәр бүгенге тормышның кадерен яхшы белә.



Ленинград блокадасында Хәтирә апа аэростатчылар частенда хезмәт итә. Немец бомбардировщикларының күзләре кызыккан Киров исемендәге заводта иртә-кич кизү торалар. Күктә самолет гүләгән тавыш ишетелүгә, кызлар завод өстендә аэростатлар күтәрергә йөгерә. (Аэростат – эченә водород тутырылган, миналар беркетелгән рослар белән күк йөзен томалап, дошман самолетларына түбән биеклектән очарга комачаулаучы очу аппараты.) Дүртәр километр биеклеккә күтәрелгән аэростатлардан шүрләп, дошман самолеты өстәнрәк очарга тырыша, бомбаларын төбәгән җиргә ташлый алмый узып китә. Төшеп очарга кыюлыгы җиткәннәрен миналарга эләгеп шартлау куркынычы сагалаган. Шарны җиргә төшереп, эчендәге водородны бик еш алмаштырып торырга туры килә кызларга. Ә кышкы суыкларда тимер тросларны ялан куллап тотып тартырга кирәк. Кызларның бияләйләре ертылып, тузып бетә.

Биредә барлыгы 24 татар кызы хезмәт итә. Күбесе рус телен ипи-тозлык та белми. Шуңа аларны, яратып, «Не белмес» отряды дип тә йөртәләр.

«Берсендә, – дип искә ала Хәтирә апа, – төнлә үзебезнең землянка янында винтовка тотып кизү торам. Әллә каян гына дошман самолеты килеп чыкты да бомба яудырырга тотынды. Бөтен җир шартлый! Берсе нәкъ безнең землянка уртасына килеп төште! Дөнья белән хушлашып, күзләремне чытырдатып йомдым. Бер... ике... өч... һаман шартламый! Дүрт... биш... алты... Күзләремне кабат ачып, кызларны уятырга керешәм! Бигрәк тә Сәрби өчен өзгәләнәм. «Сәрби, чык! Зинһар, тизрәк чык, үлсәк бергә үлик!» – дим. Дәррәү йөгерешеп чыктык землянкадан. Снаряд... шартламады! Аннан биш катлы йортның астагы бер бүлмәсен җайлап, үзебезгә тору урыны хәстәрләдек. Ә теге шартламаган снаряд шунда ята бирде...»

Блокада. 872 көнгә сузылып, миллион ярымга якын үлем китергән ачлык, салкын, сусызлык... Ут, ягулык, транспорт юклыктан һәлакәткә дучар ителгән 2 миллионлы шәһәр язмышы... Бөек Ватан сугышы тарихында миллионнар тормышында тирән яралар калдырган вакыйгаларның иң дәһшәтлесеседер ул Ленинград блокадасы. Ул көннәрнең михнәтен Кукмара районы Өлге авылы кызы Хәтирә Салиховага да татырга туры килә. Бу сынау аның язмыш битләренә дә язылган булган, күрәсең. «Башта бар да бик авыр барды, – дип, бүген янәдән ул елларны барлый 97 яшьлек Хәтирә апа. – Аннан шәһәргә юллар ачылды, икмәк керә башлады. Блокададан соң да әле без монда хәрби хезмәтне дәвам иттек. Җиңү хәбәрен үзебезнең частьта ишеттек. Төнге икеләр иде бугай, кемдер йөгереп керде дә «Җиңү!» дип кычкырды. Кочаклашып елашырга тотындык, хәлебез булмаса да, сөенечтән бии башладык. Биегез, җырлагыз, шәһәргә генә чыкмагыз, диде командирлар».

Сәрби белән Хәтирә туган авылларына 1945 елның август аенда гына кайтып керә. Өр-яңа хәрби күлмәк, гимнастерка кигән, бөдрә чәчләрен тузгытып, башларына пилоткаларын кырын салган ике кыз кыр юлы буйлап атлый. Кулларында йөкләре дә бар: унар кило он биреп җибәргәннәр. Сәрбинең апасы агач арба белән каршыларга килгән. Күңелләр көр, җанда горурлык хисе! Сугыштан кайберәүләр ялгыз нигезгә кайтып төшсә, кечкенә энесен күтәргән әнисе Хәтирәне авыл башында шатлык яшьләре белән каршылый. Сугыштан кайткан оннан ипи пешереп, икенче көнне аш уздыралар. Өйдә – хәерчелек. Инде туган илен саклап кайткан Хәтирә туган җирен күтәрергә керешә. Ленинградта бирелгән шинельдән пәлтә тегеп кия, бөдрә чәчләр янәдән яулык астына яшерелә. Бер эштән дә курыкмый ул! Мәктәпкә военрук итеп чакыргач та бара. Аннан соң бик озак еллар Кукмарага йөреп вокзал почтасында эшли. Кичке уеннан кайтканда кияүгә аны урлап алып китәләр. Үзе дә сугыш утында кайнап кайтып, Хәтирәгә булган гыйшык хисенә тугры калган Мөбарәкҗан, безнең урамнан гына әйләнеп килик әле, ди дә сөйгәнен үзләренә алып кереп тә китә. Яшь гаилә тормышы шулай башлана.

Мөбарәкҗанга сугышка киткәнче җәһәннәмгә тиң Суслонгер сынауларын узарга туры килә. Калининград өлкәсендә барган сугышларда яраланып, госпитальләрдә ята. Ике аягы да авыр җәрәхәтләнеп, сугыш беткәнче үк авылга кайта. Аякларында мина кисәкчекләре сиздереп торса да, тракторчылар бригадасына эшкә чыга.

Хәтирә апа белән Мөбарәкҗан абый, бүгенге тормышны оҗмаһка тиңләп, матур картлык көннәрен кичерәләр. 66 ел бергә алар! Кызлары Асия апа белән Әлфия апа: «Әни – командир, әти – солдат безнең!» – дип көлешә. Килешеп яшәү әйбәт ул. Иң мөһиме – исән-сау булсыннар! Безнең өчен тере тарих, чын үрнәк бит алар!



Алдагы рәттә *(уртада)* – Хәтирә апа.



Фотолар [illegible]лә архивыннан

Яңгырашына карап аеручы бардырмы бүген: гармуннар корыч телле дә, җиз дә, хәтта көмеш телле дә була икән. Корыч – каты материал, андый гармунның тавышы да катырак яңгырый. «Татарлар җиз телле гармун ярата. Аның тавышы ягымлырак, моңлырак ишетелә», – дип аңлата оста. Көмеш теллесе – мельхиордан ясалганы. Иң беренче тальянын ясаганда ул әле бер генә уен коралында да уйный белми. Ләкин гармунга тотынгач, күңелендә ниндидер көй уяна да, шул көй аңа гармунчылар гына белгән серне «пышылдый»: бармаклары үзеннән-үзе тиешле нотаны табып, телләр өстендә биешә. Югыйсә ул нота да танымый, уйнарга махсус өйрәнми дә…

УЙНА ӘЛЕ, ТАЛЬЯН!

Тальян ул – татарның юлдашы.

Татар егетләре белән фронтларны кичкән, аларның шатлыкларын-кайгыларын көйгә салып өзгәләнгән.

Барысы да рәсемнән башлана...

Әйе, бу тарих рәсемнән башлана. Дөресрәге, ясалырга тиеш булып та, киндергә төшмәгән картинадан. Башкорт дәүләт педагогика институтының художество һәм графика факультетын тәмамлыйсы егеткә диплом эше итеп тальянда уйнаган бабай сурәтен ясау тапшырыла. Ул, билгеле, әтисен – гомер юлдашы булган тальянын тезләренә куйган Зөфәр агайны ясаячак. Егетнең күз алдына әтисенең чормадагы иске гармуны килә. Яңа идея шул мизгелдә үк ярала: юк, ул рәсем түгел, чын гармунның үзен ясаячак!

Аның остазы – Уфаның танылган гармун ясаучысы Җидеяр ага Мөхәяров. Җидеяр ага үзе дә, әтисе дә виртуоз гармунчылар һәм искиткеч шәп осталар буларак атаклы. Бу борынгы һәм, кызганыч, онытылып баручы һөнәргә дә егет аннан өйрәнә. Янына үзе эзләп барып, минем дә гармун ясарга өйрәнәсем килә, дип кызыксынып, үҗәтләнеп...

Бүгенге көн остасы

Ә без аның үзе белән танышмаганбыз да түгелме?! Айрат Харисов – Башкортстанның Борай районы Кәшкәләү авылында үскән татар егете. Әтиләре Зөфәр абый, әйткәнебезчә, оста гармунчы, ә әниләре Бәһиҗәт апа татар теле һәм әдәбияты укытучысы була. Гаиләдәге алты бала да әниләре һөнәрен сайлап, педагогик белем ала. Безнең героебыз исә бертуган абыйсы – Россиянең атказанган рәссамы Ринат Харисов кебек, рәсем сәнгатен үз итә – рәсем һәм сызым укытучысы булырга әзерләнә.

1989 елны дипломлы яшь белгечне Башкортстанның Дүртөйле районына – Исмаил авылына юллыйлар. Әмма аны эшкә алган музыка мәктәбендә сынлы сәнгать бүлеге юк икән бит! Укытучы абыйлары үзе укучылар туплап, рәсем бүлеге ачып җибәрә. Тальян ясау тәҗрибәсен искә алып, музыка бүлегендәге гармуннарны рәтләүне дә тапшыралар аңа. Телләре бозылган гармуннарның көен таба-таба, уйнарга өйрәнгәнен үзе дә сизми кала Айрат.

Тынма, тальян!

Кулларына бәләкәй генә тальяннар тотып, татар милли киемнәреннән сәхнәгә чыккан 7-8 яшьлек балаларны халык алкышларга күмә. Айрат абыйларының укучылары! Әйе шул, Исмаил музыка мәктәбенең директоры итеп билгеләнгәнче, балалардан гына торган тальянчылар ансамбле дә оештыра ул. Һәр гармунны үзе ясый – бәләкәй бармакларга уйнарга уңайлы итеп, җиңел итеп... Татарның рухы булган тальян гармуннарның онытыла баруына җаны әрнеп тотына ул бу эшкә.

– Тальянны татар гармуны дисәк тә, бүген ул гармуннар үзләре дә, аларда уйный белүчеләр дә бик сирәк инде. Казандагы бертуган Вараксиннар, Гордеевлар, Салих абый Шәйдуллин, Уфадагы Җидеяр осталар турында сагынып сөйләргә генә калды. Тальянда уйнарга кайда гына өйрәтәләр соң? Музыка мәктәпләрендә дә тальян класслары юк, югары уку йортларында да өйрәнелми ул... Ә бит Башкортстанда курайны бик югары дәрәҗәгә күтәрделәр. Курайчылар сәнгать академияләрендә укытыла, – ди Айрат.

Башкортстаннан Казанга күченеп килүенә дә тальян «гаепле». Татарстанга Казан мэриясеннән чакыртып китерәләр аны. Остаханә өчен бүлмә алганчы, шактый вакыт өйдә генә эшләргә дә туры килә.

Миллион сумлык гармун

Иң беренче гармунын остазы Җидеяр агай әнә шул бәягә сатып бирә. Бигрәк кыйммәт дип аптырамагыз, 90 нчы еллар акчасы белән генә миллион сум тора ул. Ә болай, телләренә кадәр җиздән үзе чүкеп ясаган гармуннарына хак куеп, кемгәдер сатып җибәрү бик авыр Айрат өчен.

Бу эштә иң катлаулысы да, иң зур осталык һәм түземлек сорагана да гармунның телләрен ясау икән. Оста аны «тел кагу» ди. Телләр артык калын да, юка да булырга тиеш түгел. Җиз чыбыкны тапап, кыздырып, игәүләп ясала ул. Көй тоемы булу менә шушында кирәк. Телгә чиертеп карап кына да, оста кеше аның әзерлеген билгели. Бүген бу эшне Татарстанда да, Башкортстанда да профессиональ дәрәҗәдә бары тик Айрат Харисов кына башкара. Җидеяр агадан өйрәнеп, остазы Чаллыга күченгәч тә Уфа–Чаллы арасына тузан кундырмый чарлаган һөнәре ул аның.

Заказга ясаган эксклюзив гармуннарга Айрат үзе каккан җиз телләр куя. «Бик ашыгыч булганда яки гармунның бәясе кыйммәт булмасын дисәң, чит илдән кайтартылган корыч телләр дә кулланырга туры килгәли», – ди.

Гармунның корпусы яхшы сыйфатлы каен фанерадан бизәкләп, буяп, лаклап эшләнә. Грифны ясау өчен сәрви агачы кулланыла. Резонатор, басма телләр – юкәдән. Гармун күреге электро-катыргыдан бөгелеп, аңа чәчәкле сатиннан «күлмәк кидерелә» (тукыма ябыштыруны шулай диләр). Күрекнең һәр кабыргасына дермантин ябыштырылып, калай почмаклар беркетелә.

Гармун ясаучыга рәссам да, балта остасы да, тимерче дә, күнче дә һәм гармунчы да булырга туры килә.



Татар гармунының тагын бер үзенчәлеге бар: кыңгыраулы итеп эшләнә ул. Аның өчен Айрат иске телефон аппаратларын җыя икән. «Гармун ул матурлыкны ярата, – ди оста. – Җидеяр аганың да гармуннары бик матур була иде, мин дә аннан отып алган бизәкләрне кулланам. Ул бизәкләрне аның әтисе Касаткин дигән остадан өйрәнгән булган».

Бер гармунны ясап чыгу өчен бер ай вакыт кирәк. Оста өчен иң дулкынландыргыч мизгелләр – гармунда беренче тапкыр уйнап карау. Тугыз ай көткән балаңны беренче тапкыр кулга алуга тиңли ул моны.

Гармун ул – хәтер

Кайчандыр, әле бик кечкенә чагында әтисе аңа гармун сатып алган була. Өске ягына «Казан» дип язылган ул гармун бүгенгегә бер ишарә булгандыр, дип юрый оста.

Тальянда уйнаучылар сирәк дисә дә, төзәтеп бирүен сорап, борынгы гармуннарын алып килүчеләр күп аңа.

– Гармунның иң зур дошманы – дым. Вакытлар узу белән тынын да тотмый башларга мөмкин. Герметиклыгы бозылса, телләрне тибрәтергә тиешле һава тышка чыга, гармунның тавышы бетә. Дөрес сакласаң, гармунның гомере озын аның, ул әллә ничә буынга җитә.

Моннан 10–12 ел элек бер апа тальян гармун китергән иде. Корпусында «1937 елны рәтләнде» дигән язу бар. Ничәнче елгы булгандыр, бик борынгы икәнлеге күренеп тора иде, – дип сөйли оста. – Гармун ул бит хәтер, кемнеңдер төсе. «Әтиемнең төсе иде», – дип алып киләләр дә, рәтләп биреп, уйнап җибәргәч, гармунны кочаклап елыйлар.

Аның үзенең дә иң кадерле, бернинди акчаларга да сатылмас гармуны бар – әтисенең төсе. Мәскәүгә күргәзмәгә баргач, актер Николай Губенко бик үтенеп сатуын сораган булган, ядкарь икәнен белгәч, аңлаган.

Узган ел Татарстан Республикасы Президенты аңа музыка мәктәпләре өчен 100 тальян ясарга заказ биргән иде. Аның унысын Республика көнендә ияләренә тапшырдылар инде. Бер гармунда ун бала гына уйнарга өйрәнсә дә, киләчәктә мең тальянчы үсә дигән сүз бит бу.

Нинди генә шәп, яхшы уен кораллары да безнең өчен тальян моңына җитми. Тальян моңы татар кешесенең генында бит ул. Эх, онытылмасын иде ул моң, яшәтәсе иде аны!

Лилия ГӘРӘЕВА









КУРКУ УЛ – СЫНАУ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Күңелләребезгә кереп оялаган курку хисе дөресме? Ул шулай булырга тиешме?

– Адәм баласы туганда ук шушы хис белән дөньяга килә, шуңа күрә беркайчан да куркудан котылып, арынып булмаячак. Ул безгә кирәк тә. Әгәр күңелендә курку булмаса, кеше ахмаклыклар кыла башлар иде: биеклектән курыкмаса, ул аннан егылып төшәр иде; салкында юешләнүне бернигә санамаса, авырып китәр иде; караңгылыктан өркемәсә, аңа караңгыдан зыян килер иде... Димәк, безне саклар өчен кирәк бу хис.

Ислам динендә, гомумән, нәрсәдән дә булса бөтенләй котылу турында сүз бармый: һәрнәрсәне дөрес итеп куллану турында гына әйтелә. «Бернәрсәдән дә курыкмагыз», – дими ул, шул ук вакытта: «Бөтен әйбердән куркыгыз», – дип тә кисәтми. Динебез нәкъ менә шуны – нәрсәдән куркырга һәм нәрсәдән курыкмаска кирәген өйрәтә безгә. Иманы булмаган кеше исә болар арасына үзе киртә куя алмый: ул аларның барысыннан да курка башлый. Шуның нәтиҗәсендә фобиялар барлыкка килә.

Беренче чиратта без нәрсәләрдән куркырга тиеш?

– Иң беренче чиратта, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләдән куркырга кирәк. Ләкин ул ниндидер куркыныч, ямьсез, коточкыч бер зат булганга түгел, ә аның каршына басып җавап бирәсе булудан, ул безгә йөкләгән вазыйфаны үтәмичә килүдән. Аллаһы Тәгаләнең яратуын, игътибарын, рәхмәтен югалтудан. Кабатлап әйтәм: беренче чиратта Аллаһыдан куркырга кирәк һәм бары тик бер Аллаһыдан.

Аллаһыдан курку безгә нәрсә бирә? Ул безгә шушы дөньяда үзебезне дөрес итеп тотарга ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә – иң кодрәтле, иң көчле зат, бөтен нәрсә дә аннан гына тора. Ул безне ризыкландыручы, гомерне бирүче һәм алучы, балаларны бирүче һәм алучы, бәхет бирүче, бәхетсез итүче... Аллаһыдан курыксаң, әле санап киткән әйберләргә аннан башка беркем зыян китерә алмаганны аңлыйсың. Кеше, мәсәлән, мине кемдер бәхетсез итәр дип тә, хәерчелектән дә, ялгыз калудан, баласызлыктан да курыкмаячак, чөнки бәхет тә, ризык та, насыйп ярлар да, бала да – бар да Аллаһыдан. Болар – җан белән, рухыбыз белән бәйле куркулар. Һәм бу куркулар – иң начары, чөнки алар ахыр чиктә безгә психик зыян китерә.

Яшен яшьнәвеннән, көчле җил исүдән, тиз барган машинадан куркырга мөмкин, болар нормаль куркулар санала. Ә нормаль булмаганына, рухи куркудан кала, мәсәлән, дошманнан курку керә. (Дошман синең кебек үк кеше, нигә аңардан куркырга?) Яки гаделлекне яклаудан, авырып китүдән курку. Ләкин авырудан курку шулай ук икегә бүленә. Авырудан куркып, башка чирлеләр белән аралашмау – саклану чарасы һәм бу нормаль күренеш. Яки үзең авырып, башкаларга ияртүдән куркып, алар янына бармау – шулай ук нормаль күренеш. Ләкин: «Авырып китүем бар», дип паникага бирелү, кешеләрдән качып, идән астына төшеп утыру, каядыр гомерлеккә тауларга китү – монысы инде фобия – тәкъдиргә каршы килә торган курку була. Кеше, киселермен дип куркып, кулына пычак алмый, килеп чыкмас дип, беркайчан бизнес башламый, үсмәс дип, берни утыртмый, чәчми... «Көчегездән килгәнне эшләгез, ә нәтиҗәсе – миннән», – ди Аллаһы Тәгалә бу очракта.

Куркуга ничек бирелмәскә соң?

– Беренчедән, аны җиңәргә безгә тәкъдиргә ышану ярдәм итә. Икенчедән, куркуга бирелмәс өчен, аны дөрес итеп аерырга өйрәнергә кирәк, ә моңа дини яктан белемебезне арттырып, хәдисләр, аятьләр аша гына ирешеп була. Кеше табигый әйберләрдән курка икән, моңа борчылырга кирәкми. Ә инде ул үлемнән, хәерчелектән, ялгызлыктан, ягъни билгесезлектән уттан курыккандай курка башлый икән, монысы инде зыянлы. Димәк, аның иманында зәгыйфьлек бар, ул Аллаһыга, тәкъдиргә ышанмый!

Куркуларга шайтан да сәбәпче булырга мөмкин. Гадәттә, ул безне шул куркулар белән азаплый. Кеше бик каты курыккан вакытта эмоциональ яктан тотрыксызга әйләнә. Менә шул вакытта аның эченә шайтан керергә мөмкин дә. Курку аша кешеләрнең башлары киткән, акыллары зәгыйфьләнгән очраклар бар. Бу да – шайтан галәмәте. Әгәр шундый куркуларга бик бирелгән кеше бар икән, аларны өшкереп дәваларга кирәк.

Куркудан котылуның юлы, алда әйтелгәнчә, ике генә. Беренчесе – иман, Аллаһыга ышану, гыйлем аркылы. Икенче юл – өшкереп. Куркудан арынырга сөйләшү дә ярдәм итә, монысы психологлар, туганнар, әти-әни эше.

Кирәкмәгән куркуларның күбесе безгә балачакта кереп кала. Шуңа күрә баланы кечкенәдән үк дөрес итеп тәрбияләргә кирәк. Җен-пәриләр, аждаһаубырлар турында төрле әкиятләр, булмаган нәрсәләр сөйләп, аның күңеленә кирәкмәгән курку кертеп калдырырга мөмкин. Шуңа күрә һәрнәрсәне дөрес итеп аңлатырга кирәк – бала барыбер нәрсәдәндер, кемнәндер куркырга да тиеш. Беркемнән – әти-әнисеннән, олылардан курыкмаган баланың тәртибе дә, әдәбе дә булмаячак. Аллаһыдан, кешеләрдән куркуга оялу мәгънәсе дә салынган бит. Димәк, балага дөрес әйберләрдән куркуны сеңдерү кирәк.

Коръәни-Кәримдә: «Без сезне курку белән сынаячакбыз», диелә. Курку, димәк – шул ук сынау. Кеше үзен мондый вакытта ничек тотар? Ул үзен кулга ала алырмы, әллә паникага бирелерме? Аллаһы Тәгалә биргән гыйлемне, акылын эшкә җигәрме, әллә хисләренә бирелеп, аффект хәленә төшәрме? Ә курку кешене шул халәткә дә кертә... Андый чакта, иң мөһиме – барысын да Аллаһы Тәгаләгә, аның иркенә тапшыру.



...Күпмедер микъдарда вәгъдәмне үтәү йөзеннән, күренекле бу шәхесләрнең истәлекләренә, хатирәләренә нигезләнгән язмамны тәкъдим итәргә булдым. Җиңү көннәрендә фронтовикларның хатирәләрен укып уйлану аларга дога булып ирешер дигән өметтә мин.

Әхтәм ЗАРИПОВ

ХУҖАБИКӘ

Мин ул вакытта телевидение режиссеры, исемем телефильмнарда сценарийлар авторы буларак еш яңгырый башлаган чак иде.

Бер көнне эштән кайтуыма хатыным Җәмилә: «Бикә апа шалтыратты», – дигәч, югалып калдым. Театрда эшләгәндә Бикә апаның актерга шалтыратуы ЧП министры шалтыратудан да хәтәррәк яңгыраса, хәзер инде мин – артист, Бикә апа труппа мөдире түгел, нигә икән дип аптырап калдым.

Телевизион тапшыру карап, берәр гаеп тапканмы әллә?

«Эштән кайтуга әйт: срочно безгә килсен, килә алмаса, шалтыратсын!» дип әйткән ди.

...Шалтыратып, Бикә апаның сүзен ишеткәч, чак көлеп җибәрмәдем.

– Сәет абыең яңа пьесасын язып бетерде. Миңа ошамады. Шул бәхәстә кем хаклы булуны ачыкларга сине чакырабыз.

– Андый бәхәстә мин хөкемдар була алмам, Бикә апа, башка судья чакырыгыз!

– Сәет абыең сине чакыр, диде. Үзең беләсең: мин аннан уза алмыйм. Ул миннән узмый.

...Бикә апа, гадәтенчә, мул итеп өстәл әзерләгән, Сәет абый күзлеген кигән, кульязмаларын өстәлгә ачып куйган, көтә. Пьесаны укырга тотындым. Үзгәрткән, төзәткән урыннары бик күп иде, авырлык белән булса да укып чыктым. Тынлык урнашты. Мин Сәет абыйның республика театрларында уңыш белән барган әсәрләрен санап, бу пьесасы буенча телевидениедә бәхәс оештырырга кирәк, дигән «дежур» тәкъдим ясадым. Бикә апа ризалашса да, Сәет абый: «Мин кибеткә арткы ишектән керергә яратмыйм», – дип читкә китте дә миңа карап: «Эшләргә кирәк!» – диде.

– Тамашачыны кызыксындырыр өчен жанры да, эчтәлеге дә хакыйкатькә төрелгән булырга тиеш. Бары шул. Мин үзем турындагысын һич яшерми әйтә алам. Эфирда гына түгел – любой җирдә, турыдантуры, – диде Сәет абый.

– Кемгә кирәк соң синең дөреслегең? – ди Бикә апа.

– Минем кебек йөзләргә, меңнәргә кирәк, Бикә. Ил, дөнья алкышлар белән тула. Гадәттә аларны арбадан төшереп калдырырга омтылалар. Ә менә син мине арбадан чанага күчереп, яңа җан өрдең. Миннән хәзерге минне ясадың. Бу сизелми узарга тиеш түгел!..

– Бу бит, минемчә, бары тик кешелек бурычымны үтәү генә иде, Сәет, купыртма.

– Дөнья бурычлылар белән тулы, Бикә, тыйнаклыгың урынсыз. Син кеше иттең мине. Пьеса шул хакта.

...Алар бәхәсенә ноктаны мин куярга тиеш идем. Саубуллашыр алдыннан телевидениедә «Җомга көн кич белән»не сезнең гаилә тарихына багышларбыз, дип, тапшыруда кулланырга ярардай биографик-тарихи материаллар әзерләүләрен сорагач, бераз сөйләштек тә хушлаштык. Сәет абый кирәкле материалларны җыеп китереп тә бирде.

Бикә нинди вәхшәтләрне генә кичерми дә, нинди генә кыенлыкларга түзми.



– Монда санинструктор Шакирова Бикәнең холкын-фигыльләрен ача торган төрле материаллар. Башта шулар белән танышып чык. Ә менә монда без катнашкан төрле спектакльгә рецензияләр тупламасы, Бикә апаңның хатирәләре, истәлек язмалары да шунда, – диде.

Әмма түрәләремне тапшыруның кирәклегенә ышандыра алмадым... «Сүз орденлы фронтовичканың көрәшче булып яшәве турында барачак», – дигәнем дә ярдәм итмәде, вәгъдәм үтәлмәде, тапшыру булмады. Шулай зур бурычлы булып калдым. Башта Сәет абый китте, аннары, трамвайга тапталып, Бикә апа кинәт мәрхүм булды... Инде менә ничә елдан соң, вөҗданым уянып, бу онытылмас шәхесләр турында язма сүз әйтү кирәклеге тынычлыгымны алды, кулыма каләм тоттырды...

Теге чакта, чакыру белән баргач, блокнотымны чыгарып, кулыма каләм тотуга телемә килгән беренче сорау болайрак иде:

– Бикә апа, синең тулы исемең Сөембикәме, Гөлбикәме, Миңлебикәме дигәч, җавапны Сәет абый бирде: «Бу исемнәрнең һәркайсына лаек булса да, Бикә Бикә булып яшәде, шулай яшәр: чөнки Бикә – хуҗа дигәнне аңлата ул. Нәкъ Бикәнең холык-фигылен ачучы исем. Ул сүзенә дә хуҗа, эшләгән эшләренә дә, хыялларына, планнарына да, балаларына, иренә, ягъни миңа да хуҗа. Димәк, Хуҗабикә ул! Ул булмаса – минем әсәрләрем дә булмас иде. Язмаңа «Хуҗабикә кыйссасы» дип куй».

...Унбише дә тулмаган кыз сәхнәгә булган мәхәббәтенә буйсынып, атабабасы күрмәгән һөнәргә өйрәнер өчен училищеда укый башлый. Күренекле артистлар, режиссерлар алып барган дәресләрдән кыз драма артисткасы һөнәрен сайлап ялгышмаганлыгына инана. Инде алар театр сәхнәсендә дә күренгәлиләр, үз таныш-белешләре аларга беренче чәчәк бәйләмнәрен дә биргәли. Тамашачы мөнәсәбәтенең ни икәнен тирәннән тойган бәхетле мизгелләр кичерә башлый алар. Тик кинәт... Әгәр сугыш башланмаса, алар, мөгаен, олы сәнгатьнең ни икәненә тирәннән төшенеп кайткан булырлар иде.

Безнең хатын-кызларның күпчелеге тылдагы авырлыкларны яхшы белә. Әмма кайберәүләре, ир-егетләр белән бер сафка басып, сугыш кырына ук китеп баралар. Бикә Шакирова – шундыйлардан.

...Кыр госпиталендә ашыгыч операция бара. Бикә – хирургия сестрасы. Яшь-яшь офицерның аягына операция ясыйлар. Хирург: «Иң мөһиме – канын саклау, шуңа ирешсәк...» – дип сөйләнә-сөйләнә эшкә тотына.

Бикәгә, сиңа беренче операцияне күрү авыр булыр, бу якка борылма, менә шул аяктан, селкетмичә, тотып кына торырсың, дип киңәш бирәләр. Кыз күзләрен чытырдатып йома. Күпме вакыт үткәнен дә абайламый. Бервакыт бүлмәдә нindидер үзгәреш барлыгын сизеп, як-ягына караса, егылып китүдән чак тыела. Хирург та, ярдәмчеләре дә чыгып баралар. Яралы офицерны да көпчәкле ятакка күчергәннәр. Бикә кулында аның дошман пулясы чәрдәкләгән сыңар аягы гына торып калган...

Бу күренеш Бикәне тәмам чарасыз итә. Ул үзен үзе белештермичә, аулак якка чаба, үксеп еларга тотына. Бераздан исә аңа өлкән сестраның шактый кискен шелтәсен ишетергә туры килә.

– Без сугышка үз ихтыярыбыз белән килгән кызлар, – ди ул. – Барыбыз да синең кебек елак булсак, фронтка бездән ни файда? Хәзер үк сөрт күз яшьләреңне! Баш врач күрмәсен...

Бераздан ул врачның таләбен дә, иптәшләренең үтенечен дә ярты сүздән аңлаучы һәм «ялт» иттереп үтәүче бик өлгер шәфкать туташына

Сугыш кырыннан ул алып чыккан яралылар санын исә берничек чамалап булмас...



■ Орденлы фронтовичка Бикә Шакирова тыныч тормышта да көрәшче булып кала.

Фотолар: гаилә архивыннан.

әйләнә. Операцияләрнең күбесе яралы сугышчыларга кан бирүне сорый. Мондый очракларда да: «Бикә! Группасы – синең канныкы, әзер тор!» – дигән сүзне генә ишетеп ала ул. Фронт юлларында Бикә Шакирова алты литр (!) канын тапшыра.

Верховный Башкомандующий имзасы куелган Мактау грамоталарының берсендә мондый юллар игътибарга лаек: «...бер бәрелештә, үз плащ-палаткасына салып, сугыш кырыннан егерме җиде (!) яралы сугышчыны алып чыгуы өчен тирән рәхмәт белдерелә».

Нибары бер генә көндәге бәрелештә Бикә әнә нинди тәвәккәллек күрсәткән: егерме җиде кешене үлем тырнагыннан коткарган, егерме җиде тапкыр җанын үлемгә каршы куйган һәм үлемне җиңеп чыккан! Чираттагы бер бомбежкадан соң сугыш кырыннан плащ-палаткага салып медпунктка алып барганда үлем хәлендәге сугышчы: «Өстерәмә мине, туташ, мин барыбер үләсе, калдыр», – ди. Әмма Бикә аны ташламый, хирургка илтеп тапшыра: «Зинһар өчен, коткарыгыз, ул минем милләттәш булса кирәк», – ди.

Чынында исә ул азәрбайҗан егете була. Катлаулы операцияләрдән соң, үз канын биреп, солдатның терелүенә өметләнгән Бикә иптәш кызы Туешовага:

– Терелсә, бу түзем-сабыр егеткә кияүгә чыгар идем, – ди. Яралы күзен ача, сүзен генә әйтә алмый.

...Күкрәгенә орден-медальләр таккан старшина санинструктор Бикә Шакирова Җиңү көнен Чехословакиядә каршылый. Шунда ул үзе коткарып калган азәрбайҗан егетен очрата. Егет аны тавышыннан танып эндәшә: «Туташ, син миңа үз каныңны биреп, үлемнән алып калдың. Иптәш кызыңа: «Терелсә, мин бу түзем егеткә кияүгә чыгар идем, дидең. Ул чак сүз әйтерлек көчем булмаса да, ишеткәнем хәтеремдә... Сүзеңдә торасыңа өметләнеп, сине эзләдем, таптым...»

...Алар кушылалар. 1946 елда Бикә кыз бала таба. Аңа Хәдичә дигән исем бирәләр. Кызганыч, кыз башка солдатны «әти» дип үсәргә дучар була. Бикә болар турында газетага да язып, күңеленә тынычлык эзли. Әмма газета редакторы мәкаләне оптимистик юнәлешкә үзгәртүне сорый. «Егет үлмәсен дә, аерылышмасыннар да», – ди. Бикә Шакирова үзгәрә яисә үзгәртә торган шәхесме? Аңа кайда да дөреслек кадерле! Мәкалә басылмый, кульъязма авторның архивында кала.

Истәлекләренең берсендә: «Берберебезгә тупас мөгамәләдә булуыбызга йөрәгем әрни», – дип яза Бикә апа. «Ни өчен без елдан-ел усаллана барабыз? Ни өчен әле без үзебезнең элеккеге сафлыгыбызны, сабырлыгыбызны, әдәпле, никахлы булуыбызны югалта барабыз? Кибетләрдә товарлар булмаганга дисезме? Сугыш вакытында, сугыштан соңгы авыр елларда бар идеме соң алар? Көн-төн эшләп тә бер тиен эш хакы алмаган вакытларда да без бит бер-беребезгә ташланмадык. Кичтән чират алып номерларыбызны куллрыбызга яздырып, иртән ипи кибете ачылганчы төн буе 400 грамм ипи өчен торганда да картларны, балалы хатыннарны чиратсыз җибәрә идек. Ә хәзер?.. Ачмы, ялангачмы? Нигә соң без булганына шөкер итеп яши белмибез? Элек, без яшь вакытта, трамвайларның алгы ишегеннән керүне белми идек. Белмәгәннәргә трамвай йөртүчеләр: «Яшьләр, арткы ишектән керегез, олыларга урын бирегез», – дип әйтәләр иде. Хәзер дә шул матур кагыйдәләрне эшләп булмыймыни соң?

«Социалистик Татарстан» газетасында Таҗетдиновның «Йөрәк җылыбызны тойсыннар» мәкаләсе кулыма каләм алырга мәҗбүр итте. Дөрес, хөкүмәтебез безгә карата кайгыртучанлык күрсәтә. Ләкин тормышта тоябызмы соң без «йөрәк җылысын?»

Бервакытны чистартырга бирәсе әйберләремне сумкага тудырдым да киттем. Килеп керсәм, чират зур, инде башка вакытны килермен дип кире борылганда, «Участникам ВОВ без очереди» дигән язуны күрдем дә, кабат килеп йөргәнче файдаланып карыйм әле дип, удостоверениемне күрсәтеп: «Рөхсәт итегез, зинһар», – дип чираттагыларга мөрәҗәгать иттем. Йә Алла, исемә төшсә, хәзер дә йөрәгем әрни. Шул вакыт чираттагылардан берсе: «Әстәгъфирулла, монда да АЛАР!» – диде. Икенчесе: «Кайда гына юк АЛАР!» – дип куйды. Башкалары әләктереп алды да киттеләр... Аларын хәтерләмим, шундагы бер ир кеше, рәхмәт төшкере, кулымдагы сумканы алып, әйберләрен кабул итүчегә биргәндә, минем адресны һәм 6 сум 40 тиен акча сорый. Мин стенага терәлгән хәлемдә, калтыранып, адресымны әйтеп акчамны бирдем дә, терәлгән урынымнан кузгала алмыйча чираттагыларның һәммәсен күздән йөртеп чыктым. Йә Раббым... бәлки, боларның кайсының булса да атасын, бабасын, баласын, агасын сугыш кырыннан сөйрәп чыгып, беренче ярдәм күрсәтеп, аңа гомер бүләк иткәнмендер. Шуның өчен миңа «рәхмәт» яудыраларрмы?..

Шушы вакыйгадан соң ул удостовереониене үзем белән йөртмәс

булдым. Шулай да читтән күзәтеп йөрим. Берчак кибеттә бик яхшы алма саталар. Чират зур. Бер сугыш ветераны удостоверениесен күрсәтеп, ике килограмм алма сорады. Сатучы аңа: «Чираттагылардан сорагыз», – диде. Ә чираттагыларның якыннары барысы да сугыш кырында үлеп калган икән! «Нигә әле ул исән калган?» – дип шаулашалар. Әле без исән калганыбыз өчен дә гаепле икәнбез!..

Дөрес, без ветераннар арасында да төрлебез бар: чиратта биш-алты кеше булганда да, йә булмаса сатыла торган әйбер бетеп килгәндә сәгатьләр буе чират торучылар җитәме-юкмы дип борчылып торганда, шулар алдыннан бер ветеран килеп актыкны алып китә. Бу хәлгә кемнең ачуы килмәсен? Андыйлар анда да җылы урыннарга интендант булып урнашып, Германиядән вагон-вагон трофей җибәреп, орденнар белән кайттылар. Ә чын сугышның эченнән гарип булып, бер медаль дә алмыйча кайтучыларны «тегеләр» белән тигезләп, шул ук удостоверениене тоттырдылар. Тигезлекме бу?

Рәнҗетмәгез без – ветераннарны. Мин сугыш ветераннарын гына әйтмим. Сугышта булмаганнар да сугышның ачысын күп татыды. Ничә ел буена төзәлеп бетмәгән яраларыбызга тоз салмыйк!»

«Язмыштан узмыш юк», диләр. Язмышымдагы төп вакыйгага күчәм. Ул минем язмышым да, канатымның сыңары да. Канат булса – парлы гына була. Сыңар канатлы кош юк дөньяда. Сәет белән без очар кошлар идек. (Сәет абыйның вафатыннан соң язылган истәлегеннән – *авт.*)

Без Сәет белән 47 нче елны, сугыштан соң иң авыр елларның җәендә таныштык. Мин Мамадыш театры белән гастрольдә, авылдан авылга үгез җигелгән арбаларда, 1 яшьлек бала белән, арыш башакларын уып ашап, ашардай үләннәр җыеп, ярым ач, ялангач йөргәндә безгә Казаннан Сәет Шәкүров дигән артист килеп кушылды. Ул көнне колхоздан бераз он биргәннәр иде. Шуны стаканлап бүләбез, өчәр стакан тиде. Шунда мин: «Балага да өлеш чыгарсагыз иде», – дип сорадым. Бер артистыбыз: «Минем өчен чыгып уйнасын, аннан өлеш алыр», – диде. Сәет бу хәлләрне күзәтеп торып: «Минем өлешемне балага бирегез», – ди. «Син кем соң әле монда, килмәс борын өлеш алырлык», – дип җавап бирә теге артистыбыз. Сәет дәшмичә чыгып китә. Озак та үтми, өч килограмм он күтәреп фатирыма килеп керә. Ул вакытта өч килограмм он... Клубтагы сүзләрдән соң бөтен тормышыма, утлы сугыш кырларыннан исән кайтуыма ләгънәт укып утырганда Сәет он күтәреп килеп керә... Ул минуттагы кичерешләрне язып-сөйләп аңлатуы авыр... Бала, мәммәм, дип елый, ә мин, белмим, ачы язмыштанмы, әллә сөенечтәнме үксеп еларга тотындым. Ә ул баланы кулына алып тынычландырды да: «Ярар, тынычлан, бала да ач, минем дә ашыйсым килә, умач булса да әптәрлә», – диде. Менә шулай булды безнең танышу. Шуннан ул балага азык тапкалап, ешрак килеп йөри башлады. Бала аңа ияләште, хәтта «әттә», дия башлады, өйрәткәндер, күрәсең. Мин дә ул килмәсә, юксына башладым. Ә бер көн әйтә: «Бикә, син матур, үзеңә ир табарсың, балага хәзер үк ата кирәк», – ди. Шул авыр елларда, ирләргә кытлык заманда шундый мәһабәт кеше алам дип торганда, ничек инде риза булмыйсың, ди. Кавыштык.

Әйе, төрле хәлләр булды безнең. Шундый авыр вакытларда Ходай Тәгалә әйткәндер, «түз, сабыр ит, олыгайган көнеңдә рәхәт күрерсең», дип. Олыгая башлагач, ул чын мәгънәсендә минем алтын баганама әверелде.

Сәет нечкә күңелле булса да, рухи яктан көчле, максатына ирешә торган тынгысыз, хыялый кеше. Тормышка, табигать матурлыгына соклана торган илаһи зат. Ул һаман киләчәккә, тормышыбызда кайчан да булса кискен үзгәреш булачагына өмет белән яшәде. Аның соңгы иҗат эше «Артист» дигән повесть. Ул аны озак еллар дәвамында бик яратып, эчке кичерешләргә бирелеп язды. Инде бөтен кыенлыкларны үтеп, менә-менә дөньяга чыгачагына сөенеп кайтып: «Шул китабымны кулыма алсам, үлсәм дә үкенмәс идем», – диде. Күрә алмады... Бездә гаҗәеп бер гадәт бар. Кеше теге дөньяга киткәч кенә аның иҗатына бәя биреп, матур сүзләр белән мактыйлар. Әгәр шул мактау сүзләренең чиреге генә үзенә әйтелгән булса да, ул шуңа куанып, тагын да әллә ниләр иҗат иткән булыр иде кебек...

Безнең 42 ел яшәү дәверендә язучы буларак та, ир буларак та оныта алмаслык гыйбрәтле, үкенечле, куанычлы мизгелләр бик күп.

Сугыштан соң иң авыр елларда кавыштык. «Барлык сөйдерә, юклык көйдерә», дип юкка әйтмәгәннәр. Төрле вакытлар булды. Ләкин шул авыр елларда да киләчәккә өметебез зур иде, шул өмет гаиләбезне саклап калды.

Һәрвакыт бер-беребезгә «әнисе», «әтисе» дип дәшә идек. Хәтта бер авылда фатир хуҗасы миңа «әнисе» дип дәште. Ул исемемне Әнисә дип уйлаган. Әгәр ирең сиңа «әнисе» дип дәшә икән, ул инде сине тупас сүзләр белән мыскыл итә алмый. «Әтисе» – ул газиз балаларыңның әтисе, ул синең юатучың, яклаучың».

...Язмамның ахырында Ватан сугышының җанлы истәлеге Бикә апаның кызы Хәдичәнең язмышын кыскача әйтеп узмасам, кыйссабыз китек чыгар...

...Хәдичә Бикә апаның да, Сәет абыйның да иркә кызы булып үсә. Институтта укып, югары белемле математика-физика мөгаллимәсе була. Хәзерге көндә балалары шатлыгы белән куанып, лаеклы ялда. Мәрхүм әнисен дә, әтиләрен дә хөрмәт белән искә алып, оныклары укыр өчен хатирәләр яза. Бу кыйсса өчен фотоларны Бикә апаның Ислам исемле оныгы китереп бирде. Шулай яши Бикә Шакирова – «Хуҗабикә» балалары, Бикә апаны күреп белгәннәрнең хатирәләрендә. Аның исеме Бөек җиңүчеләр исемлегендә мәңгелеккә теркәлгән. Ул чын солдат, үрнәк шәхес иде.

Шагыйрь, тәрҗемәче, язучы... Марс Шабаев турында шулай әйтәсе килә. Ул «Татарстан» радиосында, «Яшь ленинчы», «Азат хатын»,«Чаян» кебек басмаларда, Татарстан китап нәшриятында эшли. Иҗатыннан яктылык, ихласлык, зәвык бөркелә. (Язучы дусларын көймәдә Идел утрауларына алып китүче, колач салып йөзәргә, балык тотарга яратучы чып-чын табигать баласы бит ул!) Ә инде «Салда сәяхәт» повестен укып, романтик, сәях җанлы язучының күңел дөньясына сәяхәт кылган кебек буласың. Туган як табигатенең шигъри гүзәллеген ничек матур ача! Иҗатташ дуслары Мирсәет Яруллин, Габделхәй Сабитов, Мәсгут Имашев, Наил Нуретдиновлар белән Ык елгасы буйлап салда сәяхәт итүләре никадәр маҗаралы, кызык тасвирланган! (Үзе дә Ык ягыннан бит: Минзәләнең Югары Тәкермәнендә туган, Минзәләдә педучилищеда укыган.) Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев репертуарында яңгыраган «Их, Мөслим, инде нишлим! / Сагынырмын ич мин...» җыры да шул сәяхәттә туа (Мирсәет Яруллин көе). Аның поэмалары аерым бер осталык, җылылык белән иҗат ителгән. Публицистика да, фәлсәфи лирика да бар аларда.

Марс ШАБАЕВ

DIE TATARISCHE FRAU*

(Табибә Зәйнәп Бәхтияровага)

Госпиталь.
Госпиталь каршында
Тынлыкка күмелгән
бакча бар.
Ишетелми балалар тавышы,
Зурлар да кермиләр,
Качалар.
Бакча бар...
Юк бакча!
Алданма –
Бакча юк,
Зур гына чокыр бар.
Ажгырып килгән дә
Кара кош
Кешеләр йөргән чукырга
Бакчага,
Таң кебек гөлләргә,
Кан кебек гөлләргә, –
Һәм тагын кемнәргә? –
Тамызган кап-кара
тамчысын.
Әйткәндер ул гыйфрит:
– Үлемнең
Ачысын
Гөлләр дә татысын!
Кара кош –
Тәреле бомбовоз.
Тамчысы –
Фугаслы бомбасы.
Бомбадан бакчамы
сау калсын?
Бомбадан чокырмы
калмасын?!
Чокыр бар – бакча юк...
Гөлләр юк...
Толлар бар – уллар юк,
ирләр юк...
Сугыш бар, үлем бар,
Үлемсез көннәр юк.
Түземлек бирегез –
Кемнәр нык?
Кайгылы хәбәр бар –
ирең юк.
Кайгылы хәбәр бар –
улың юк.
Нигә соң кайгыга үлем юк?
Нигә соң үлемгә үлем юк?
Йолкынган, ителгән,
сытылган
Гөлләргә кем сулыш
өрер соң?
Төзәлмәс җәрәхәт сызылган
Күңелгә кайчан җан
керер соң?
Таш та таш – күңел дә...
Ул кайчан, әйтегез,
Ул кайчан эрер соң?..
Ир дә юк, ул да юк,
ә син бар.
Син – кеше:
Сагын да,
Юксын да,
Тик сынма.
Син – кеше,
Гөл түгел: түз, сынма!
Син – табибә,
Хирург.
Кулларың
Илеңнең яралы улларын
Аякка бастыра яңадан.
Көрәшнең бик авыр
булганын
Онытма, онытма, онытма!
Бар үчне, бар көчне,
бар эшне –
Фронтка, фронтка, фронтка!
Госпиталь йокыда.
Төн эри...
Тәрәзә буенда кем йөри?
Төн эри...
Ә күңел – сынган гөл,
Сулган гөл, туңган гөл,
Калганын үзең бел...
Төн эри... Аллана...
Ә хирург уйлана.
Төн эри,
Ә күңел бозташмы?
Төнмени агарткан бу башны?
Карачы офыкка –
Аллана, нурлана!
Тол хатын, тол ана,
Моңланма:
Төн артыннан көннәр килер,
Күңелләргә нурлар керер,
Бозташ булып каткан кайгы
Эрер, эрер...
Син – кеше,
Гөл түгел: түз, сынма.
Ирең юк, улың юк –
Илең бар.
Илең бит кол түгел.
Илең бар, җирең бар,
Алланган таң төсле
җиңү бар!
Госпиталь.
Госпиталь эчендә, –
Хирург,
Колак сал,
Ишет син, –
Кемнәр ул ыңгыраша,
Сызлана?
Якты көн,
Юл куйдың ничек син?
Ничек син
Кояшың яндырып,
Оялмый тудың соң дөньяга?!
Госпиталь эчендә –
Немецлар...
Аларның ярасын син яма!
Син мине тилмертмә,
Кирәкми.
Якты көн,
Тыңла син йөрәкне.
Типми ул,
Үкси ул сулкылдап –
Кайгы бит яхшыга өйрәтми...
Кайгы һәм хурлану елата,
Үксетә йөрәкне –
Мескенне.
Кулларда скальпель,
Әйтче, көн:
Яргалыйк,
Телгәлик без кемне?
Яргалыйк немецны,
Дәвалыйк.
Шәп итеп дәвалыйк,

Ха-ха-ха!..
Хирург күзендә ачы яшь,
Яшенә яшеренгән каһкаһә...
Күз яше – күз яше инде ул,
Ә приказ – солдатка
ул закон.
Тол ана,
Бүген бит син – солдат.
Приказны үтәми, боза кем –
Аңарга трибунал...
Син – солдат.
Аңлыйсың үзең дә,
аңлыйсың.
Тик менә...
Тик менә немецны,
Фашистны дәвалый
алмыйсың.
Кулларың калтырый, хирург,
Скальпель тотарга ашыкма.
Өстәлең өстендә җан бирсә,
Берни юк дөмеккән
фашистка.
Ә сиңа:
«Әсирне үтергән...» –
Дип шомлы бәлане ягарлар.
Ашыкма, хирург,
Ашыкма –
Аз гына төзәлсен яралар...
Төзәлсен аз гына, ярыймы?
Әй ана, күңелең яралы...
Госпиталь.
Әсирләр...
Фашистлар...
Шулар бит иреңне,
Балаңны...
Тревога! Тревога!!
Сирена!!!
Хирург,
Кач тизрәк,
Кач инде!
Юк, качмый,
Йөрәге боера:
Тәрәзне ач тизрәк, ач инде –
Күрсеннәр утларны,
Килсеннәр.
Бомбага тотсыннар,
Кырсыннар.
Фашистны
фашистлар кыйнасын,
Госпиталь көл булсын,
Корсын ла!
Сирена...
Сирена чыелдый.
Хирург тәрәзгә атыла!
Куллары пәрдәне
Төшерә...
Йөрәге хаклысын хаклы да,
Куллары тагын да хаклырак,
Хирург хатынның куллары...
Бу солдат-ананың хисләрен,
Дойчланд-фатерланд уллары,
Аңларсыз микән сез,
Юк микән?
Анысы әлегә караңгы...
Дөньяда зур сугыш бара әле,
Әнә бит ыңгыраша яралы.
Гансмы, Фрицмы –
Бер немец –
Ыңгыраша,
Саташа:
– О, муттер**...
Муттерың бардыр да бит,
бәлки,
Вөҗданың бармы соң?
Әй, юктыр!
Ятасың син менә бирелә,
Терелеп чыкканчы ятарсың.
Яңадан сугышка юлыксаң,
Кемгә син –
Безгәме атарсың?
Муттерың еракта,
Ялварма.
Күзеңне ач –
Каршыңда кем тора?
Чал чәчле,
Сагышлы ана ич.
Аңарга баш ор да
Син сора:
– Улыңны үтерде кем? –
диген.
– Ireңне үтерде кем? –
диген.
– Иленә дәһшәтне,
вәхшәтне,
Кайгыны китерде кем? –
диген.
Ә немец кулларын күтәрә,
Төшендә пленга бирелә.
«Хайль!»ны
оныткан инде ул,
Сукалый,
Пупалый кирегә:
– Русиш гут***...
Кароший товариш...
Терелгәч
әйтерсең микән син:
– Фрау, – дип, –
Ду зер гут татариш?..***
Әйтерме икән ул,
Юк микән?
Анысы әлегә билгесез.
Әлегә син аны дәвала...
Дәвалау, ай, кыен,
Белмисез!
Хәтерли алырмы хирург:
Кай минут,
Кай сәгать,
Кай көнне
Нинди хис,
Нинди көч эретте
Күңелдә утырган кайгыны?
Тик солдат-ананың йөрәге
Аңлады:
Немец та күптөрле.
Гансның,
Фрицның әнисен
Елатты,
Күз яшен түктерде
Бер кайгы,
Бер хәсрәт,
Бер бәла...
Мул чәчте бу сугыш үлемне
Һәркемгә – сезгә дә,
безгә дә...
Әйтегез, җитмәде түгелме?
Гансның, Фрицның муттеры,
Җирдәге аналар, хатыннар
Күз яшен сөртсеннәр –
Аларның хакы бар,
хакы бар, хакы бар!
Хирург Гансны дәвалый,
Ганста ярадан гангрена.
Капут бит аягы!
Ничек соң
Ул кайтыр муттеры кырына?
Хирург Фрицны дәвалый,
Фрицның куллары өзелгән.
Ә Фриц – музыкант.
Кулларсыз ул нишләр?
Сорагыз үзеннән...
Хирург Карлны, Вернерны,
Мюллерны, Паульны...
Дәвалый.
Бүгенгә әсирләр,
Иртәгә
Ничек соң тормышның
дәвамы?
Сугыш бит җан бирә
әкренләп...
Сез менә терелеп чыгарсыз.
Биш елдан, ун елдан
Кайсыгыз кай җирдә
Нинди җыр җырларсыз?
«...Дер велт фор
дем гроссен криг...»мы****,
Әллә соң башкамы? Яңамы?
Килмәсме Дойчланд өстенә
Өр-яңа Гитлерлар заманы?
Ул көннәр актылар еракка,
Еллар да чиратлап йөгерде...
Кырык дүрт –
Алтмыш дүрт.
Ике ара
Аз түгел,
Күп түгел –
Егерме!
Хирург һаман да сугыша,
Үлемне якалый кич-иртән.
Ул – солдат
Бу тыныч чорда да,
Ә менә Ганслар кем икән?..
Ганстан хат килә, Фрицтан,
Хат килә Карлдан,
Паульдан...
«...О, фрау!
Исәнме-саумы син?
Син кайсы шәһәрдә,
авылда?..»
Ганслар, Фрицлар, Паульлар
Хезмәттә солдатлар
икән бит.
Татариш фрауның куллары
Иң нечкә кылларга
тигән бит.
Язалар немецлар:
«...Син, Фрау,
Күңелне дәвалап җибәрдең.
Килеп кит бу якка.
Күреп кит
Яңарган Дойчланд
җирләрен...»
Кырык дүрт –
Алтмыш дүрт.
Ике ара аз түгел,
Күп түгел –
Егерме!
Хирург Берлинга юл ала:
Гансны, Фрицны күрергә.
Җырлыйлар көпчәкләр,
Көйлиләр:
– Ди муттер, ди муттер,
ди муттер...
Чал чәчле хирург-анага
Моннан да күңелле юл
юктыр.

1964 ел


---

* Die tatarische frau – татар хатыны (нем.)
** Муттер *(нем.)* – ана.
*** Русиш гут *(нем.)* – рус яхшы.
**** Фрау, ду зер гут татариш *(нем.)* – ханым, син бик яхшы татар.
***** Дер велт фор дем гроссен криг *(нем.)* – дөнья калтырана зур сугыштан. (Гитлер армиясенең поход маршында шулай җырланган.)



Әмирхан Еники... Тыйнак, мөлаем, сизгер күңелле, кешелекле язучыбыз ул. Әсәрләрен укыган саен укыйсы килеп тора. Каләмен, әйтерсең, хискә-моңга, сагышка манып язган: күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли. Иҗаты уйландыра, күңелне иркәли, теле җырлап тора, музыкаль бер аһәң булып яңгырый. Проза белән яза торган шагыйрь, укучы аңына юлны йөрәге аша салган үтә нечкә күңелле рәссам, диләр аның турында. Әсәрләрендә – кеше җаны. Укучыларны шуның белән сихерле ул.

...Ә без, әйдәгез, кабат Әмирхан ага Еникига әйләнеп кайтыйк әле. Өр-яңадан ачкандай, «Кем җырлады?» хикәясен укыйк. Дәһшәтле сугыш, гади кешеләрнең рухи чыдамлыгы, туган илне сагыну, Таһирә җырының йөрәкләрне актаруы шулкадәр тирән кичерешләр аша психологик осталык белән тасвирланган. Гади солдат булып Бөек Ватан сугышы фронтларын узган Әмирхан Еники гына шулай яза ала! Таһирәнең прототибы исә – Әлфия Тутаева, Миләүшә Тәминдароваларның әнисе Таһирә ханым.



Әмирхан ЕНИКИ

КЕМ ҖЫРЛАДЫ?

Хикәя

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк – бар да җимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен – әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы – моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын тора, әйтерсең казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант – татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кы-

чыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды – эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымда гына җырлап торган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы-мазар ишетелми иде. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан, ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкренрәк җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең нindидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын



Рәсем: Наталья Васильева



гына башлап китә. Үзенә күбрәк ошаган кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына — Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңнардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне һавада йөзгәндәй җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр берзаман шул,
Печәннәре җитәр берзаман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таякка таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

– Әнием, әнием! – ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып, терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз, тирән бер сагыш белән:
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда... –

ди.

Һәм егет ике куллап Таһирәсенең башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен аның күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен аның җылы, йомшак муенына тидерә, имеш:

«Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың? Без мәңге, мәңге бергә ич!»

Һәм кыз, башын аның күкрәгеннән алмыйча, назланып, зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем...

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәңге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга, Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенең күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр, йа Хода, нинди киңлек, нинди киңлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган җир! Шундый җиңел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын киң җәеп, таудан күтәреләләр һәм пар аккоштай елгалар, кырлар, урманнар өстеннән шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

Кыз җырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавыш-тынсыз гына кузгалып китте – егет моны сизмәде. Ул инде яңадан аңына килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, бәхилләшергә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә, чыннан да, бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

1956 ел

«КАДЕРЛЕМ, РӘЙСӘМ! БЕЗ – БЕРЛИНДА, ҖИҢҮ БАЙРАГЫН КАДЫЙБЫЗ!»

Алар – тыныч тормышны яу кыры белән бәйләп торган, соңгы сулышкача яшәргә һәм «Алга!» дип, дошманга каршы ташланырга көч биргән, яраларның сызлавын басарга ярдәм иткән, туган якның иркен һавасын алып килгән фронт хатлары. Кургаш исен сеңдереп, сугыш кыры белән туган ил арасында йөреп торган сары конвертлы хатлар... Сугыш чынбарлыгы, саф сөю хисләре, тыныч киләчәккә якты ышаныч тулы бу хатларның күбесе тере тарих булып музей киштәләрендә, ә кайберләре кадерле ядкарь булып гаилә архивларында саклана. Күптән түгел генә без дә Әлки районы Яңа Чаллы авылыннан сугыш хатларының күчерелмәсен алдык. Аларны редакциягә Лира ханым ВӘГЫЙЗОВА юллаган.





«Бу хатлар сугышның башыннан алып ахырына чаклы барып җиткән, Җиңүне Берлинда каршы алган әтием Хасыйб Рахманов кулы белән язылган.

Сугышка чаклы әтием Әлки районы Иске Алпар авылы мәктәбендә белем бирә. Үзенең чыгарылыш класс укучыларын имтиханнардан соң Мәскәүгә алып барырга хыяллана ул. 1941 елның 19 июнендә Әлки яшьләре Хасыйб абыйлары җитәкчелегендә Мәскәүгә килеп җитә. Бу төркемдә – булачак әнием Рәйсә дә була. Укытучы белән укучы арасындагы җылы мөнәсәбәтләр беркем өчен дә яшерен сер булмый... Укучылар Ленин Мавзолеенда, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә, башка истәлекле урыннарда булырга өлгерә. Сугыш дигән коточкыч хәбәрне дә алар Мәскәүдә ишетә. Әтием кичекмәстән Фрунзе исемендәге Хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итә. Аңа укучыларны тиз арада үз авылларына алып кайтырга приказ бирәләр. Кыенлыклар кичереп булса да, әтием укучыларны кайтарып җиткерә. Бер-берсенә гашыйк укытучы егет белән укучы кыз тиз арада никах укыта. 1941 елның ноябрь башында әтиемне сугышка алалар. Әнием үзенең туган авылы мәктәбенә башлангыч сыйныф укытучысы булып урнаша. Ирен сугышка озаткан әниемнең карынында җан иңәргә өлгергән нарасые тибенә... Әтием тиз арада элемтәче һөнәрен үзләштерә, фронтның алгы сызыгында – җирдә, сулы урыннарда элемтә чыбыклары суза. Ул әнигә бик матур хатлар юллый, җае булганда солдат көндәлеге алып бара.

«Сөеклем, Рәйсә! Синең белән хат аша гына сөйләшә алам. Бездә бер ышаныч: бу канлы сугышның озак бармавына өметләнү белән дошманга каршы сугышабыз!..»

«Сөеклем, Рәйсә! Сиңа бит әле 18 яшь кенә. Укучылар бик борчымыйммы? Аларның күбесенең аталары сугышта бит. Вакыты белән сиңа кырыс та булырга туры киләдер. Үзеңне сакла!»

«1942 ел, сентябрь. Ржев шәһәре өчен каты сугышлар бара. Кадерлем минем, иң куанычлы хатларың адаша-адаша килеп җиттеләр. «Ура!» кычкырам. Димәк, безнең Илдарыбыз бар, без хәзер өчәү! Үзеңне берүк саклый күр! Кулымда – карточкаң, күңелемдә – сүзләрең. Өзелеп-сагынып – Хасыйбың.»

«1943 ел, 27 март. Бүген сиңа 100 нче хатымны язам. Илдар үсә, дигәнсең. Зур шатлыгым бу. Икенче шатлыгым – «Сугышчан батырлык» медале белән бүләкләделәр. Хатларыңны ешрак яз! Хат килми торса – күңелем боега. Хасыйбың.»

Әтием 1944 елны көчле контузия алып госпитальдә каршы ала. Әниемә хатлар инде госпитальдән килә башлый.

«Рәйсә, кадерлем, түземлем минем! Илдар үлде, дигән хәбәрең килде... 35 яшьтә көтеп алган улым инде дөньядан китеп барган. Ничек түздең икән? Сугыш ирләрне кыра, аяк-кулларын гына түгел, өметләрен дә өзә... Тик безнең мәхәббәтебез көчлерәк, мәхәббәт мәңгелек!»

Көндәлектән өзек: *«30 март, 1944 ел. Күп авырлыклар белән дошманны тар-мар итеп, Перемышль шәһәрен азат иттек. Югары Совет Президиумы Указы белән Висла елгасы янындагы сугышта күрсәткән шәхси батырлык өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләндем».*

«1944 ел, 29 декабрь. Гомерлек Рәйсәм! Бу елда минем соңгы хатым булыр, 1945 елга аяк басабыз. Елның соңгы төнен яңа бәхетләр теләп каршы алыйк! Без Германия җирендә, Берлинга 60–70 чакрым».

«Сөеклем, Рәйсәм! Сиңа 157 нче номерлы хатым. Бүген Берлинда Җиңү байрагын кададык! Менә ул, Берлин – җимерек, бер генә төзек йорт та юк. Гел синең турында уйлыйм, җан җылым бит син минем. Күңелемдә өч хыял: туган туфракка кайтып тезләнү, сөйгәнемне кочагыма алып, алдагы гомер сукмагына чыгу һәм сугыш ачысын күргән, атасыз калган балаларга белем-тәрбия бирү. «Хәерле иртә, балалар!» – дип, дәресемне башлап җибәрәсе килә, Рәйсәм!»

Хасыйб Рахманов авылга күкрәген орден-медальләр белән балкытып, җиңүче булып кайта. Сугыш кырларындагы изге хыялы чынга аша аның: бергәләп Алпар урта мәктәбендә гомер буе татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучылары булып эшлиләр.

Әтиемнең өч теләге дә үтәлде. Без биш баласына тәрбия биреп, олы тормыш юлына озаттылар. Кадерлеләрем икесе дә мәрхүмнәр инде. Алар турындагы бу язмам – әти-әниемә дога булып ирешсен иде.



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Капкадан чит кешеләр керүен күргәч, Мәҗүдә әбинең йөрәге жу итеп китә. Юлаучылар Асия Хәлиулла кызының Таң авылында шушы йортта туууын ачыклагач, әбигә «Кызыңнан!» – дип, фанердан ясалган чемодан бирәләр дә, аманәтне тапшырдык, дип китеп тә баралар.

Әби чемоданын ачып җибәрсә, «Без кайттык, кызың бик еракларга китте» дигәндәй, Асиянең кызыл атлас белән үрелгән ике толым кап-кара чәче һәм әнисенә язган хаты килеп чыга.

Чәч толымнарын күкрәгенә кысып озак кына елагач, әби язылганнарны укырга керешә. Хатта яшь укытучы кыз үзен фронтка җибәрүләре, исән булса, Ходай кушса, тиздән кайтып күрешергә өмет итүе турында язган була. Берникадәр вакыттан соң Асиянең фронттан беренче хаты да килеп җитә. «Дошманнар көне-төне шәһәрне бомбага тота, безне – 30 кызны зенитчылар итеп Белорус фронтына озаталар», – дип яза ул.

Асия – минем әнием була инде. Ул 1921 елда Буа районы Яңа Тинчәле авылында дөньяга килә. 1940 елда Буа педагогика мәктәбен тәмамлагач, аны Теләче районына балалар бакчасы тәрбиячесе итеп эшкә җибәрәләр. 1942 елда фронтка китә. Зенитчы булып хезмәт итеп, күп батырлыклар күрсәтә.

...Асиянең әнисенә сугыш кырыннан хатлар килеп кенә тора. «Нинди авырлыклар булса да, Ватан алдында изге бурычны үтәргә тырышабыз! Бер генә самолет бәреп төшерсәк тә, күпме кешенең гомерен саклап калабыз бит!» – дип яза ул. Соңгы хатын ул 1945 елны: «Без Одра елгасы буенда. Озакламый күрешербез – иң беренче хатын-кызларны демобилизацияләр. Кичә окоплар арасыннан гармунга кушылып агылган татар җырын ишетеп, күңелләрем нечкәреп, Таң авылының бәбкә үләненә ятып елыйсыларым килде. Эзләп барсам, олы яшьтәге бер абый татарча җыр суза. Үзен Ульян өлкәсеннән дип таныштырды. Миңа: «Елама, сеңлем, сугыш бетәр, без җиңәбез», – дигәч, шатланып, насыйп булсын иде дип Ходайдан сорадым», – дип тәмамлый ул.



Сугыш бетә, илгә Җиңү килә. 1945 елның августында әнием туган ягына әйләнеп кайта. Озакламый аны Нурвахит авылына укытучы итеп билгелиләр. 1946 елны авылга сугышка киткән егетләр кайта башлый. Суксу мәктәбендә әнием белән бергә укыган Сәлим исемле егет тә кайтып төшә. Алты ел хат алышып, вәгъдәләр бирешкән ике фронтовик Суксу авылында тормыш корып җибәрә. Асия – мәктәптә, Сәлим авыл советында авылдашларына хезмәт итәләр. Икесе дә күптөрле медальләр, орденнар белән бүләкләнәләр.

Әниемнән: «Җиңү көнен кайда каршы алдың?» – дип кызыксынган идем, землянкада, дип җавап бирде. «Төнге караңгыда кайтып, йокыга гына киткән идем, көчле атыш тавышыннан, өстемә туфрак коелудан уянып киттем. Дошман яңадан һөҗүмгә күчә икән, үлсәм – үләрмен, дип, башымнан ук томаланып яткан идем, елашып кызлар килеп керде. «Тор, сугыш бетте, булган барлык снарядларны атып бетерергә приказ килде», – диләр. Кочаклашып елаштык...»

Әти-әнием – Асия һәм Сәлим Насыйбуллиннар 58 ел бергә гомер итеп дүрт бала үстерде. Хәзер инде без – балалары һәм укучылары – алар рухына дога кылабыз, рухлары шат булсын дигән теләктә торабыз.

Сугыш афәтләре бүтән кабатланмасын иде!

Дания ИБРАҺИМОВА.
Буа районы.

Фото: Газинур Хафизов

Кешелек дөньясына кайгы-хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга инде җиде дистә елдан артык вакыт узды.

Гомерендә бер мәртәбә дә авыз тутырып «әти» дип әйтә алмаган балалар хәзер инде үзләре әби-бабайлар. Канлы ут эчендә йөргән ветераннарыбызның да саны елдан-ел кими бара. Бөек Җиңү көнендә аларның моңсу күзләрендә һәрвакыт яшь тамчылары ялтырый.

Безнең Әгъзам бабабыз сугышка беренчеләрдән китә. 1938 елны Минзәлә педагогика көллиятен тәмамлагач, Җәмәк, Яңа Кормаш мәктәпләрендә белем бирә. 1940 елда армия сафларына алына. Сугыш башлангач, 23 июньдә аларны Ленинградка Киров заводын сакларга җибәрәләр. 25 июньдә солдатлар Смоленск юнәлешендә юл тоталар. Көчле немец гаскәре һөҗүменә түзә алмаган 111 дивизиянең 155 нче укчы полк сугышчылары чигенә башлый. Аларны фашистлар чолгап ала. Ачлык, ялангачлык көчәя, команда составы көннән-көн сирәгәя бара. Волховны үтә алмагач, алар вак төркемнәргә бүленәләр. Ачлыктан хәлсезләнгән бабам пленга эләгә. Аны Чудово станциясеннән ерак булмаган бер лагерьга илтеп ташлыйлар. Әсирләр арасында йогышлы тиф чире башлана, бет баса. Башкорт егете бабабызны тиф белән авырмаучылар янына күчереп, гомерен саклап кала. Дортмунд шәһәрендәге лагерьдан ул Омск егете белән кача, әмма Герцен шәһәрендә яңадан тотыла. Шул шәһәр төрмәсендә поляклар белән утырганнан соң, Бухенвальд концлагерена озатыла. Бу лагерьда аларны каты җәзалыйлар: мунчага кертеп, өсләренә башта боздай салкын, аннан тәнне пешерерлек кайнар су коялар. Күбесе, хәлсезләнеп, пешеп, чыга алмыйча шунда кала.

Концлагерь 28 чакрым мәйданда, электр тогы үткәрелгән, чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган. Ә яшәгән блоклары тактадан гына эшләнгән, салкын вакытта бер-берсенә сыенып, өелешеп ятып җылынганнар. Ачлыктан хәлсезләнгәч, бер-берсенә тотынып йөргәннәр. Концлагерьдан аларны Америка гаскәрләре азат иткән.

Япон сугышы башлануга, бабам кабат сугышка китәргә гариза яза. Ул анда минометчы булып хезмәт итә. 1946 елны укытучыларны кайтарырга дигән приказ булгач, туган ягына әйләнеп кайта. Минзәлә районының Иске Байлар авылында мәктәп мөдире булып эшли, гаилә корып җибәрә. Гомер буе укытучы булып эшләп лаеклы ялга чыга. Аның фидакарь хезмәте орден-медальләр белән югары бәяләнгән.

Әгъзам бабам 1990 елда мәчет төзү эшенә дә җитәкчелек итә. Ул 2002 елда бакыйлыкка күчә. Авылыбызның ихтирамга лаек кешесе буларак, аны бүген дә сагынып искә алалар.

Резидә ВӘЛИЕВА.
Түбән Кама шәһәре.

Безнең Актүбә эшчеләр бистәсе Азнакай районының иң биек җирендә урнашкан. Безгә кайсы гына яктан килсәң дә, юллар өскә таба менә. Ә кышларын ул ерактан ук ак түбә булып күренеп тора – шуңа да аның исеме Актүбә.

Сезне менә шул Актүбә эшчеләр бистәсенең зур хөрмәткә лаек, соклангыч шәхесе Ләйлә Миргалим кызы Карамова белән таныштырасым килә. Ул – бистәбездә 600 кешене берләштергән инвалидлар җәмгыяте рәисе. Мөмкинлекләре чикләнгәннәр белән эшләү аеруча игътибарлы булуны сорый. Ә безнең Ләйләбез барысын да булдыра. «Үзем оештырган «Җырлы язмышлар» төркеме белән төрле төбәкләрдә 1450 нче концертыбызны куеп кайттык», – ди ул. Ләйлә – 95 җыр авторы. Сүзләрен дә, көен дә үзе яза, башкара, сценарийлар төзи, кичәләр алып бара, кирәк булса аппаратураны да үзе көйләп куя. «Мин җитәкчелек иткән төркемнең җырчы егетләрен Тәтешле мәдәният сараенда узачак концертка чакырдылар. Анда мәрхүмә җырчыбыз Хәния Фәрхигә багышланган кичәдә «Хәниябез» дигән җырымны башкардым, җырчының туганнары белән аралаштык», – дип, истәлекләре белән бүлешә Ләйлә. Шулай ук концертлардан кергән акчаны авыру балаларга бүлеп бирү, ярдәмгә мохтаҗларга хәйрия концертлары аша ярдәм оештыруларын да әйтеп узасы килә. «Казандагы 2 нче, Әлмәттәге 8 нче санлы каты режимдагы төрмәләрдә, Бөгелмәдәге вакытлыча тоткарлану изоляторларында да чыгыш ясау күңелләрдә онытылмаслык булып уелып калды, – ди ул авыр сулап. – Хөкем ителүчеләр арасыннан сәхнәгә күтәреләбез. Кулларына автомат тоткан төрмә хезмәткәрләре безне озатып бара. Әниләр, туган як турында үзем иҗат иткән җырларымны башкарганда хөкем ителүчеләрнең күзеннән яшь акканы күренә, аларга карап минем дә күңелем тула... Язмыш адәм баласын ничек кенә сынамый! Менә шулай алты районның инвалидларын берләштереп, төрле Картлар йортларында яшәүче инвалидларны да ияртеп, төрмәләрдә, Балалар йортларында хәйрия концертлары куя бик зур тырышлык таләп итә», – ди ул елмаеп. Ләйлә Миргалим кызының кешеләргә булган олы мәхәббәте, ихласлыгы, гадилеге, эчкерсезлеге, юмартлыгы аны кабатланмас шәхес итә.

Ләйлә Миргалим кызы ире Илдар белән ике кыз, бер ул үстерәләр. Илдар – Ләйләсенә җаны теләгән эшләр белән шөгыльләнергә мөмкинлек тудыручы олы йөрәкле кеше. Кызлары Рәзилә Әлмәт шәһәрендә Клара Булатова исемендәге премия уңаеннан уза торган конкурста лауреат булды, шигырьләре китапка кертелде. Уллары Илнар – II группа инвалид. Азнакайда инвалидлар җыелма командасы белән спорт ярышларында катнашып, өч алтын, ике бронза медальгә лаек булган. Ләйлә Миргалим кызы үзен бәхетле саный. «Минемчә, бәхет ул – тормышны бөтен тулылыгы белән тоя алуда, игелек кылуда, якын кешеңнең елмаюын күрүдә. Адәм баласына тормыш башкаларга булышу, игелек кылу өчен бирелгән» – ди ул үзе.

Әлфия ЗАКИРОВА.
Азнакай районы, Актүбә бистәсе.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

SOS! Җанымны коткарыгыз!





Эльмира ЗАКИРОВА

Бу язма – Бөек Ватан сугышы фронтларының алгы сызыгында көн саен үлем белән очрашып та исән-сау әйләнеп кайткан, ләкин гаиләдә икенче сугышка, ир тарафыннан җәбер-золымга эләгеп, дөньядан вакытсыз китеп барган хатын-кыз язмышы турында. Беренче Украина фронты өлкән сержанты радист Рәҗәп Вәҗиевага ут эченнән штабка мөһим мәгълүматлар, хәрби приказлар тапшырып торырга да, Морзе әлифбасында ашыга-ашыга «өч нокта-өч тире-өч нокта» җыеп, безнең җаннарны коткарыгыз дип, SOS һәлакәт сигналы җибәрергә дә туры килгәндер. Ә менә сугыштан кайткач күргәннәре – үзенә ярдәм сорап һәлакәт сигналлары җибәрерлек булган. Рәҗәп апаның кызы Рузалия Низамова хәтерендә шулар куркыныч фильм кебек кабат-кабат яңара. Ул сөйләгәннәр, күз яшьле көндәлек битләре булып ачыла бара...

Аерылып та китмәде, рәхәт тә күрмәде

1950 нче еллар ахыры. Мин белә-белгәннән бирле әни больницада икешәр смена санитарка булып эшләде. Өйгә тәмам хәлдән таеп кайта иде. Ир кеше агач утыртырга, йорт салырга, уллар үстерергә тиеш, диләр. Безнең әни хатын-кыз була торып та шуларның барысын да үтәде. «Татарстан» совхозында алма бакчасы утырткан. Аннары Киров совхозына күчеп кайтып, шунда беренче өен салган. Сәфәр урамындагы иң азаккы өй безнеке иде. Байсарга кайткач, башта интернат янындагы өйалдысы да булмаган өйне сатып алды, аннан яңа өй салдырды. Үз гомерендә өч өй салып керде ул. Үзе җыйган акчага, үз тырышлыгы белән! Дүрт бала табып үстерде. Әти безнең тормышка битараф булды. Әнинең өстеннән йөрде. Әле бер авылга, әле икенчесенә чыгып китә. Кушаматы Зимагур иде. Безгә бер тиен дә акча бирмәде.

1956 ел, март. Күз алдында һаман бер картина: тәрәзәдән кар яуганы күренә, ул шундук эреп, дөньяны пычрата... ә безнең өйдә мәхшәр! Әти әнине кыйный. Мин күлмәкчән шул пычрак урамга чыгып йөгерәм дә әбиемнең өй почмагына барып ышыкланам. Әни килгәнче шунда басып торам, чөнки ул әбине уятып, борчымаска куша... Бәлки, әнисенә бөтенесен сөйлисе дә килмәгәндер...

1957 ел. Бер көнне әнинең күкрәген такта белән кысып алган. «Әнине үтерәсең!» – дип елап, сеңлем белән икебез ике ягына асылынабыз, ә әнинең авызборыныннан кан ага. Сугышта күрмәгәннәрен ир кулыннан күрде! Инде ничәнче мәртәбә: «Әни, аерылышыйк!» – дип ялварам. Ул бер сүз дә дәшми. Аерылып та китмәде, рәхәт тә күрмәде. Әнинең язмышы менә шулай үкенечле булды. Сугыштан исән-сау кайтып, икенче сугышка килеп эләкте, шулай дөнья көтте. Әни ирле

килеш пар канатсыз яшәде... Бер генә минутка да исемнән чыкканы юк. Хәзер искә төшерәм дә...

60 нчы еллар. Әнине җәлләп бөтен эшләрен эшләргә тырыша идем. Алтынчыда укыганда керләр юа идем инде. Аның бердәнбер күлмәге бар иде, гармун кебек рәсемнәр дә төшкән. Үзе гел ямалып беткән. Эчке күлмәкләрендә дә ямау өсте ямау. Аларны көчкә күтәреп сыгам. Бер юньле киеме дә булмаган инде. Үләр алдыннан үзенә плащ, бер свитер алып кала алды. Мендәр дә, юрган да юк иде безнең. Салам тутырылган мендәр, матраста өскә әнинең шинелен ябынып йоклыйбыз...

1970 ел. Декабрьдә аңа 48 яшь тулырга тиеш иде. 1970 елның августында китеп барды. Энекәшләр әле кечкенә, мәктәптә укыйлар. Мин инде кияүдә, ун айлык кызым бар. Гүзәл генә кайтып җитә алмады. Мединститутка имтиханнар тапшырып йөри иде. Әнкәй үзе үк: «Имтиханнарны бирә алмадым, конкурстан узалмадым дип кайта күрмәсен берүк, медучилищега булса да керсен!» – диде һаман. Чөнки заманында үзе Казан медучилищесына дип чыгып киткән булган. Пароходта документларын урлаткан... Аннары инде Бауман урамындагы типографиягә урнашкан. Шуннан сугышка киткән... Үләсе көнне дә Гүзәл белән сөйләшкән әле телефоннан. Рус телен генә тапшырасы калган... Ә берничә сәгатьтән кайгылы хәбәр килеп җитә. Елап ректорга керә. «Кызым, үлгән әниеңне кайтара алмыйсың. Кайтырга да өлгермисең. Имтиханыңны тапшыр, синең бар да әйбәт бара», – ди ул.

1954 ел. Мин кечкенә идем әле. Совхозда яшәгән чак. Ирләр юк. Хатын-кызлар өй борынча кич утырырга йөри. Апалар, безгә кереп, калай мич тирәсендә дөнья хәлләрен сөйләшәләр. Алар чыгып киткәч, әни радионы борып ача. Татарча радиоспектакльләрдән еш кына сугыш эпизодларын яңгыраталар. Пи-пипи-пи... Морзе әлифбасында нәрсәдер хәбәр итәләр. Әни тиз генә кәгазь, карандаш алып, шул морзянканы шифрлый башлый. «Әни, нинди сызыклар ул? Син каян беләсең?» – дип сорыйм. «Менә монда фашистларның кайда тупланганын, сугышның ничек барганын штабка хәбәр итәләр. Радистлар шулай эшли», – ди. Үзе башлап сөйләми. Гомумән, әни сугышта күргәннәре турында сиран гына искә төшерә иде. Сугышта булганга шундый булып калганмы, башка сәбәпләрме... Сөйләгәннәре аерым эпизодлар булып кына искә төшә.

Фриц куак арасыннан килеп чыгар кебек

Әни истәлекләреннән. «Кичтән повестка китереп тоттырдылар. Иртән 7.30 га Вахитов районы военкоматына килеп җитәргә кушылган. 1 котелок, 1 кашык, 1 кружка, алмаш кием алырга дип язганнар. Әнине дә күрми үләм икән дип, төне буе елап чыктым... 1942 елда, сугышның иң хәтәр көннәрендә бу. 1941 елда әле нәрсә килеп чыгасын аңлап та бетермәгәннәрдер. Очучы-разведчик Фәрваз абыем да каты яралана. Госпитальдән чыккач, ике генә көнгә авылга кайта. Һәлак булды хәбәре килгәч бит әле ул. Әни чак һуштан язмый. Кабат

Сәламәтлеге тәмам какшап, әти кыйнауларыннан вакытсыз китеп тә барды.



фронтка китә абый. Аның турында легендалар йөри. 283 очыш ясап, меңнәрчә километр ара очып, йөзләгән метр фотопленка төшерә. Эфирга сигналлар җибәрә: «Алтмышка якын вагон. Ачык платформаларда барлыгы кырык танк». Берсендә разведкадан кайтып барышлый Терек елгасы аркылы салынган күпердән дошманның берничә танкы узып бара. Барлык бомба запасын шулар өстенә яудыра штурман. Танкларның берсендә немец генералы – Төньяк Кавказ фронты командующие утырган булып чыга. Фашистлар өчен бу югалту зур фаҗигагә әйләнә, алар фронт буенча өч көнлек матәм игълан итә...

Әни истәлекләреннән. Машиналарга утыртып вокзалга алып килделәр башта. Аннан вагоннарга төяделәр дә алып киттеләр, кая баруыбызны әйтмәделәр. Казан кызлары Тамара белән Галя юл буе җырлап-биеп барды. Мин еладым да еладым. Поездан төшкәч, тагын исемлек буенча тикшерделәр. Япан кыр. Сугыш авазлары яңгырап ишетелеп тора. Шомлы. Тамарага – передовойга, Галяга кухняда каласың, диделәр. Кызлар, аермагыз безне дип, кочаклашып елый башлады. Шунда каян нинди көчләр алганмындыр – русчам да чамалы, званиеләрен дә белмим – «Товарищ командир, пусть они на передовую идут, оставьте меня на кухне», – дидем. Баштанаяк карады да: «Вазеева, на кухню!» – дип приказ бирде. Бер украин егете ашарга пешереп йөри иде. Исемемне сорады. «Рәҗәп... Разяп», – дидем. «Р хәрефе бар, З бар, димәк – Роза син!» – диде. Миңа бөтен ризыкны пешерергә өйрәтмәкче! Ул да булмады, «В атаку!» дигән приказ яңгырады, поварны да чакырып алдылар. Автоматын алды да китте, кире әйләнеп кайтмады. Нишләргә белмим. Повар кайтыр дип, бер әйбергә тотынмадым бит! Алай да нидер пешереп, тәлинкәләргә бүлдем. Берзаман котелоклары белән өстәлгә бәрә башладылар. «Мондый повар кирәкми!» – дип шаулашалар. Тора-бара өйрәндем. Авылларга керергә туры килсә, ярманы кәбестәгә алмаштырдым. Бушап калган бакчалардан кәбестә яфраклары җыйдым...

Әни истәлекләреннән. Фәрваз абыйның йогынтысы булгандыр дим. Чакырып алып, Морзе әлифбасын өйрәтә башладылар миңа. Көндез – кухняда, кич укуда булам. Менә шулай радист булып куйдым. Машинада йөрибез. Кабельләр салып, элемтә чыбыкларын сузып... Беребез килгән хәбәрләрне кабул итеп утыра, калганнар тышкы якта дежур тора. Машина артында берүзем саклап торганда шундый курка идем! Фриц куак арасыннан килеп чыгар да автоматтан ата башлар сыман...

Яртылаш йөз, сыңар куллар оча...

1960–70 нче еллар. Әнинең бер чемоданы бар иде. Шунда медальләре, солдат кенәгәсе, карточкалары,



Әни үләсе елларны гына сугышта катнашканнарны җыелышларга чакыра башладылар.

солдатлар белән төшкән фотолары... Ул фотоларны әти ертып, тураклап ташлады. Күз алдына китерәсезме: ерткаланган фото кисәкләре җилдә яфрак кебек оча... Әнинең сурәттәге бөдрә чәчләре, яртылаш йөзе, күзләр, сыңар куллар, пилоткалы солдат башлары... Әни үлгәч, ул чемоданны үзем белән алып китәргә талпындым башта, аннан, өйдә кеше кала бит әле дип, кагылмадым. Шулай да бер нәрсәне эшләдем. Әнинең әбидән калган көмеш чулпылары бар иде. Шуларны уенчык итеп уйный идек. Берсе дә калмады, югалып бетте. Энекәшләр балачага белән уйнап, югалтып бетерер дип, медальләрен әнинең баш очындагы мендәренә кадап куеп, үзе белән бергә җир куенына озаттым. Ул вакытта аңлап та, кадерен белеп тә бетермәгәнбез инде. Сугыш һәр өйгә, һәр гаиләгә кергән бит. 1970 елда Җиңүнең 25 еллыгына багышлап клубка җыйдылар. Медальләр тапшырдылар. Ул бер генә җыелышка барып калды, мәрхүмкәем. Фотодагы костюмы да үзенеке түгел, эчтән кигән кофтасы да... Андый җирләргә киеп чыгар киеме дә юк иде аның. Гел шул бер халаттан йөрде.

Нәрсәгә шул ир белән торды икән газапланып?.. Юкса сугыштан кайткач, бер украин егете сорап килә – әнисе кире бора, Сорокин дигән керәшен егете килә, әнисе тагын риза булмый. Балык Бистәсенә бер балалы иргә биреп җибәрәләр – җәяүләп качып кайта. Күрше авыл егете Рифгатькә – безнең әтигә чыга. Үземне аның урынына куеп, анализлап карыйм да, җавап табалмыйча гаҗиз булам. Нигә? Нигә? Нигә? Шәһәрләргә китеп, башка хатыннар белән яшәде. Никләр түзгән әни?! Сугышта үлем белән дә очраштым әле дипме? Балалар хакынамы? Кеше сүзеннән кыенсыныпмы? Психологик яктан аңларга тырышып карыйм да төртеләм. Бу инде сугып җибәреп бит күгәртү генә түгел...

Авыл советы элеккеге байлар кибетенең икенче катына урнашкан иде. Әти белән әни йомыш белән кереп, икесе арасында тавыш чыккан. «Әтиең Рәҗәп апаны өстерәп алып, икенче каттан аска кадәр тибә-тибә алып төшеп китте», – дип сөйләделәр. Хәер, сөйләмәсәләр дә, үзем күреп үстем бит. 15–20 минут кына черем итеп ала да сикерә дә тора иде әни. Сугыштан шулай калгандыр, нервылары беткәндер дип уйлый идем...

Кеше кулыннан үтмәсәм ярар иде, кызым!

13 август, 1970 ел. Безгә Күҗәкәгә соңгы килүендә әнине йоклаттым да каршыдагы буага бала чүпрәкләре юарга төшеп киттем. Ул арада артымнан килеп тә житкән. «Сине эзли-эзли арып беттем», – ди. Басмага аягын сузып утырды да: «И кызым, кеше кулыннан үтмәсәм ярар иде инде», – диде. Ул сүзләрнең мәгънәсен аңламаганмын шул. «Нәрсә соң ул?» – дигәч, эндәшмәде. «Кызым, әллә яшәп була, әллә юк – сиңа әйтәсе сүзләрем бар әле», – диде бераздан. Кинәт әллә нишләп киттем. «Нәрсә сөйлисең син, әни?! 47 яшеңдә үләргә җыенасыңмы? Балаларыңны кем карар?» – дип, бу сөйләшүдән ераклаштырасым килде.

14 август, 1970 ел. Әнине җомга көнне ирем белән авылыбызга кайтардык. Чәй дә эчеп тормадык, ашыкпошык кына саубуллаштык та чыгып киттек. Дүшәмбе барыбер отпускыга кайтам бит.

И яңгыр килә инде. Чыланмасын дип, кабалана-кабалана печән җыярга чыктык. Шунда кинәт күңелемә шом төшеп, әни янына кайтасым килә башлады. «Кайтып килим әле. Эчем поша. Әнигә бер-бер хәл булмагае. Их, теге машина да безнең якка кайтып китәчәк бит!» – дип өзгәләнгән идем, ирем җибәрмәде.

16 август, 1970 ел. Төнлә төш күрәм. Әни белән икәү буа басмасында икәнбез. «Кызым, сиңа әйтер сүзем бар», – ди. «Хәзер, әни, синең якка чыгам», – дип, басманың теге ягына гына чыгам – әни икенче якка күчкән була! Инде кабат әни янына чыгып җиттем генә дигәндә, ул тагын каршы ярда. Уртада – су... Безгә чапырыш кына парторг Камильяновлар өе иде, төштә өй почмаклары җимерелеп төшкәнен күрдем. Мин утырып кайтырга теләгән машина да шунда...

17 август, 1970 ел. Иртән ирем районга, ерак туганыбызның бездә торучы кызы клубка (ул шунда эшли иде) җыена башлады. Чәй эчкәндә төшемне сөйләдем. «И апа, әйбәткә түгел. Үлем-китем булмагае», – дип шөбһәгә салды туганыбыз. Озак та үтми, тыны куырылып, клубыннан йөгереп кайтты, әниең авыр хәлдә, ди. Иремнең энеләренә ат җигәргә кушып, әнинең хәлен белешергә дип телефонга чыгып чаптым. «Нәрсә дип шалтыратасың? Әниең үлгән инде!» – ди секретарь апа. Трубканы ыргыттым да урамга атылдым. Барсам, атлар җигелмәгән дә әле. Шулчак күрәм: кожаннар киеп утырган парторг бишекле мотоциклда узып китте. Артыннан өйләренә чаптым. Ихаталарына керә-керешкә хәлне аңлаттым да, очтык кына авылга! «Тизрәк, тизрәк!» – дип куалыйм әле. «Газны бөтен көченә ачып бетердем, моннан да тиз баралмыйм!» – ди Камильянов.

Бераз калкулык булып күтәрелгән урамнан, кечкенә чакта әнинең эштән кайтуын гел көтеп тора идем. Шул юлдан әни зиратка китеп барадыр кебек...

Кайтып туктадык. Халык ыгы-зыгы килә. Атылып кердем дә: «Әни, үтерделәрме?..» – дип сыгылып төштем. Беләм бит инде, әти тагын кулы белән уйнаган. Күршеләр: «Юк, үтермәделәр. Үзе... Кан басымы белән...» – дип, мине җилтерәтеп алдылар да, үлек өстенә яшь төшерергә ярамый дип, урындыкка утыртып куйдылар.

Ниләр әйтергә теләдең икән, әнием?! Һәлакәт киләсен сизеп, җанымны коткарыгыз, дип ялвардың микән? Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау сорадыңмы? Минем ирем дә кул күтәрергә ярата. Каршыңда сүз бирәм, әни, синең тормышны кабатламаячакмын. Кул күтәрә икән – араларны өзәм! Бәхил бул, әнием! Гомер буе сине сагынырмын! Соңгы сулышымача йөрәк түремдә булырсың, әнкәем минем!..

КИЛЕН КЫЗ БУЛМЫЙ

Баштарак бу хәлгә артык игътибар да итми идем, хәзер менә кайчак ачу да килә, кайчак аптырап та куям. Сәбәбе: нәрсә генә эшләсәм дә, кайнанам эшемне килештерми. Аш бүлә башласам, сыек итеп бүлгәнсең, чәй ясасам, сөтен аз салгансың... Аңа ошасын дип, сөтен мулрак салсам, бу сыек чәйне кемгә дип ясадың?.. Юк, моның өчен өйдә тавыш чыгарып, ачуланышып яшәмибез. Гомумән, кайнанам янына кунакка гына кайтыла. Әмма гел гаеп тапкач, күңелле түгел. Югыйсә үзем дә илленче яшем белән барам бит инде.

Нурания Галимова.
Казан шәһәре.

Алсу Фазлыева,
җырчы:

– Минемчә, яши-яши кешенең фикере үзгәрүчән. Яшь вакытта бертөрле булган кеше, олыгая төшкәч, башкача уйлый башлый, үзен башкача тота. Олы кешенең көйсезләнүедер бу, бәлки. Алар үзләренчә генә дөрес дип саныйлар. Шуңа күрә бу очракта сүз көрәштереп, хаклыгыңны расларга тырышудан мәгънә юк. Аеруча кунакка гына кайтып йөргәндә һәм аеруча килен кешегә. Иң яхшысы: ярар, дияргә дә бетерергә. Кайнана кушканча эшләү җайсыз булса, шыпырт кына үзеңчә эшләргә. Инде күңеле булсын дисәгез, ул кушканча тырышырга. Сирәк кенә күрешкән кешеләрнең синең хакта ни уйлавы ул кадәр үк мөһим дә түгел, үз гаиләң белән килешеп яшәү мөһимрәк.

Рәмис Латыйпов,
журналист:

– Бергә тормагач, ирең белән балаларың яратканга сөенеп яшә инде. Кайнанаң ошатмаса, нишләп була? Бернишләп тә булмый. Кайнана – Африкада да кайнана инде ул. Килен кыз булмый, шикәр тоз булмый, дип кызыктан әйтмәгәннәр. Олы кешене үзгәртеп булмый, яраткан иреңнең әнисе, балаларыңның әбисе булганга чыдап, бергә тормаганыгызга куанып, өегезне яратып, рәхәтләнеп яшәгез. Кайнана яратмый дигән сүз гаҗәп хәл түгел, ярата дигәне сәер, мин кеше шикелле икән әле, башкалардан артык та, ким дә түгелмен дип уйлагыз да, әллә нинди коуч-моуч, психологфәләннәргә йөрмичә генә торыгыз. Бик ачуыгыз килгәндә эчегездән, мин өемне яратам, мин иремне яратам, дип кабатлагыз. Дөнья тик тормый, кем белә, вакыт узгач яки кайнанагызның башка конкурентлары барлыкка килгәч, сезнең әйбәт икәнегезне аңлар да көндәш дип кабул итми башлар.

Дин әһелләре бу дөнья сынау өчен, ахирәт өчен яшибез дип тынычландыра бит. Сез дә килен статусыгызны кайнана статусы өчен сынау срогы дип кабул итегез: килен чакта түзсәгез, кайнана булгач, киленегезгә үзегезгә булмаган хөрмәтне күрсәтеп, сөенеп яшәрсез.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Чынбарлыкны һәркем үзенчә кабул итә. Бу аерма буыннар арасында аеруча зур, чөнки чынбарлыкны кабул итү фильтры ул – безнең тормыш тәҗрибәбез. Өлкән буын безгә үз тормыш тәҗрибәсен, үз фикерен җиткерергә тели, бездән шуны кабул итүне көтә. Ул моны яхшы ният белән башкармакчы. Ә яшьләргә аларның чынбарлыгын кабул итү кыен. Бу – буыннар арасындагы конфликт. Ул синнән үзе күрергә теләгәнне көтә, ә син үзеңне бүтәнчә тотасың.

Бу очракта нишләргә соң? Безне башкалар тәнкыйтьләгән, эшебезне килештермәгән, ачуыбызны китергән вакытта һәрчак энергия туа. Шуны аңлау мөһим: энергия бервакытта да начар була алмый, һәм ул кыйммәтле әйбер. Шушы барлыкка килгән энергияне файдалы максатта куллана гына белергә кирәк. Кайнанагыз эшегезне килештерми, тәнкыйтьли башласа, максатларыгызны, эшлисе эшләрегезне, ирешәсе уңышларыгызны күз алдыгызга китерегез һәм бу энергияне күңелегездән генә шунда таба юнәлтегез. Аны юкка-барга, аеруча мөнәсәбәтләр ачыклауга, үпкәләшүгә исраф итү дөрес булмас.


ҖАН ЯРАСЫ

Бу язмыш безнең редакциягә үз аягы белән килеп керде. Лилия ханым әнисенең моннан 33 ел элек ул вакыттагы «Азат хатын» журналына язган хатын алып килде. Ниндидер сәбәпләр белән җибәрелми калган. Әнисе вафатыннан соң күп еллар узгач, үзенең тамырлары, нәсел тарихы белән кызыксына башлый Лилия ханым. Документлар арасыннан менә шушы хатны табып ала. «Энем Мияссәр Гатиятовның фронттан җибәргән соңгы хатын журналда бастырып чыгара алмассызмы?» – дип яза Зөһрә Мусина. Өч орден белән бүләкләнгән, 21 яшендә һәлак булган Мияссәр солдатның васыять шигыре анда. Ул вакытларда фронттан килгән миллионлаган хатларның берсе бу. Туганнары өчен, әлбәттә, олы бер хатирә. Лилия ханым белән сөйләшеп утыра торгач, Зөһрә апаның үз язмышы да бик аянычлы булуы ачыкланды. Илгә килгән кайгы өстенә аның шәхси фаҗигасе дә була әле. Ул аны үзе генә белә, үзе генә яна, йөрәк яраларын үзе генә бәйләргә тырыша. Тик аннан гомере буе кан саркып тора... Хәтта сугыш тәмамланып, дистә еллар узгач та. Үләр алдыннан гына кызы Лилиягә йөрәгендә таш булып яткан авыр серен ача ул. Явыз фашист илгә үзенең пычрак аяклары белән килеп кермәсә, бәлки, аның язмышы бөтенләй башкача булыр иде...

Бу язма аның рухына дога булып барсын...



Фотолар: гаилә архивыннан



Минем әле килә әни [illegible]
Кочкан бәләкәйләрне алмыйсың.
Җан сагындым сезнең барыгызны
Күптән аерылдык туган авылдан
[illegible] ич бит [illegible] инде
Бу сугыш давылларыннан.
Ышаныгыз җиңү бездә булыр.
Исән калырмынмы белә алмыйм.
Фашистларны туган илдән куып
Сагынсамда сезнең янга кайталмыйм.
Әгәр исән булсам [illegible]
[illegible]
Курган кулә кинәт [illegible] кадалды
Басып тора [illegible] [illegible]нде егылдым
Көчләремне тәнемнән [illegible] алды.
Кайнар [illegible]ан исен сизгән көндезда
Әйләнә ул башым очында
Иртә бит [illegible] әле йомма күзем
Яшь салдат[illegible] әле һаман көчемдә.
Дуаларга [illegible] туганнарыма
Тапшыр минем [illegible] сәламем..
Хай [illegible] [illegible] [illegible]
Кулыма [illegible] [illegible]нде [illegible].

Бөгелмә районы Татар Димскәе авылында туып-үскән Зөһрә җырларга-биергә бик ярата. Бөтен теләге – артист булу. Тик колхоз рәисе булып эшләгән әтисе кистереп әйтә: «Юк!» Сәхнәдә җырлап йөрүне җитди эшкә санамый ул. Кыз, мәктәпне тәмамлагач, Казанда фельдшер-акушерлык һөнәре буенча белем ала. Тыныч тормышта бер генә ел эшләп кала. Фин сугышы башлана. Запастагы пехота полкында фельдшер булып хезмәт итә. Аларның полкын сугышка озатканда, Сталиннан хатын-кызларны фронтның алгы сызыгына җибәрмәскә дигән приказ килә. Гомере буе Зөһрә моның өчен Сталинга рәхмәт укый. Сугыш утыннан түгел, фин солдатларыннан курка ул, чөнки әсир хатын-кызларны явызларча мәсхәрәлиләр икән дигән сүзләр йөри. «Җиңү көнендә бер тост фашистларны җиңү өчен булса, икенчесе Сталин өчен иде безнең өйдә», – дип искә ала Лилия ханым. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка киткән Зөһрә гел алгы сызыкта: хәрби-санитар поездда фельдшер була ул. Сугыш кырыннан яралы солдатларны җыеп, поездларда госпитальгә ташыйлар. Пулялар яңгыры астында сугыш кырыннан алып чыккан беренче яралы солдатны гомере буена да онытмас... Чандыр гәүдәле Зөһрә, бар көчен җыеп, яралы солдатны өстери, колак яныннан гына пуля сызгырып үтә (гомеренең соңгы көннәренә кадәр ядрә сызгыруын оныта алмый ул!), якында гына бомба шартлый. Канга баткан солдатның санаулы гына минутлары калган, ул инде үләсен белә. Ташлап калдыр мине, җәфаланма, дип үтенә. Кызның күзләренә карап әкрен генә васыять әйтә: «Сестричка... сестричка... вернись с войны живой...» Билгесез солдатның шул сүзләрен ул сугыш еллары буе талисман итеп йөртә: һич тә исеннән чыгармый. Кем белә, бәлки, әнә шул васыfive аның гомерен саклап та калгандыр әле: Зөһрә бер тапкыр да яраланмый.

Кызыл хач төшерелгән поездларны утка тотмаска дигән халыкара килешүне фашистлар үтәми. Киресенчә, состав тулы яралы хәрбиләр, бер ярдәмсез хатын-кызлар белән мәче, тычкан уены уйныйлар. Ничәмә-ничә тапкыр Румыниягә, Югославиягә илтүче поезд юлын кисәләр: рельсларга бомба ташлыйлар. Ярый ла рация исән калып ярдәм чакыра алсаң, юк икән, яралыларны якындагы авыл-шәһәрләргә кадәр сөйрәп алып барасы. Исән калсаң, сөенә-сөенә сөйрәрсең... Бомбага тота башлаган поездан сикереп төшеп, гадәттә, якындагы урманга йөгерәләр. Кечкенә Зөһрә һәрвакыт поезд астындагы рельска терәлеп үк кереп ята. Рельс тимере ядрә уздырмый, өстән бомба төшә икән, җәфаланмый гына үләсең. Иптәш кызларын да шулай сакланырга өнди. Тик бомбалар ява башлагач, риза булганнары да торып йөгерә... Алар артыннан канатлары белән җиргә тияр-тимәс кенә фашист самолетлары «иярә». Корбаннары белән шулай уйныйлар. Син – мишень, алар – аучы... Йә исән каласың, йә юк... Зөһрә үз күзләре белән үлемне күрә шулай. Иң куркынычы – Волховстрой станциясе тирәсендәге һөҗүм булгандыр. Кичке уннан таң атканчыга кадәр дошман самолетлары әнә шулай «күңел ача». Зур бер составтан берничә вагон гына исән кала. Бу төнне Зөһрәнең дус кызының чәчләре ап-акка әйләнә. Сугыш бетеп күп еллар узгач та самолетлар гүләвенә битараф кала алмый Зөһрә апа. Бөгелмә аэропортына төшкән самолет тавышын ишетсә, барган җиреннән туктап кала. «Йөк ташучы самолет оча... Бомба төягән очкыч тавышын беркайчан да онытмаячакмын», – ди ул.

Бомба яудырып кына калмый, мәче-тычкан уены уйнап күңел ача фашист летчиклары.



Күктә шомлы самолетлар күренмәгәндә дә көннәре җиңел үтми аларның. Иң өметсез хәрбиләр яткан «Крегер вагоны»нда эшләгәндә җаны әрни, хирургиядә бинт җиткерә алмыйча җәфа чигәләр. Көн саен бинт юып киптерәләр. Операция ясарга наркоз юк. Солдатка спирт эчереп, авызына таяк каптыралар да эшкә тотыналар. Яралардан учлап-учлап корт чүплиләр... Санитар поездының даруханә башлыгы итеп билгеләнгәч, медикаментлар юклыктан интегә Зөһрә. Поезд станциягә туктаган арада, таныш түгел шәһәрдә төшеп, дарулар эзләп чаба. Кузгалып киткән поездга чак сикереп менеп өлгергән чаклары күп була аның. Әнә шулай дару эзләп чапкан бер көнне шәһәрдә очраклы гына абыйсы Суфиян белән очраша. Маңгайга-маңгай килеп бәреләләр. Ул шатлыклы күрешү мизгелләре секундлар белән генә исәпләнә. Икесе дә ашыга: берсенең поезды китәргә тиеш, икенчесенең – самолеты. Рельслар өстендә яшәгән Зөһрәнең өйдәгеләр белән элемтәсе булмый. Абыйсыннан якыннары хакында сораштыра да (алар дүрт бертуган – фронтта), торып йөгерә.

Хатын-кыз сугышта да хатын-кыз булып кала инде. Дарулар эзләп чабып йөргәндә хатын-кыз киемнәре кибетенә керәләр. Ә анда – нечкә бретелькалы кыска ефәк күлмәкләр эленеп тора. Соңгы тиеннәрен санап сатып алалар. Имеш, сугыш беткәч туган якларына кайтып, көязләнеп йөриячәкләр. Соңыннан гына аның эчке күлмәк икәнен беләләр.

Җиңү көнен дә рельс өстендә каршылыйлар. Сугыш бетү турында Левитан тавышы белән яңгыраган сөенечле хәбәр җаннарны актара: күргән һәр кеше белән кочаклаша, үбешә башлыйлар. Ә «Крегер вагоны»нда – тынлык. Анда селкенү түгел, сөйләшә дә алмый торган яралылар. «Аңында булганнарның күзләреннән бары яшь акты», – дип искә ала Зөһрә апа ул минутларны.



Ярата, бик ярата.
Тик гомерлек мәхәббәтен берничек тә гафу итә алмый...

Туган йортына әле ул бер елдан соң гына кайта ала. Сугыш тәмамлангач та шушы ук поездда Румыния, Югославия хәрбиләренә булышалар. Тыныч тормышта да авыруларга ярдәм итүен дәвам итә. Пенсиягә чыкканчы Бөгелмәдә ашыгыч ярдәм хезмәтендә баш фельдшер булып эшли.

Тән ярасын дәвалап була ул, ә менә җан ярасын ничек дәваларга? Сөйләп тә бушанып булмый, онытып та... Җитмәсә, фаҗиганең төп сәбәпчесе һаман юлына чыгып тора. «Без бит бер-беребезне яратабыз, әйдә, кавышабыз», – дип, ярага тоз сала. Ярата, бик ярата. Тик гомерлек мәхәббәтен берничек тә гафу итә алмый... берничек тә...

«Әнигә ул вакытта 67 яшь иде. Кибеттән агарынып кайтып керде. Күзләрендә яшь. Әти белән миңа берни сиздермәскә тырышты. Кичен, аш бүлмәсендә икебез генә калгач: «Кызым, түзә алмыйм, сиңа эчемне бушатам, – дип чишелде. – Моңа кадәр мине аңламассың дип курка идем. Хәзер инде үзең әни, аңларсың. Мин бүген аны очраттым... Беләзегемнән тотты. Ул тоткан җир әле һаман ут кебек яна...»

Лилия ханым елый-елый сөйли: «Әни кебек сабыр кеше юктыр, аның язмышы хакында бер китап язарга була...»

...Казанга килеп фельдшер-акушерлык мәктәбендә укый башлагач, Зөһрә гомерлек дустын һәм мәхәббәтен очрата. Дус кызы белән алар бик якын булып яшиләр. Укыганда, икәүләп ике дус егет белән очраша башлыйлар. Зөһрә Шәйхигә кияүгә чыга. Яшь гаиләгә куаныч өстәп, тупырдап торган уллары туа. Балага алты-җиде ай булдымы икән, Зөһрә иренең хыянәте хакында белеп ала. Яраткан кешесенең бу адымын гафу итә алмый – сабыен ала да өйдән генә түгел, шәһәрдән үк чыгып китә. Ленинград өлкәсенең Красногвардейск шәһәрендә яшәгән Суфиян абыйсы янына барып урнаша. Шунда эшкә керә, ире белән аерылышырга гариза язып җибәрә. Берничә айдан ире аны эзләп таба. Тезләнеп гафулар сорый, тик Зөһрә аны кабул итми. Бала белән аралашуга гына киртә куймый. Әтисе бит! «Алайса мин бала белән урамда йөреп кайтам», – дип, баланы күтәреп чыгып китә ире. Зөһрә эшкә йөгерә. Кайтса, өйдә бала да, ир дә юк. Абыйсы Суфиян белән эзләмәгән җирләре калмый, милициягә мөрәҗәгать итәләр. Тулышып шешкән күкрәкләреннән сөт ага... Зөһрә баласын эзләп Казанга ук кайтып китә. Тик анда да иренең кайда икәнен белүче табылмый. Шулай да берничә айдан эзләп таба ул аны. «Бернәрсә дә кирәкми, баланы гына бир», – дип ялвара ул элеккеге иренә. Һәм җан өшеткеч җавап ишетә: «Мин аны Балалар йортына тапшырдым... Сиңа үч итеп...» Зөһрә улын Казан, Ленинград өлкәсендәге Балалар йортларыннан эзли башлый. Таба гына алмый. Шул вакыт фин сугышына җибәрәләр, аннан соң – Бөек Ватан сугышы... Кайтуга кабат эзләргә керешә. Тик файдасыз. Кабат ирен эзләп таба. Сугыш кичкән ир, күрәсең, акылына килә: Зөһрәдән кабат гафулар үтенә. Баланы чит исем-фамилия белән кайсы Балалар йортына тапшыруын әйтә. Имеш, дөм ятим калган күрше малае, ата-анасы юл фаҗигасендә үлгән... Күпме генә эзләп карасалар да, таба алмыйлар. Дүрт ел барган сугыш Балалар йортларының да астын-өскә китерә. Кая гына җибәрмиләр ул вакытта ятимнәрне... Шулай итеп, өмет киселә. Зөһрә баласын югалта, тик ул гомер буе аның йөрәк авыртуы, җан газабы булып кала. Аның истәлеген гомере буе күңел түрендә саклый. Мәхәббәтен дә шунда бикләп куя. «Әйдә, кабат кушылыйк», – дип, күп тапкырлар эшенә килә яраткан кешесе, тик бала өчен ул аны гафу итә алмый. Бары шуны гына әйтә: «Очрашулар эзләмә! Бала ул – изге. Аңа кул сузарга ярамый».

Сугыш инвалиды Ильяска кияүгә чыга. Үрнәк гаилә булып яшиләр. Бергәләп йорт төзиләр, ике бала үстерәләр... Бөтен яратуын, назын балаларына бирә Зөһрә. Курск дугасындагы бәрелеш вакытында бер аягын төптән үк югалткан элеккеге танкист ире дә уңган кеше була. Протез киеп йөрүгә карамастан, машинада да җилдерә, эштән дә курыкмый. Районда узган мотоцикл узышларында беренчелекне бирми. Протезын яр буена салып калдырып, колачлап йөзәргә дә ярата. Ире машинаны бар тизлегенә куганда кычкырып җырларга ярата Зөһрәсе. Күрәсең, йөрәк ярсуларын әнә шулай басарга тырышкандыр... Соңгы тапкыр Шәйхи белән очраклы гына кибеттә күрешәләр. «Инде балалар урнашкан, оныклар бар. Картлыкны бергә үткәрик. Бергәләп улыбызны эзләп карыйк. Бәлки, табарбыз», – ди ул. Гомере буе җыелган үпкә Зөһрә апаның күз яшьләре булып бәреп чыга:


– Нигә? Нигә хәзер аны эзләргә? Без аны бәхетле итә алмадык. Ул ятим үсте. Әти-әни иң кирәк вакытта янәшәсендә була алмадык. Хәзер ул гаиләледер. Без инде аңа кирәк түгел. Яра салмыйк. Аңа безне гафу итү бик авыр булыр. Ул баланың күзләренә карап нәрсә әйтербез? Үләр алдыннан синең алда гөнаһларыбызны җуяр өчен генә эзләп таптык диярбезме? Мин үз гөнаһым өчен үлгәч үзем җавап бирермен», – ди ул.


«Әни йокысызлыктан интекте. Төннәр буе йоклый алмый йөреп чыга иде», – дип искә ала Лилия ханым. – Яралы җан ничек үзенә тынычлык таба алсын, төннәрен ул яра бигрәк нык сулкылдагандыр шул...»

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛГА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА


2020 елның икенче яртыеллыгы өчен газета-журналларга *Tatmedia.ru* сайтыннан кереп язылу уңайлы. Басма матбугатка *Tatmedia.ru* сайты аша язылу тәртибе






1. *http://tatmedia.ru/podpiska/* сылтамасы буенча «Подписка бүлеге»нә керегез.
2. «Сөембикә» журналын сайлагыз.

3. Китертү юлын сайлап алыгыз.
4. Адрес һәм исем-фамилияне языгыз.
5. Язылу айларын сайлагыз.





6. «Корзина»га керегез, түләү төймәсенә басыгыз.
7. Сайтта теркәлегез (ул бик җиңел) яки авторизация үтегез.

8. Заказны түләгез.

! **ТАТАРСТАНДА** «Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча. Индекс – **П2204** !
! **РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ** «Роспечать» каталогы буенча. Индекс – **73002** !
! **РЕДАКЦИЯДӘ** Килеп алу шарты белән ярты елга язылу бәясе – **330 сум.** !

ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ АЙДАН ЯЗЫЛЫРГА МӨМКИН. ЯРТЫЕЛЛЫККА ЯЗЫЛЫРГА ӨЛГЕРМИ КАЛУЧЫЛАР ҺӘР АЙНЫҢ 15 НӘ КАДӘР ЯЗЫЛЫП, ЖУРНАЛНЫ КИЛӘСЕ АЙДАН АЛДЫРА АЛА.

БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru** ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**
Фейсбукта: **www.facebook.com/syuyumbike** Инстаграмда: **www.instagram.com/suyumbike_journal**

16+
РЕКЛАМА

Аның эчендә гел ут булгандыр. Ул шул уйлары белән яткандыр, торгандыр... Сагынгандыр, саргайгандыр... Билгесезлек әрнеткәндер... Бабам Гордеев Петр Гордеевичның тормыш юлы белән якыннан таныша башлагач шаккаттым: ул бу сынауны ничекләр кичте, гомер буе шушындый газап белән ничек яшәде икән?!





Эльвира
ШАКИРОВА

БЕР МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ ТАРИХЫ

Бабам 1919 елда Мамадыш районының Югары Әрнәш авылында дөньяга килгән, шунда үскән, укыган. 19 яшендә яшьтәшләре кебек үк армия сафларына алынган. Өйдән чыгып киткәндә туган ягына сигез елдан соң гына әйләнеп кайта аласын уйлап та карамагандыр... Башта – фин, аннары Бөек Ватан сугышы, соңрак япон сугышында катнашып, взвод командиры була, офицер дәрәҗәсенә күтәрелә. Соңгы сугышта каты яралана, аздан гына үлми кала. Күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен», «Германияне җиңгән өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнә. Әбием Мария белән алар икесе дә гомерләрен балаларга белем бирүгә багышлыйлар. Бабай – мәктәп директоры, соңрак почта мөдире булып эшли. Өч балаларын тормыш юлына бастыралар. Бабай сәламәтлеген сугышта югалтып кайта. Бик сызланып, 1982 елда арабыздан китеп барды ул...

Бервакыт компьютер артында утырганда әнием яныма килде дә:

– Кызым, беләсеңме, минем бит абыем бар... Геннадий исемле. 1946 елда туган... Аны компьютер аша табып булмыймы икән? – диде.

Телсез калдым... Минем аптыраулы йөземә карап, әни сөйләп китте.

– Әти япон сугышы вакытында каты яраланып госпитальгә эләгә. Һәм шунда ул аякка бассын өчен хирург ярдәмчесе булып эшләүче Полина исемле кыз бик күп көч куя. Әти белән Полина бер-берсенә гашыйк булалар. Бераздан туй ясап өйләнешәләр. 1946 елда уллары Геннадий туа. Бала азрак үскәч, тернәкләнгәч, улы белән хатынын алып әти туган якларына юл тота. Шәмәрдән станциясенә кайтып җиткәч, баласы белән хатынын шунда калдыра да үзе әйберләрен төяргә дип, авылга арбалы ат алып килергә китә. Сигез ел буе аны көтеп елый-елый күзләре дөм сукырайган, чәчләре ап-ак булып агарган анасы, ирләре сугышта үлеп калган, көн-төн колхозда авыр эштә интеккән, «энекәш кайтыр да ярдәм итәр» дип өметләнеп торучы өч бертуган апасы каршы ала аны. Әти авылдагы хәерчелекне, ачлыктан күбенгән туганнарын күреп шакката. Ничә еллар берничек тә аларга ярдәм итә алмавына өзгәләнә. Гаиләдә ир-ат булганнарга яшәү азмы-күпме җиңелрәк булган шул ул чорда... Әтинең хатыны, баласы турында әби ишетергә дә теләми. «Татар авылына урыс кызы ничек ияләнсен? Шәһәр кешесе авыл пычрагына ник төшсен? Марҗа килен мине – сукыр керәшен карчыгын карап ятмас. Су сорап алырлык киленең дә булмагач, нишләргә кирәк? Авылга марҗа ияртеп кайтучы булмаган иде әле! Мәңге ризалыгым юк. Рәнҗешемнән курык!» – ди ул. Анага ничек каршы киләсең – алар бит башкача тәрбияләнгән. Аның фатихасыннан башка яшәп буламы?! Йөрәге ничекләр өзгәләнгәнен бу минутларда әти үзе генә белгәндер... Язмышындагы мондый борылышка ул, әлбәттә, әзер булмый, әмма бу карарны барыбер кабул итәргә туры килә. Ике ут арасында калып, туганнары хакына мәхәббәтеннән баш тартырга мәҗбүр була ул. Барысы да күз ачып йомганчы бик тиз була: әтине, димләп, яшь укытучы кызга – Мариягә өйләндерәләр. Минем әнигә... Полина горур була: ялынып-ялварып аны эзләп килми – бала белән бу йортка аяк басмый. Кире Владивостокка, сугыш вакытында иңгә-иң күеп эшләгән врач-хирург янына эшкә китә. Аралар шулай өзелә... Әти бераздан Полинаны эзләп тә карый, ләкин инде таба алмый.

Ел артыннан ел уза торды, әтинең сәламәтлеге күзгә күренеп начарайды: сугышта алган яралары эзсез узмады, билгеле. Ә күзләре гомере буе гел моңсу кебек тоела иде миңа. Күңеле йомшак булса да, көчле рухлы, гадел кеше иде ул. Әнигә дә беркайчан каты бәрелмәде. Урыннары җәннәттә булсын инде...

Әйтелмичә калган сүзләр ничә еллар йөрәкләрне өшетеп яшәгәндер.



Мин, телсез калып, әни сөйләгәннәрне тыңлап утырдым. Аннан интернет челтәреннән Геннадийны эзли башладым. Әнинең күңелен кызыксыну катыш курку биләп алды. «Бәлки, ул гомер буе нәфрәт белән яшәгәндер... Бәлки, эчкечедер... Бәлки, ул безне күралмыйдыр... Бәлки, ул да эзләгәндер...» – дип сөйләнде ул үзалдына.

– Әни, Гордеев Геннадий Петровичлар монда байтак, кайсысы дип уйлыйсың? – дип, берничә дистә кешенең фотосын ачып куйдым.

– Бу түгел... Юк, бу түгел... Бу да түгел, – дип фотосурәтләрне карый башлады әни. Һәм кинәт: «Шушы! Бу бит әтинең яшь чагы! Коеп куйган әти!» – диде һәм елап җибәрде.

«Исәнмесез, Геннадий! Мин әниемнең абыйсын эзлим. Сезнең биографиягездә Татарстан белән бәйле юллар юкмы?» – дип, беренче хатымны юлладым. Җавап шунда ук килде: «Әйе, минем әтием Татарстанның Кызыл Йолдыз (хәзерге Мамадыш – *Э. Ш.*) районыннан булган...» Ике арада хатлар йөри башлады. Аның югары белемле инженер икәнен, җитәкче урыннарда эшләвен, туганнарын эзләвен, ләкин таба алмавын, Түбән Новгородта яшәвен, ике улы, хатыны барлыгын, иң мөһиме – әнисе Полинаның әле исән икәнен белдек. Инде ике ай буе дәвам иткән язышулар, скайп аша сөйләшүләрнең ахыры очрашуга барып тоташырга тиеш иде. Ләкин Геннадий Петровичның әлеге адымны ясарга икеләнүен сиздек. Бактың исә, бу яңалыкны Полина әбигә әйтергә җөрьәт итмәгән икән әле ул. Әнисе Полина гомере буе бабайга тугры калган, башка беркемне дә үзенә якын җибәрмәгән һәм 60 ел буе аңа карата нәфрәт, ачу белән яшәгән... Шулай да, кыюлыгын җыеп, Геннадий әнисе белән сөйләшә. Полина түтәй бу яңалыкны ишетүгә:

– Синең бернинди туганнарың юк! Хатының Татьянадан кала... Мин риза-бәхил түгел! – дип горур атлап, ачуланып бүлмәдән үк чыгып киткән. Әмма ике көннән улы янына килеп үзе кабат сүз башлаган:

– Улым, мин барын да кабаттан уйладым... Әгәр андый теләгең бар икән, аралаш, ризалыгымны бирәм, – дигән.

Геннадий Петрович гаиләсе белән Казанга килеп төште. Китте туганнар арасында танышу, кунак алышу, аралашу... Чират җитеп Мамадышка кайткач, бабай каберендә ялгызы гына калып зиярәт кылды, күңеленнән, күз яшьләре аша аның белән ниләр хакындадыр сөйләште. Туганнарның туган җанлы-

Ипле, сабыр, мөлаем, тыйнак кеше булып хәтеремдә саклана бабам.



Бабам Гордеев Петр Гордеевич (1919–1982).

лыгына, авыл халкының киң күңеллелегенә таң калып, әтисенең туган авылында бик хөрмәтле кеше булганлыгына инанып, тыныч күңел белән Түбән Новгородка кайтып китте.

Кунак ашы – кара-каршы. Берничә атнадан әниләр, барысы җыенып, Түбән Новгородка юл тоттылар. Полина әби яңа туганнарын җылы каршы ала. Бераз сөйләшеп утырганнан соң:

– Елена, сезнең белән аерым сөйләшеп алырга мөмкинме? – дип, әнине йокы бүлмәсенә алып кереп китә. Әни дә, шуны гына көткән кебек, 87 яшьлек Полина Ивановнага юл буе әзерләп, күңеленнән барлап килгән сүзләрен җиткерергә ашыга:

– Әтием өчен сездән гафу үтенәм, хөрмәтле Полина Ивановна, – ди ул. – Һәм аның рухының шат булып ятуын телим. Әти яхшы кеше иде. Сезне дә йөрәгендә саклагандыр... Аны да аңларга тырышсагыз иде, ул сезне эзләгән, ләкин элеккеге адресыгыз белән тапмаган...

Әтисенең ул чакта әнисе әмерен берничек үтәмичә булдыра алмавын, аны димләп, бу турыда берни белмәгән кызга өйләндерүләрен, аның авырып ятуларын – барысын-барысын әйткән әни. Полина әби дә үз язмышын, башыннан үткәннәрен сөйләп киткән.

– Ачлык, ятимлек ачысын тоеп үстем, – дигән ул. – Әнием минем белән йөкле вакытта әтием вафат булган. Мине тапканда әнием дә үлеп киткән. Гаилә саен бер көтү бала-чага, ачлык, ялангачлык, хәерчелек... Мине бирер кеше тапмаганнардыр инде: бәлки, монысы да үләр дип, салкын мич алдына куеп чыгып киткәннәр. Елаганмын да елаганмын... Шуннан, җәлләп, күршеләр үзләренә алып чыккан. 6 яшемә кадәр авылда өйдән өйгә йөреп үскәнмен – мине бөтен авыл караган.

Көннәрдән бер көнне авылга укытучы кыз килә, һәм мине үзенә ала. Укырга-язарга өйрәтә. Озакламый бер хәрбигә кияүгә чыга, һәм мине дә алып, Владивостокка китеп баралар. Шунда мин шәфкать туташы булырга укыдым. Япон сугышы вакытында Петр каты яраланып, мин эшләгән госпитальгә эләкте. Шунда без аның белән таныштык... Улыбыз Геннадий тугач бик сөенде. Ул терәкләнеп беткәч, безгә Петрның туган ягына кайтырга рөхсәт бирделәр. Ләкин Шәмәрдән станциясендә Петр безне калдырып китте дә, яңадан килеп алмады. Аның кыз туганнары килеп, мине поездга утыртып җибәрделәр... Владивостокта бераз эшләгәч, аякка баскач, үземнең туган якларыма, дус кызым янына кайтырга булдым. Шулай итеп, Түбән Новгородта төпләндем. Балам ятимлектән читенсенмәсен өчен барысын да эшләдем. Югары белем алсын дип тырыштым. Аллага шөкер, ул минем йөземә кызыллык китермәде. Геннадийның туганнары булуына мин бик шатланам...

Полина әби күз яшьләренә буыла:

– Я отпустила, отпустила, отпустила его, – дип бертуктаусыз кабатлый ул.

Шулай итеп, алтмыш ел буе җыелып килгән ачу-нәфрәт таралды... Ә бу вакыйгалардан соң һәркемнең күңеле тынычлап калды, күп сорауларга ачыклык кертелде. Түбән Новгород белән Казан арасында ныклы туганлык күпере салынды: дүрт бертуган бәйрәмнәрне бергә уздыру гадәтен керттеләр. Алар гына түгел, без – балалары да якыннан аралашып яшибез.

Берничә айдан Полина әбинең йөреп торган җиреннән кинәт үлеп китүе турында хәбәр килеп ирешә. Тыныч күңел белән бакыйлыкка күчкәндер диясе килә.

Петр бабамның да, Мария әбиемнең дә, Полина әбинең дә рухлары шат булсын иде.

Бу хәлләргә аларның берсе дә гаепле түгел. Язмыш бу...

48 нче биттәге фотода: Полина Гордеева (7.11.1923–6.06.2013) улы Геннадий белән.

ТААРУГА – ТАУ ЧӘЧӘГЕ

Тиздән, бик тиздән җәй җитәр. Бар дөнья яшеллеккә, чәчәккә күмелер. Бар да үзгәрер... Табигать белән бергә һәр хатын-кызның да үзгәрәсе килү теләге табигый ул: чибәррәк, матуррак, сылурак күренәсе килә. Кызганыч, әлегә кибеттән кибеткә йөреп җәйгә яңа күлмәк сайлый алмыйбыз... Әмма күңелне төшерергә кирәкми! Теләгән кешегә мөмкинлекләр һәрчак табыла! «Тааруга» авторлык остаханәсе безгә үзләренең www.taaruga.com сайтында урнашкан интернет-кибет хезмәтеннән файдаланырга тәкъдим итә. Сатып алучыларга җайлы булсын өчен сайтта үлчәмнәр таблицасы да бар.

ЗАКАЗНЫ НИЧЕК ЯСАРГА? АНЫҢ ИКЕ ТӨРЛЕ ЮЛЫ БАР.

Беренчесе:

1. «Каталог» дигән бүлектән үзегезгә ошаган кием-салымны сайлагыз һәм «Кәрзингә» («В корзину») дигән төймәгә басыгыз: өстә – менюның «Кәрзин» («Корзина») дигән графасында сезнең ничә әйбер сайлавыгызның саны күренер. «Кәрзин» («Корзина») дигән төймәгә бассагыз заказыгызны тулысынча күрә алырсыз.
2. Заказны тагын бер кат тикшерегез. Барысы да дөрес икән, «Заказны җибәрергә» («Отправить заказ») дигән төймәгә басыгыз.
3. Заказ формасын тутырыгыз.
4. Үзегез турындагы мәгълүматларны: телефон номерын, адресыгызны язарга онытмагыз.
5. Комментарийда сезгә киемнең нинди төслесе кирәген языгыз. Тагын нииндидер теләкләрегез бар икән – аларны да өстәгез.
6. «Җибәрергә» («Отправить») төймәсенә басыгыз.
7. Заказыгыз кабул ителде! Бер тәүлек эчендә менеджерыбыз сезнең белән элемтәгә керер: йә шалтыратыр, йә хат язар – көтегез!

Икенчесе:

Күзегез төшкән кием-салымга taarugashop@mail.ru адресы белән безнең электрон почтага язып та заказ бирә аласыз. Хатыгызда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:
1. Телефон номерыгыз, өй адресыгыз.
2. Сайлаган кием-салымның исеме (нәкъ сайтта күрсәтелгәнчә).
3. Сайлаган әйбернең төсе.
4. Сайлаган әйбернең саны.
5. Заказны илтеп җиткерү ысулы.

Менеджерыбыз бу очракта да сезнең белән элемтәгә керәчәк һәм заказ буенча туган сорауларын ачыклаячак.

Модель: К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Резеда Сәлахова.

мастерская
Тааруга

Кибетнең адресы: Казан шәһәре, Бауман ур., 51/50 нче йорт, ГУМ.

www.taaruga.com

ok.ru/taaruga

instagram.com/taarugashop

vk.com/taaruga

РЕКЛАМА



ТОЗАК



«Казанда яшәүче 34 яшьлек ханым март башында гына интернет аша аралаша башлаган танышына 3 мең доллар акча күчергән».
Матбугатта күптән түгел күзгә чалынган яңалыкларның берсе бу. 3 мең доллар! Ир-ат үзен Америка армиясендә хезмәт итәм дип таныштыра, «Әле Әфганстанга командировкага җибәрделәр», – ди. 9 март көнне инде ул бурычка акча сорый. Аның кадәр акчам юк дигәч, «Бәлки кредитка алырсың? Россиягә килүгә, бурычымны кайтарачакмын», – ди. Акча исәп-хисап счетына күчүгә, ир социаль челтәрләрдән югала... «Минем белән мондый хәл булмас дип, хатын-кызларның берсе дә әйтә алмый», – ди психолог Зөлфия МАКСУТОВА. Әгәр социаль челтәрләрнең берсеннән сезгә таныш түгел кеше яза башлаган икән, иң элек нәрсәләргә игътибар итәргә, нәрсәләрдән шикләнергә – ул шулар хакында сөйли.

АВАТАРКА. Яңа танышыгызның кем икәнлеген ачыклауны аватаркасын өйрәнүдән башлагыз. Фото урынына йә берәр җанвар, уен карталары, йә табигать күренеше, йә бик затлы машина, атаклы берәр актер фотосы, компьютер уеннарындагы берәр куркыныч персонаж куелган икән – шикләнергә урын бар. Димәк, бу кеше, үзе турында нәрсәдер яшерә. Юлбарыс, арыслан кебек ерткыч хайваннар торса, бигрәк тә игътибарлы булыгыз. Аватаркага үзен түгел, ә билгеле берәр актерның фотосын куя икән, үзен башка берәү итеп күрсәтәсе килә. (Без бөтен актерларны танып бетермәскә мөмкин бит – ул шуңа өметләнә.)

Күпләр аватаркага яшь чактагы фотосурәтен урнаштыра. Бу очракта шикле: кеше нидер яшерә. (Безнең кызлар белән танышырга теләгән өлкәнрәк төрек, гарәп ирләре күп очракта шулай эшли.) Еш кына хат алыша башлагач та, йә яшь чактагы фотоларын, йә берәр артист фотосын җибәрүчеләр бар. Шундый очрак булды, «мин Төркиядә яшәүче татар» дип, бер таныш кызга Камал театры артисты фотосын җибәрделәр.

Әгәр ир-ат профессиональ фото җибәрә икән, моңа да игътибар итәргә кирәк. Яңа танышыгыз, чыннан да, актер, йә зур урынны биләүче җитәкче булмаса, әлбәттә. Тик үзегез дә аңлыйсыздыр – андый шәхесләр танышу сайтларында утырмый. Сез шикләнмәсен өчен, «бу – мин», дип, ул хәтта берничә фото да җибәрергә мөмкин: артистларның фотосурәтләрен интернеттан табу авыр түгел бит хәзер. Тик менталитет башка икәне, гадәттә, йөздә барыбер чагыла. Фотодагы кешенең киеме дә, машинасы да «люкс» икәнен дә аңлау авыр түгел.

ПРОФИЛЬ. Кешенең социаль челтәрләрдәге профиле буенча да аның турында бик күпне сөйләргә була. Монда нюанслар бик мөһим. Әгәр анда бер мәгълүмат та юк, аккаунт әле генә ачылган икән – бу беренче шикле билге. Мондый профильдә исемнәр сәер булырга мөмкин: әйтик, Алмаз яки Тимур түгел, ә «Серый волк», «Принц» яки билгеле шәхесләр исемнәре тора. Кемдер яки нәрсәдер артына яшеренгән (димәк, яшерер нәрсәсе бар!) кешеләр белән аралашмавың хәерлерәк.

Кайбер ир-атларның аккаунтына керәсең, карыйсың: чип-чиста, үзе хакында бернинди мәгълүмат юк. Йә берәр зур йорт, бик матур йокы бүлмәсе, йә яхшы машина, йә йорт төзелеше рәсеме генә куелган. Дуслары исемлегендә исә гел хатын-кызлар гына. Әмма хатын-кыз, гадәттә, дуслары арасында кемнәр бар дип карамый, аның күзе беренче чиратта шул рәсемдәге зур өйгә, машинага гына төшә. Манипулятор исә барысын да белеп эшли – ул кызларның хыялы өлкәсенә күчә: сез нәрсә телисез, янәсе. Ә безгә, билгеле инде, йорт, гаилә кирәк, матур йокы бүлмәсе, машина...

Профиль чын булган чаклар да бар. Бу очракта кеше нәрсә яза, шуны карагыз. Репостларына игътибар итегез: алардан да кешенең кем икәнлеген, чынмы-түгелме икәнен чамаларга була.

Мин әйткәннәрне кызлар әниләренә генә түгел, егетләрнекенә дә белеп тору кирәк – манипулятор кызлар да байтак.

Әйтик, үзе нидер язмаса да, кемдер билгеле бер темага репостлар күп ясый, димәк, ул шушы юнәлештә эшли яки шушы тема белән кызыксына. Дизайнер икән, үз эшләрен куя, иҗатташларының эшләрен урнаштыра. Карыйсың да аңлыйсың, бу – чын кеше. Ә кемнеңдер аккаунтында гел шигырьләр яки акыллы кешеләрнең фикерләре, матур табигать рәсемнәре генә. Аларны исә төрлечә аңларга, кабул итәргә була. Бу очракта серлелек төтене шушылай тудырыла.

ЯЗУ СТИЛЕ. «Юк» дип кире борсагыз да, ул сезгә башка исем артында яза башларга мөмкин. Хәтта башка социаль челтәрләрдән. Әмма игътибарлы булсаң, мондый кешеләрне язу стиле буенча барыбер ачыкларга мөмкин.

Беренче җөмлә һәркайсыныкы үзенеке, әлбәттә. Алар гадәти булмаган фразалар куллана беләләр. Әйтик: «Сәлам, мин синең булачак ирең!» яки «Сагынам... синең булачак ирең», – дип язалар. «Кара, ничек кызык!» – дибез. Әңгәмә шулай башлана... Дөресен әйтик, «Әйдәгез, танышыйк!» – дип кенә мөрәҗәгать итсә, җавап бирмичә генә узу ихтималыбыз зур бит. Ә ул шунда ук: «Син миңа ошыйсың!» – ди. Син гаҗәпләнеп каласың һәм... җавап бирәсең. Яки беренче җөмләдән үк комплиментлар яудырырга керешә: «Шундый чибәр, гүзәл, ягымлы ханым белән танышырга мөмкинме?» Күзгә төтен җибәрә белә! Алга таба тагын да кызыграк булачак! «Смс» яңгыры явачак! Көннәр генә түгел, төннәр буе. Аралашуның башында алар Голливудның идеаль героен хәтерләтә. Хатын-кыз үз бәхетенә үзе ышанмый: мине аңлаган кешене, ниһаять, таптым, ди...

Аз гына тын алып, ул алдарак язганнарга кабат күз салыгыз. Хәбәре өзек-өзек түгелме? Ике-өч сүздән генә тормыймы? Фактлары туры киләме? (Дөреслекне без, гадәттә, беләбез, ә ничек ялганлаганны хәтерләмибез!)

ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ. Җөмлә ахырында һәрвакыт күп ноктаклар куярга яратучылардан шикләнегез. Әгәр ул аны һәр җөмлә артыннан тезә икән, димәк, бу кеше үзе өчен сезнең уйлап бетерүегезне тели. Аннан шизофрениянең бер билгесе дә булырга мөмкин: андыйлар күп ноктаны җөмлә башында да куярга ярата.

Өндәү билгеләре күп булу да сезне шикләндерергә тиеш. Күп сүзләрне тулысынча баш хәрефтән язу да: димәк, бу кеше нәрсәдер турында «кычкыра», аны ишетүләрен тели. Һәрвакыт «кычкыру» исә шулай ук дөрес түгел.

Манипуляторны җөмлә ахырында ике нокта куюыннан да танырга була. Кайчак нокта ялгыш та куелырга мөмкин, әлбәттә. Әмма әледән-әле кабатлана икән, икеләнмәсәгез дә була, бу – манипулятор. Димәк, ул бу фразага игътибар итүләрен тели. Икенче сәбәп – нәрсәнедер әйтеп бетерми яки ялганлый.

СЕЗНЕ ҮЗЕНӘ ИЯЛӘШТЕРӘ. Башта, әйткәнемчә, «смс» яңгыры явачак, шалтыратулар башланачак: сезне үзенә бәйләп кую өчен ул барысын да эшләячәк. Профессиональ манипулятор күп мәгънәле фразалар кулланырга ярата: аларны болай да аңлап була, тегеләй дә. «Тәрәзәгә карап басып торам, сагынам», – дип яза ул. «Мине сагына!» – дип уйлый хатын-кыз. «Кыш, салкын, җылы җитми», – дип яза ул. «Миннән җылы көтә!» – дип сөенә хатын-кыз...

Фото: www.pixabay.com

PRESSA

Интуиция мондый моментларны бик тиз сизә, без генә аны тыңламыйбыз: нәрсә күрергә телибез, шуңа ышанабыз.

ВАКЫЙГАЛАРНЫ АШЫКТЫРА. Сез әле аралаша башладыгыз гына, табигать, һава торышы турында гына сөйләшәсез, ә ул: «Мин, ниһаять, үземнең идеалымны таптым», «Мин сине шундый озак эзләдем!» – дип яза. «Мондый хатын-кыз башка юк, сез бердәнбер», – ди. «Син башкаларга охшамаган!» – ди. Телефоннан: «Миңа кияүгә чык», – дип тә әйтергә мөмкин... Хәтта шикләнмәгез дә: сезнең каршыда – манипулятор. Нормаль кеше болай эшләми. Тик бер нәрсәне онытмагыз: болар сүз генә сөйли, эшкә күчми.

ИНТИМ ТЕМАЛАРГА КҮЧӘРГӘ АШЫГА. Әле сез таныштыгыз, аралаша гына башладыгыз, ә ул инде интим сораулар күтәрә. Интим фото, видео сорый – сүзе гел шул тирәдә әйләнә. «Ашыгасыз түгелме?» – дип әйтсәң, «гафу», ди дә, әмма үзе бераздан тагын шул эзгә кайтып төшә. Сез әле аның йөзен күрмәгән, хәтта тавышын да ишетмәгән, ә ул җенес органнарын фотога төшереп җибәрә.

СЕЗНЕҢ БЕЛӘН САНЛАШЫП ТОРМЫЙ. Әйтик, сез инде йокларга ятасыз, ә ул ватсаптан шалтырата. Сезнең киңәшмә бара, ә ул бертуктамый элемтәгә чыга. Ярыймы дип сорап та тормый. Телефон номерыгызны үзе табып та шалтыратырга мөмкин.

КОНКРЕТ СӨЙЛӘМИ. Язганнарын кабат укып карагыз, ул күп яза, матур яза, әмма анда конкретлык юк икән, бу – манипулятор. Гел гомуми сүзләр! Ул хатын-кызга үзенә уйларга, хыялланырга урын калдыра. (Ә без хыялланырга яратабыз!) Хатын-кызга ни кирәген ул яхшы белә. «Мин монда йорт төзим, – дип яза ул. – Кухням 25 квадрат метр булачак. Синеңчә, ничек, кечерәк түгелме? Бервакытта да: «Синең белән минем өчен бу кухня кысанрак булмасмы?» – дип өздереп сорамый, ә хатын-кыз инде үзен шул кухняда итеп күрә – ашарга пешерә, янында балалар йөгереп йөри... Хатын-кыз нәрсә ишетергә тели – ул шуны сөйли. Чынлыкта йорт булырга да мөмкин, булмаска да. Хатын-кызның яше утыздан өстә икән, ул, һичшиксез, балалар турында сүз кузгата: «Кызың да (улың да) синең кебек чибәр булачак», – ди. «Безнең балалар», – дими. Гомумән, «без синең белән» дип сөйләшми.

БЕРКАЙЧАН «МИН» ДИП СӨЙЛӘМИ. Мин уйлыйм, мин киттем, мин барам дип язмый ул. Мин сине яратам дип тә язмый, «яратам» гына ди. Күп вакыт өченче затка күчеп сөйләшә: мин эшлим дими, Руслан аны эшләр, ди. Ихлас кеше болай сөйләшми.

Ул сезгә исем белән дәшмәскә тырыша. Куяным, матурым дияргә мөмкин. Яки «принцесса» дип кенә атый. Әгәр әңгәмәдә шушы күренеш күзәтелә икән, димәк, сезгә карата көчле манипуляция техникасын инде кулланалар дигән сүз. Кеше өчен аңа исем белән дәшүләре бик мөһим бит. Исем белән дәшү, без, димәк, таныш, бер-беребезгә якын дигәнне аңлата. Ә андый кешене рәнҗетү авыррак булачак. Бер танышымның: «Ике ел инде берәү белән аралашам. Аның ялгыш та исемем белән дәшкәне юк, «кадерлем» дип кенә әйтә. Бу дөрес хәлме?» – дип мөрәҗәгать иткәне булды. Утырып сөйләшкәч ачыкладык, ул кеше – манипулятор.

ОЧРАШЫРГА АШЫКМЫЙ. Танышканнан соң ике атна узгач та очрашу турында сүз башламый икән, шикләнергә урын бар. Кайда гына яшәсә дә, башка шәһәрдәме, чит илдә үкме, гадәттә, ир-ат сине ошата икән, якыннан күрәсе килү теләген белдерә. Ә манипулятор төгәл датаны беркайчан әйтмәячәк – гел сузачак. Әбием авырый, эштән китә алмыйм... Мең сәбәп табачак!

Танышу сайтларында сезнең белән беркайчан очрашырга җыенмаган ир-атлар бик күп. Алар өчен язышу, аралашу гына кирәк – күбесе күптән инде өйләнгән. Бер кыз, мәсәлән, шундый манипулятор белән дүрт ел язышкан! Казанда булган хәл бу. Якынаймыйча да, ерагаймыйча да, сине шулай гел билгесезлектә тота ул. Исәнлегеңне, тынычлыгыңны, елларыңны урлый. (Алайса араларны өзәм, дисәң, кулга кергән кош ычкынмасын дип, бер килеп күренергә дә мөмкиннәр.)

ЯКЫН-ЕРАК ТЕХНИКАСЫ. Беркайчан ишетмәгән комплиментлар ишетәсез, ул сезне күкләргә күтәрә. Аякларың матур, ди, тавышың... «Ниһаять!» – дип уйлый хатын-кыз. Ә ул... кинәт югала. Аңлатмыйча, әйтмичә. Сез язганнарга җавап бирми, элемтәгә чыкмый. Аннан, берни булмагандай яңадан пәйда була. Сез җиңел сулыйсыз... Яңадан шул ук сораулар башлана: матурым, сагындым, миңа синең белән рәхәт... Нигә югалып тордың, дигән сорауны йә бөтенләй җавапсыз калдырачак, йә бик озаклап нигә җавап бирмәгәнен сөйләячәк: эштән чыккан, юлны узган, мәчене бәрдергән, аның белән ветеринарга киткән... Ә аннан... тагын югалачак. Бу хәл кабатлана икән, димәк, сез – манипулятор кулында: ул «якын-ерак» техникасын куллана.

ГЕЛ КӨТМӘГӘНДӘ ЯРСЫЙ БАШЛЫЙ. Гап-гади бер сүзегездән дары кебек кабына – сез үзегезне гаепле хис итсен өчен эшләнә бу. Әйтик, «Коену костюмыннан берничә селфи ясап җибәр», – дип сорый ул. «Юк», – дисәң,

шундук ярсый, «Аралашасым килми синең белән», – ди һәм... югала.

«Нәрсәне дөрес эшләмәдем икән?» – дип уйлый хатын-кыз. Ул бит аның үзенә берөзлексез соклануын әле хәтерли: хәзер ярату сүзләрен әйтми икән, димәк, үзем гаепле дип саный. Үземне яхшырак тотарга кирәк, ди һәм бераздан ул табылуга аңа ярарга тырыша башлый. Гафу үтенә! «Ярый, ярый, фотомны җибәрәм», – ди. Интим фотоларын да сала, акча да...

ХАТЫН-КЫЗНЫ ШӘХЕС БУЛАРАК ЮККА ЧЫГАРУ, ТҮБӘНСЕТҮ БАШЛАНА. Башта сезне күтәрә, аннан түбән төшерә – кимчелекләр таба. Йә эшеңне, йә сөйләшүеңне ошатмый. Түбәнсетергә сәбәп эзли, тәнкыйтьли башлый икән – манипулятор белән аралашасыз дигән сүз.

«Эмоциональ таган» техникасы куллануы да шул хакта сөйли. Йә ул сезне кимсетергә керешә: «Миннән башка син кемгә кирәк?», «Сиңа тагын кем карасын?» «Бала белән сине кем алсын?» – ди. Үпкәләсәгез, баштагы шоу кабатлана: «Принцессам, чибәрем, ярый очрадың...» Ә аннан тагын өстегезгә пычрак коя... Нинди генә очракта да без барыбер ул кешене уйлыйбыз. Һәм ничек уйлаган очракта да, аңа гашыйк булабыз... Хатын-кыз бу мөнәсәбәтләрдән җиңел генә котыла алмый. Хәтта бик көчлеләр дә.

Гөлнур САФИУЛЛИНА әзерләде.

ЗӨЛФИЯ МАКСУТОВА КИҢӘШЛӘРЕ

– Манипулятор, дип, үзе бернәрсә дә бирмичә синнән нәрсәдер алырга теләгән кешегә әйтәләр. Өлкән яшьтәге ир-ат яшь кенә кызны шушы тозакка төшергән икән, ул бары шушы аралашудан тәм ала. Ә хатын-кызның күңелен аздыру, аны вәсвәсәләндерү белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнүче ир-атка – пикаперга синнән йә акча, йә секс кирәк. Сиңа күпме авыррак – аңа шуның кадәр яхшырак. Синең белән идарә итә алудан ул тәм таба. Әйтик, аның өчен син ваза кебек. Вазаны ватсаң, аңардан гафу сорамыйсың бит, кызганыч, әлбәттә, әмма сатуда башкасы да бар. Монда да шулай.

Интернет аша танышканда бик сак, бик игътибарлы булырга кирәк. Хатын-кыз һәрвакыт ак атка атланган принц көтә. Һәм мөнәсәбәтләр башлангач та, гадәттә, бик күп әйберләргә күз йома. Нәрсәнеңдер дөрес түгел икәнлеген акылы белән аңлый, әмма аңа мәхәббәт кирәк, наз, сөю...

Алар башта сезнең арттан күзәтәләр, социаль челтәрләр аша өйрәнәләр. Кем белән аралашасыз, нәрсә белән кызыксынасыз? Кемгә лайклар куясыз? Сезгә кемнәр куя? Үзегез турында социаль челтәрләрдә ни сөйлисез? Ә без анда бик күпне сөйлибез... Алар бу мәгълүматны җыялар, ә аннан беркөнне «ишегегезне шакыйлар»: сезгә сезнең хакта сөйли башлыйлар. Бәлеш пешерергә яратасыз икән, «иң яраткан ризыгым бәлеш», диләр. Тенниска йөрисез икән, «мин дә зур тенниска гашыйк», диячәк. Ялгыз икәнсез, моны социаль челтәрләрдә сиздермичә калмыйсыз, ә алар мондый авырткан нокталарны бик тиз таба. Димәк, анда артыгын сөйләмәскә, язмаска кирәк.

Хатын-кызга серлелек кирәк, ул гел шуны эзли. Принцның да ак аттагысы гына түгел, ә романтигы кирәк аңа. Без бит романтик китапларда, фильм-сериалларда, җыр-шигырьләрдә тәрбияләнгән. Гап-гади ир-атның: «Сәлам, әйдә, танышабыз», – дигән сүзе яныннан, әйткәнемчә, узып кына китәбез. Бу безгә кызык түгел. Ә чын ир-атлар, гадәттә, бераз кызыксызрак була.

Ир-атка хатын-кызның күңелен аздырырга өйрәтүче махсус курслар бар. Мондый пикап курсын узучылар – профессиональ манипуляторлар. Алар инде хатын-кызның кайсы ноктасына басарга кирәклеген яхшы белә. Ә ул нокталар барыбызда да диярлек бар безнең... Аерылышкан хатын-кызны кулга төшерү дә берни тормый аларга. Гомумән, теләсә кайсыбыз бу тозакка эләгергә мөмкин. Бер мисал. Төрмәдә утыручы бер ир-ат танышу сайтында берьюлы өч хатын-кыз белән хат алыша. Һәрберсенә өйләнергә вәгъдә итә. Утырганын да яшерми. «Ялгышлык белән эләктем, чыгар өчен залогка акча кирәк», – ди. Казаннан бер ханым 1 миллион күчерә, икенчесе тагын 1 миллион. Ә югары уку йортларының берсендә юридик факультетта укыткан ханым фатирыннан ук мәхрүм кала. Мөнәсәбәтләр шактый җылы була бит, хатын иргә үзенең интим видеосын җибәрә. Ә акча сораганнан соң, хатын: «Юк, җибәрә алмыйм шул», – дигәч, ир янауга күчә: «Алайса бөтен студентларыңа интим видеоңны салам», – ди. Фатирын сатып, 3 миллион күчерергә туры килә аңа... Акылсыз дияргә ашыкмагыз. Мондый ир-атлар акыллы, кызыклы хатын-кызны гына сайлый. Бернәрсә бирә алмаган, гади, бәхетсез хатын аларга кирәк түгел. Ул сезнең йә элемтәләрегезгә, йә акчагызга, талантыгызга, йә чибәрлегегезгә күз төшерә. Менә ни өчен ул кулланган барлык ысулларны белеп тору кирәк тә безгә. Әгәр ул бертуктамый зарлана башласа (үзем авырыйм, әни авырый, больницага ятам), димәк, тиздән сездән акча сораячак. Безгә бит аның мәхәббәтен яулап алу кирәк, шуңа күрә: «Мин ничек сиңа ярдәм итә алам?» – дибез. Билгеле инде, акча белән!

Мондый тозакка эләгүеңне иң элек организм сизә. Әгәр кеше белән аралашканда косасы килә, йөрәк кага, баш авырта, температура күтәрелә, уч табаннары тирли, йокысызлык интектерә, бер сәбәпсез йә ябыгасың, йә тазарасың икән, болар барысы да интуиция биргән сигналлар – ул сине, манипулятор белән аралашасың, дип кисәтә. Бер кызның: «Интернеттан Мәскәү егете белән таныштык, бер ай инде йокысызлыктан интегәм», – дип әйткәне бар. Димәк, бу кешедән табаныңны ялтыратып качарга кирәк.



ҖИР АРТЫНДАГЫ ҖИР



Алсу ХӘЛИМОВА

Бу – гаҗәеп сәяхәт булды. Утрау ягыннан төлкеләр һәм аюлар күренеп ала, Тын океаннан башларын гына чыгарып тюленьнәр безне күзәтә – аларны шаярып «япон шпионнары» дип атыйбыз, ә күктә канатларын җәеп ак җилкәле диңгез бөркетләре оча...

Сүзем Курил утрауларының иң көньяк ноктасы – Кунашир утравы турында. Бирегә кемнәр элегрәк килеп урнашкан: русларммы, японнармы – бәхәсле сорау. Дүрт утрау – Кунашир, Итуруп, Шикотан, Хабомаины кайтарып алу Токио өчен абруй мәсьәләсе. Курил утраулары кире кайтарылмый торып, икенче Бөтендөнья сугышы алар өчен тәмамланмаган санала. Япония премьер-министры Синдзо Абэ Россия Президенты Владимир Путин белән сөйләшүләргә килгәч, бу очрашуны минем кебек тын да алмый күзәтүче тагын булдымы икән?!

А. П. Чеховның «Сахалин утравы» китабы күпләргә таныштыр. 1890 елда Антон Павловичка Мәскәүдән Сахалинга барып җитү өчен поезд, пароход, көймә, атлар ярдәмендә 81 көн юлда булырга туры килгән. Ә безне хәзер очкыч Мәскәүдән Сахалинга – җир читенә 8 сәгатьтә илтеп җиткерә.

Менә ул – Җир артындагы җир! Бу якларда Россиянең дәүләт чиге уза. Шуңа да Курил утрауларына бару өчен Сахалин чик буе идарәсеннән погранпропусклар алырга кирәк. Корсаков портында таможня контроле үтәбез һәм «Игорь Фархутдинов» теплоходына утырабыз. Ул бозлар арасында йөзә алырлык куәтле судно. (Беләсездер инде, Игорь Фәрхетдинов 1995–2003 елларда Сахалин өлкәсе губернаторы булып эшләде. Аның тамырлары Татарстанның Балтач районына барып тоташа. Вертолет һәлакәтендә вафат булган губернатор исеме белән 2004 елда – теплоход, 2017 елда Кече Курил тезмәсенең моңарчы исемсез булган бер утравы аталды.)

Кунашир утравында Курил тыюлыгы урнашкан. Ул 1984 елда оешкан. Утрауның көньягы һәм төньягы тыюлык территориясе санала һәм анда эләгү өчен тыюлык администрациясендә пропуск рәсмиләштерергә кирәк.

Утрауның бер як ярын – Охот диңгезе, икенче як ярын Тын океан сулары юа. Һава шартларының ике ярда ике төрле булуы турыдан-туры шушыңа бәйле.

Төнлә төлкеләр палатканың тамбурыннан әйберләреңне урлап качарга да күп сорап тормый.

22 кешелек төркемебез өчен поход нәкъ менә Тын океанның кара комына аяк басудан башлана. Тын океан ярында кайнар чыганаклар бар. Алар бассейн рәвешендә. Ул суда ярты сәгатьтән да артык торырга ярамый. Кайнар судан чыгасың да салкын океанга чумарга дип йөгерәсең. Җан рәхәте! Ләкин кузгалырга кирәк, алда безне ике көнлек юл һәм вулканга менү көтә. Ул арада яңгыр да ява башлады. Аяклар комга бата. Авыр рюкзаклар белән юеш комнан атлап бару үзе зур сынау.

Төннәрен палаткада океан шавын тыңлап ятам, әйтерсең кайдадыр урман артында тимер юл составлары үтеп бара. Исеме генә тын шул, ә җисеме...

Бу утрауда төлкеләрне эзләргә кирәкми, алар сине үзләре эзләп таба. Көндез үзләрен, төнлә караңгыда ялтырап торган күзләрен күрергә күнегеп бетәбез.

Вулканга менәр көн дә килеп җитә. Тятя – дөньядагы иң матур вулканнарның берсе. Ул үзенең формасы белән вулкан эчендәге вулканны хәтерләтә. Аяз көнне утрауның кайсы җирендә генә булсаң да аны күрергә мөмкин. Вулканга менеп төшү өчен унике сәгать кирәк. Алдагы көннәрдә арыганлык үзен сиздерә: төркемдәге 22 кешенең 10 ысы гына өскә менеп җитә ала. Вулкан әле дә актив. Югарырак күтәрелгән саен, аяк астындагы җирнең кайнаррак булуын тоясың. Ул тере, ул сулый... Болытлар гына, бетергеч кәгазьне чистарткан сыман, җир белән күк арасын агарта баралар.

1983 елда биредә вертолет һәлакәткә юлыга. Көчле җил аны утрауның каршы ягыннан вулкан ягына алып китә. Вертолет 1750 метр биеклектә очкан, ә Тятяның биеклеге 1819 метр. Әйе, берәү дә исән

■ Утрауның мәйданы 1490 кв. км тәшкил итә. Кунашир айннар теленнән «кара утрау» дип тәрҗемә ителә. Ылыслы кара урманнарында, кара җире һәм кара комлы ярларында, кара шлаклы вулкан конусында чагылыш таба ул төс. Хәтта кайнар чыганакларның суы да көмеш бизәнү әйберләрен кара төскә кертә. Кунаширда үзебез тоткан горбуша, кета балыкларын учакта пешерү, тозлау серләренә төшендек. Безне гел күзәтеп торган тюленьнәр дә балык ярата икән. Балыкчыларның җәтмәләренә даими рәвештә зыян салып торалар. Бу акыллы хайваннарны куркыту өчен төрле җайланмалар уйлап табарга, хәтта фәнни институт хезмәткәрләрен дә җәлеп итмәкче булалар.












Автор фотолары

Бу якларның географик киңлеге – Кырымныкы, ә озынлыгы Колыманыкы дип юкка гына әйтмиләр.





калмый... Егылып төшкән вертолет әле һаман да югарыда, фаҗига урынында ята. Аңа аркан бәйләнгән, күпмедер араны шуңа тотынып менәбез. Аңа кадәр, 1975 елның кышында да шундый ук һәлакәт була. Паникага бирелгән пассажир вертолеттан чыгып түбәнгә төшә башлый, ләкин юлны таба алмый. Җылы вулкан шлагына күмелү генә аңа гомерен саклап калырга ярдәм итә. Курил вулканнары авиация өчен куркыныч: бу очраклардан соң вертолетларга утрау эченә кермичә, диңгез яры буйлап кына очарга рөхсәт ителә.

Рәсми мәгълүматлар буенча Кунаширда 70–80 ләп аю яши. Поход дәвамында иң күп кабатланган авазлар «э-хе-хей...» булды. Аюларны куркыту өчен шулай тавышланып йөрү кирәк. Алар безгә өч тапкыр очрады. Аюны күргәч, кычкыру һәм сызгыруның кульминацион өлеше башлана: әйтерсең лә яраткан командаң көндәшләренең капкасына туп керткән. Аюларга Кунаширда ризык җитәрлек. Елгаларда балык күп. Су чигенеше вакытында океан ярында күпләп суүсемнәр, кысласыманнар, моллюсклар, медузалар, диңгез керпеләре, диңгез йолдызчыклары кала. Океан ярында җәтмәләр, юан баулар, төзелеш материаллары һәм башка күп кенә әйберләр табарга мөмкин. Кибеттәге сыман, һәр иртәдә яңа товар, давылдан соң – распродажа. Хәтта бер пыяла шар да таптык. Ул кухтыль дип атала, безнеңчә, җәтмәләр өчен калкавыч. Аларның узган гасыр башында Японияда җитештерелгән булуы турында безгә соңрак Көньяк Курильск музеенда әйттеләр һәм шундый ук сихри шарларны күрсәттеләр. Вакыт узу белән пыялага алмашка башка материаллар килгән, шуңа да хәзер пыяла кухтыльләр зур табыш санала. Ул шарлар эчендә шул заманның һавасы сакланып калган.

Сәяхәтебезнең икенче өлеше Охот диңгезе ярларында үтә. Чираттагы вулкан бөек рус сәяхәтчесе Василий Михайлович Головнин исеме белән аталган. Хоккайдо утравында ике елдан артык японнарда тоткын булып яшәүгә карамастан, ул каршы якның зур ихтирамын яулый. Аңа хәтта Японияда һәйкәлләр куелган. Әнә ул Хоккайдо, 40 чакрымда гына. Головнин вулканы (541 м) – утрауның иң борынгы вулканнарыннан берсе. Аның кальдерасы моннан 39 мең ел элек барлыкка килгән. Кальдерада ике күл бар: «Кипящее» һәм «Горячее». Беренче күл кайнап тора, андагы температура урыны белән 100 градуска җитә. Ул кургаш төсендә. Икенчесе ачык зәңгәр төстә, анда су керергә мөмкин, тик озак коенырга гына ярамый. Күлләр японнар казыган канал ярдәмендә тоташканнар. Япония кайчандыр биредә күкерт табу эшләрен алып барган.

Утрауда талпаннар бик күп. Һәр кич өс-башыбызны, тәнебезне тикшереп кенә йокларга ятабыз. Бу якларга бара калсаң, прививка ясату мәҗбүри. Гомеремдә беренче тапкыр талпан мине нәкъ Кунаширда тешләде. Иптәшләремнең,

эскәк ярдәмендә мине коткару «операция»сен уздыруларын, ә Казанга кайткач, талпан энцефалиты, боррелиозга анализлар тапшырып йөрүемне онытасым юк.

Кунаширдагы дүрт актив вулканның өченчесенә – Менделеев вулканына (886 м) менәбез. Вулкан итәгендә сольфатар кыры урнашкан. Сольфатарлар кайнар күкерт газы бүлеп чыгара һәм бик куркыныч тавышлар чыгарып үкерә. Әйтерсең лә аяк астында җир ярылган һәм җәһәннәм капкалары ачылган...

Вулканга сукмак башта кеше аягы беркайчан да басмаган реликт урман, аннан бамбучник эченнән бара. Ике метр ярым биеклектәге бамбучник арасыннан барганда, алдан атлаган иптәшеңне күз уңыннан югалттыңмы, адашуыңны көт тә тор. Кунаширда агачларда үсүче гөмбәләрне күрергә була. Җыеп алыр өчен төрле акробатик трюклар ясарга туры килгәнгә, аларны «акробатлар» дип атыйлар. Гөмбәләрне күрер өчен аяк астына түгел, ә күп вакытта өскә карарга кирәк.

Охот диңгезе ярларында палаткаларда түгел, ә ачык һавада төн үткәрергә ниятлибез. Утырып уйлар уйлар өчен шулкадәр киңлек монда. Белмәссең, әллә диңгез – күкне, әллә инде күк диңгезне коча... Төннәрен күк йөзе йолдыз белән тула: кулыңны сузсаң, аларга кагылырсың кебек... Бу гаҗәеп манзараны төнге икедә чик сакчылары килеп боза. Алар безнең учак яктысын күргәннәр икән һәм менә кемлегебезне тикшерергә булганнар. Алдагы берничә сәгать погранпропускларны, паспортларны тикшергәнне көтеп үтә. Браконьерлар да, качаклар да булмавыбызны ачыклагач, алар безгә күңелле яллар теләп, көймәләре ягына таба кузгалалар.

Кунаширның иң матур урыннарының берсенә – Столбчатый борынына юнәләбез. Ул ЮНЕСКО реестрына кертелгән. Менделеев вулканы – үзе бөек архитектор лабаса. Аннан агып чыккан лава катып калган һәм алты почмаклы таш баганалар хасил иткән. Миңа бу урын Зур концертлар залындагы органны хәтерләтә: колакта ирексездән музыка яңгырый...

Утрауда еш кына җир тетрәүләр булып тора. Шуңа да йортларның биеклеге ике-өч каттан артмый. Җирле халык инде бу күренешкә күнеккән, җир тетрәвен алар, аюның өй түбәсенә менеп, аны селкетепме-селкетүе белән чагыштыра.

Япония белән килешү нигезендә, 1992 елдан Кунашир, Итуруп һәм Шикотан утрауларында яшәүче җирле халык кояш чыгышы иленә визасыз гына бара ала. Япон делегацияләре дә әлеге утрауларга визасыз гына килә. Без барган җәйдә дә 80–90 яшьлек япон картлары утраудагы каберлекләрне зиярәт кылып киткән.

...Хушлашу мизгелләре җитә. Поход таныш булмаган кешеләрне дә тиз арада берләштерә. Синең хәтта «саклаучы фәрештәң» дә барлыкка килә. Ул сиңа авыр рюкзагыңны киеп-салырга булыша, ризыгы белән бүлешә, ярдәм кулы суза... Үзең дә кем өчендер фәрештә ролен башкарасың. Походның ахыргы көнендә бу уенга йомгак ясала. Бер-береңә ярдәмләшү шулкадәр гадәти күренешкә әйләнә ки, бу минем фәрештәм түгелме дип, һәрбер катнашучыдан шикләнеп чыгарга өлгерәсең.

Кайнап торган күлләре, карак төлкеләре, горур бөркетләре, чәчәккә күмелгән кыргый магнолияләре, сәнгать әсәрләренә тиң кыялары белән әкияти Кунашир артта кала. Алда – Итуруп. Тик безгә анда төшәргә рөхсәт юк, теплоходтан гына күзәтәбез.

Кайтыр юл ерак... Ике кич теплоходта барырга, бер кич Көньяк Сахалинда кунарга, башта Мәскәүгә, аннан гына Казанга очарга. Коеп яңгыр яуганда, чыдап булмаслык эссе кояш астында барганда, янартауларга менгәндә, таш кыяларга үрмәләгәндә, гомумән, тормыш сукмакларыннан атлаганда юлчы булуыңны тою – гаҗәеп халәт. Шул халәтне югалтмаска иде...



ХЫЯНӘТ – ЮЫП БЕТЕРГЕСЕЗ ГӨНАҺ



Фирдүс ТЯМАЕВ,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 7 ел;
балалары – Раян, Кәрим.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Тәрбиясенә. Минем әни: «Нәселенә карап кызын коч», – дип әйтә иде. Күп кызлар белән йөрдем. Резеданы Казанда татар дискотекасында күрдем һәм ошаттым. Ул студент кыз иде әле. Безнең яшь аермасы – 12 ел. Резедаларның өенә барып алар гаиләсендәге тәрбияне күргәч, минем күңелемә ул тагын да ныграк ятты. Ирне хөрмәт итү. Өстәл артында ир кеше сөйли. Ә бу минем өчен бик мөһим.

2 Нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Бу ир-атның холкыннан тора. Мин өйләнгәч ике генә таләпне әйттем. Беренчесе – хыянәтне беркайчан да кичермәячәкмен. Икенчесе – хатыным миңа әниемнән, туганнарымнан зарланырга тиеш түгел. Хәтта алар хаклы булмаса да. Кайнана белән килен арасында төрле хәлләр килеп чыга, тик акыллы ир-атта бер кагыйдә бар: ике арага кермәскә! Якламаска! Әни – әни ул, хатын – хатын. Икесе дә бик якын. Әни ягына бассам, «маменькин сыночек» булып гаиләне бозачакмын, хатынны якласам, әнигә каршы барып, нәселгә хыянәт итәчәкмен. Күп гаиләләр шуның аркасында бозылыша. Ә хыянәткә килгәндә... Ир шул юлга баса икән, димәк, иң элек үзенә хыянәт итә. Бу – аның башсызлыгы! Ә хатын-кыз читләргә караса, гаиләсенә, балаларына хыянәт итә дигән сүз. Балалар үскәч: «Әтиең читкә йөрде», – дип әйтсәләр, бу хәбәрне күңелләренә авыр алмаячаклар. Ә инде әнисенә карата әйтсәләр, җанга тиярлек моннан да авыр сүз булмаячак. Коръәндә дә Аллаһы Тәгаләдән соң ана тора. Әни җитмеш тамырын өзеп баласын таба. Әни – иң изге кеше. Ә изгеләргә андый хата эшләү – гөнаһ.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Мәгънәсез сорау бу! Өеңә ямь керткән хатын ничек инде илһамландырмасын ди! Әлбәттә, илһамландыра. Аларны икегә бүлеп карау, гомумән, дөрес түгел. Минем әни өйдә ямь дә булдырды, илһамландырды да. Безнең гаиләдә дә шулай ук. Яратып өйләнгәнсең икән, башкача сүз булырга тиеш түгел. Хатын ашарга да пешерә, илһамландыра да, талаша да, ярата да, назлый да... ул шуның өчен хатын бит.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Нинди генә дустың булса да, иң якын дустың – хатының. Берни сөйләмим дигәннәргә ышанмыйм: һәрбер ир-ат хатынына серен сөйли. Гап-гади тормыш мисалы китерәм: кайбер ир гомере буе бик күп сөяркәләр белән йөри-йөри дә, саулыгы беткәч, хатыны янына килеп егыла. Димәк, ул аның якын дусты. Аннан да якын кешесе юк.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Хәтерлим. Беренче очрашуда ук: «Син – минеке», – дидем. Казанда дискотекада очрашканнан соң өч ел йөрдек. Тыйнаклыгы, мөлаемлыгы йөзенә чыккан иде. Хатынкызның кем икәнен күзенә карап беләм. Романтик тәкъдимнәр ясый алмадым. Авыр чак иде. Авариягә эләккән вакыт. Акча юклык... «Бүген сезгә кыз сорарга киләбез», – дидем. Бөтен тәкъдимем шул булды. Ә концертымда сәхнәдә матур итеп тәкъдим ясадым. Алдына тезләндем дә мәхәббәтемне аңлаттым. Балаларыбыз бар иде инде.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әни Резеданы күргәч үк: «Бу – синең кеше. Холкыңа туры килә. Синең бәхетеңә туган бала», – диде. Әлбәттә, ир-ат әнисенә охшаган хатын эзли. Минем әти кызмача кайта идеме, ярсып кайтамы, төнлә кайтып керәме – өстәлдә һәрвакыт әнинең бәлеше, токмачы, җимеше булды. Ит белән бәрәңгене әйтеп тә тормыйм инде. Нинди генә хәл булмасын, әтинең носкиларына кадәр үтүкләнгән була иде. Авылда яшәп! Әти электрик иде, әни гомер буе сыер сауды, ашханәдә дә эшләде. Ул тәртип ярата. Шкафында әйберләр һәрвакыт таслап-таслап өелгән... Мин шундый хатын эзләдем һәм таптым.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Кайбер хатыннарның бер зур кимчелеге бар: күбрәк акча эшли башлый икән, ирен битәрләргә тотына. Элек андый нәрсә юк иде бит! Моңа дәүләт гаепле: ирекне күп бирде. Уйлап карагыз! Бүгенге көндә ир-атның бер хокукы да юк. Менә гади генә бер мисал. Гаилә таркала икән, бала хатында кала. Бу – гаделсезлек! Әгәр закон баланы әтидә калдыру ягында булса, хатын бит аерылмаячак. Дөрес, өйдәгеләрне җәберләп яшәгән ир-атлар да бар, ләкин бу очракта да гаепне ир-атка гына ташлап булмый. Ир рюмкага үрелә икән, димәк, гаиләдәге мөнәсәбәтләр начар. Ә тормышның 80 проценты хатын-кыздан тора. Гаиләдә дилбегә хатын-кыз кулында. Хатын-кыз, бала табам да үзем өчен үстерәм, дип аерыла. Ә бала кем булып үсә? Гомумән, хәзерге заман балалар тәрбиясе өчен үтә куркыныч. Балага эләктереп аласың икән, опекага килеп җитә. Мәктәптә укытучы балага тавыш күтәрсә, шундук әти-әнисе килеп, аны эшеннән алдырта. Элекке заман кирәк! Тал чыбыгы! Мин әти-әниемә тал чыбыгы өчен бик рәхмәтле. Минем өйдә шундый закон: өйгә егетләр белән кайтып керәм икән, хатын чәй куя да бүлмәсенә кереп китә, балалар да безнең янда утырмый. Без үзебез дә шулай үстек. Кайбер гаиләләргә килеп керәсең – балалары өстәл башында, шунда ук хатыны җәелеп утыра. Әле ире белән талашып алырга, ятлар янында кайнанасын хурлап алырга да күп сорамый. Алай ярамый. Иргә карата хөрмәт булырга тиеш.

8 **Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Сәхнәдә булгач, безне идеаль дип уйлыйлар. Юк, без дә шундый ук гап-гади ир-атлар, безнең дә шундый ук организм. Кияүдәге хатын-кызларның башка ирләргә мәхәббәт аңлатуларына шаккатам. Азгынлыкмы инде бу, үз иренең ирлек көчсезлегеме?! Әмма шуны онытмаска кирәк: бу – зур гөнаһ. Әгәр хыянәт иткән хатын-кызларга моның нинди зур гөнаһ икәнен аңлатсалар, ул гомере буе сәҗдәдә булыр иде. Күңелләрендә иман булганда гына ир белән хатын матур яши.

9 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Күп сөйләп тормыйм, бер сүз белән генә әйтәм: чын ир-ат булуы. Ә менә һәр хатын-кыз өчен чын ир-ат төшенчәсе төрлечә ул.

10 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Концертларымда минем чын ир-ат булып күренәсем килә. Тамашачылар шуның өчен дә киләдер, мөгаен. Ир-ат чын ир-ат булсын инде ул. Әнисен кулларында күтәреп йөртсен, алдында тезләнсен, хатыны белән матур итеп яшәсен. Концертымнан соң тамашачыларым өйләренә якты хисләр белән кайтып китсен иде. Ирләрнең – хатынын, хатыннарның ирен хөрмәт итеп яшәүләренә өлеш кертәм икән, бик сөенәчәкмен.

11 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Башкалар өчен җавап бирә алмыйм. Үзем көчлесеннән дә, матурыннан да курыкмыйм. Матур хатын-кыз ул салкын булырга мөмкин. Аны кочаклап бернинди энергетика ала алмыйсың икән, нигә кирәк ул матурлык?!

12 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Бездә андый очрак юк. Хатыным холкымны белә: мин – медийный кеше, үз законнарым бар. Кайчан һәм ничек итеп сүз кушарга кирәклеген дә белә ул. Юк, мине тиран дип уйламагыз сез. Без киңәшләшеп яшибез. Хатынымның фикере минем өчен мөһим. Мин аңлыйм: хатыныма карата нинди мөнәсәбәттә булсам, туганнарымның, әнинең мөнәсәбәте дә нәкъ шундый булачак.

13 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы әллә инде юл куясызмы?**

– Ул кыланчык түгел, масая белми. «Матурым, ул синең эшең, мин тыгылмыйм», – ди. Миңа Резеданың тормышка карашы ошый. Аның фикеренә колак салам, үзем дә сорыйм. Ул мине, бәлки, тәрбияли дер дә әле.

14 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым, дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?**

– Бездә андый хәлнең бөтенләй булганы юк һәм булмаячак та. Мин гастрольләрдән кайткан көнне бәлеш, мантый пешкән. Безнең запассыз яшәгән юк. Балконда – какланган каз, суыткычта – пилмән. Бу – әнидән килгән гадәт. Нурлатта әнинең йортында дүрт суыткыч тора. Анда ике үгез сыеп беткән. 400 баш кош-корт кына үстерә әни. Нинди генә акчасызлыкта яшәсәк тә, беркайчан да ризыкка аптыраган булмады. Хатынның өстәле дә, әнинеке дә, әбинеке дә мул. Һәр гаиләдә шулайдыр ул. Өстәл мулрак булган саен, Ходай Тәгалә бирә. Җай чыга икән, күршеләреңне, туганнарыңны, ятимнәрне ашат. Аның әҗере кайтмый калмый. Сигез ел тулай торакта яшәдем. Бәлешкә кадәр пешерә беләм, пешереп тә ашатам. Аш-суга оста мин.

15 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Гадәти хәл. Аның өчен тавыш чыгарганым юк. Гомумән, минем өйдә тузынганым юк. Усал кешедән куркырга кирәкми, тыныч кешедән саклан, диләр. Ул аркаңа пычак кадарга мөмкин. Ә хатын-кызның җыенуы... Әнә, җиденче яртыдан башланачак концертка дүрттә үк килеп әзерләнә. Алар шунда – бүлмәдә хатын-кызлар белән чәч ясыйлар, бизәнәләр. Хатын-кыз бит инде ул, җыенсын рәхәтләнеп.

16 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Без бар нәрсәдән матурлык таба беләбез. Сәхнә кешесе үзе шул сюрприз оясында яши. Шуңа күрә бер-беребездән әллә ниләр көтмибез. Әйе, чәчәкләр бирәм, әлбәттә. Анысы да шул 8 Мартта, туган көнендә. Беркайчан да аның теләкләренә каршы килгәнем юк.

PRESSA



Җәйне кайсыбыз гына яратмый икән?! Бигрәк тә балалар куана. Аларны табигать, саф һава, елга-күлләр, җиләкле болыннар көтә. Балаларыбызның табигатьтә кичергән рәхәт мизгелләре күңелсезлек белән тәмамланмасын өчен, әти-әниләрдән икеләтә игътибарлылык сорала. Безнең күбебез аяк-куллардагы тырналган-киселгән яраларга хәвеф чыганагы итеп карамый. Ә бит менә шул бәләкәй генә яра аркасында балада үтә куркыныч чир – столбняк башланырга мөмкин. Әлеге чир хакында Республика балалар клиник хастаханәсенең эпидемиология бүлеге җитәкчесе, югары категорияле табиб, медицина фәннәре кандидаты Илсөя ФАЗЫЛҖАНОВА белән сөйләшәбез.

КЕЧКЕНӘ ЯРАДАН...

Столбняк – үтә куркыныч инфекцион чирләрнең берсе. Организмга килеп эләккән столбняк таякчыгының агуы үзәк нерв системасын зарарлый.

Столбняк таякчыгы табигатьтә киң таралган, һәм безнең организмыбыз аңа үтә дә сизгер. Тузанда, туфракта, кипкән үләннәрдә, яфракларда, төче һәм тозлы сулыкларда, күп кенә кыргый һәм йорт хайваннарының, хәтта кешеләрнең дә эчәклегендә яши. Эчәклек стенкалары аша үтеп чыга алмаганлыктан, әлеге очракта бу токсин сәламәтлеккә зыян китерми. Столбняк кешедән кешегә дә йокмый.

Инфекция тиредәге яра аша кергән очракта куркыныч тудыра. Токсин барлыкка килсен өчен билгеле бер шартлар кирәк: дымлылык, 37 градуска кадәр җылылык һәм кислород булмау.

Хәзер столбняк белән, нигездә, аякларны җәрәхәтләү аркасында авырыйлар. Аны йоктыру өчен зур яра да кирәкми, урамда күгәргән кадакка гына басу да җитә. Тән тиресендә пешкән, тырналган урыннар булса, инфекция шуннан да керә ала.

Бик сирәк очракларда, баланы тудырганда гигиена шартлары үтәлмәгәндә, столбняк кендек ярасы аша да керергә мөмкин. Монысы иң авыр форма булып санала.

Столбняк белән төрле яшьтә дә авырыйлар. Балалар исә үзләренең табигатьләренә хас тиктормаслыклары, кызыксынучанлыклары, игътибарсызлыклары һәм хәвеф янавын аңлап бетермәүләре аркасында күңелсез маҗараларга күбрәк таручан. Балаларның организмы әлеге инфекцияне олыларга караганда авыррак кичерә.

Столбнякның инкубация чоры – 10–45 көн. Җәрәхәт аша кергән очракта гадәттә беренче билгеләр 6–14 көннән күренә башлый.

Тиз арада тиешле дәва чаралары билгеләнмәсә, столбняк чиренең бик зур күңелсезлекләргә, хәтта үлемгә дә (тын ала алмау аркасында) китерүе ихтимал.

Төп билгеләре

- көчлерәк тавыш, яктылык, хәтта кагылып кына киткәннән дә тәнне көзән җыеру;
- тәннең температурасы 40–42 градуска кадәр күтәрелү;
- бик нык тирләү;
- ашказаны-эчәклекләрдә спазмнар.



Беренче ярдәм

■ **Җәрәхәтләнгән баланы тиз арада травмпунктка яки яшәү урыны буенча поликлиникага, балалар хастаханәсенең кабул итү бүлегенә алып килеп, ашыгыч рәвештә столбнякка каршы прививка ясатырга кирәк.**

■ **Яраны хирургик эшкәртү – ашыгыч профилактика чарасы. Өй шартларында яраны йод, зеленка, водород перекисе белән юдыру гына столбняк таякчыкларын зарарсызландыра алмый.**

■ **Җәрәхәт алган балага столбнякның анатоксины, столбнякка каршы сыворотка яисә иммуноглобулин ярдәмендә иммунопрофилактика ясала.**







Фото: www.pixabay.com

Әти-әниләрне нәрсә сагайтырга тиеш

■ Баланың авыз мускулларында киеренкелек күзәтелә. Ул авызын бик авырлык белән генә ача яки бөтенләй дә ача алмый.

■ Биттәге мускуллар кыскару аркасында баланың йөзенә «газаплы елмаю» чыга.

■ Муен мускулларының кыскаруы сәбәпле, бала башын артка ташлый. Соңыннан көзән җыеру бөтен тәнгә тарала һәм бала үзенең гәүдәсен төрле рәвешләргә кертергә мәҗбүр була. Әле алга бөгелә, әле аркасын артка ташлый, әле үрә ката.

Ничек сакланырга

■ Бүгенге көнгәчә иң үтемле саклану чарасы булып столбнякка каршы ясалган прививка санала. Профилактик прививкаларның Россия Федерациясендә кабул ителгән гомумхалык календаре буенча әлеге процедура балага өч айлык вакытта, дүрт ай ярым булгач, алты айда ясала, шулай ук яшь ярым, җиде, ундүрт яшьләрдә һәм һәр ун ел саен кабатлана. Прививкадан соң барлыкка килгән иммунитет ун елга җитәргә тиеш.



Материал ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Яз көне бакчада, ишегалдында эш күп – җыештырабыз, тырмалыйбыз, себерәбез. Барына да җитешергә кирәк дип ашыкканда иң мөһимен онытып та җибәрәбез. Ә иң мөһиме: үз-үзеңне саклау. Беренче карашка артык зарарлы булып күренмәгән чүп-чар арасында куркыныч чир китереп чыгаручы вируслар булырга мөмкин. Тычкан бизгәге белән авыручылар нәкъ менә яз һәм көз айларында арта. Югары категорияле табиб-инфекционист, Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгының йогышлы авырулар буенча төп белгече, медицина фәннәре кандидаты, доцент Халит ХӘЕРТДИНОВ белән әлеге чирнең билгеләре һәм кисәтү юллары хакында сөйләшәбез.

ТЫЧКАН БИЗГӘГЕ

Бөер синдромлы геморрагик бизгәк – тычкан бизгәгенең медицина телендәге атамасы әнә шундый – кискен йогышлы авыру. Энцефалит яки боррелиоз кебек үк, ул да табигый чыганаклы чирләрдән санала. Татарстан Республикасында бөер синдромлы геморрагик бизгәк табигый чынагаклы чирләр арасында иң киң таралганы. Инфекциянең төп чыганагы – тычканнар, аеруча җирән кыр тычканы.

Ничек йога

- һава аша. Кимерүчеләрнең нәҗесләре булган тузанны сулаганда чирне кузгатучы инфекция һава белән тын юлларына элә;
- авыз куышлыгы аша. Тычканнар кимергән яки өстеннән йөргән ризыкларны кулланганда чирне кузгатучы вируслар организмга авыз куышлыгы аша үтеп керә;
- контакт юл белән. Җәрәхәтле кул белән тычканнар пычраткан печән-салам яки чүпләрне тотканда да тычкан бизгәген йоктыру ихтимал;
- кешедән кешегә бу чир күчми.

Нинди билгеләре бар

- югары температура;
- бизгәк тоту;
- баш авырту;
- буыннар һәм мускуллар сызлау;
- күз алды томалану;
- яктылыкка карый алмау;
- тәнгә кызгылт таплар чыгу;
- бит һәм муен тирәсенең шешенкелеге;
- бил авырту;
- бәвел бүленеп чыгуның кимүе.

Бу билгеләрнең күбесе гриппныкына охшаш, шуңа да башлангыч мәлдә диагнозны дөрес итеп кую мөһим.

Вирусны йоктыргач та, кеше авырый башламаска мөмкин әле. Чирнең инкубация чоры ике атнадан алып биш атнага кадәр. Төп симптомнар башланыр алдыннан хәлсезлек, йончу, йокы килү, аяк-куллар сызлау, тамак авырту күзәтелү ихтимал. Беренче билгеләр күренү белән табибка мөрәҗәгать итү мәҗбүри. Тычкан бизгәге йоктырган кеше инфекцион хастаханәдә табиб-инфекционист күзәтүендә булырга тиеш. Чөнки геморрагик бизгәкнең авыр формасы кеше гомере өчен куркыныч.

Югыйсә әлеге чиргә тарымауның кагыйдәләре бик гади: дачаны яки бакчаны, сарайларны җыештырганда, табигатькә чыкканда саклык чараларын төгәл үтәү.

Ничек сакланырга

- кимерүчеләргә каршы көрәшү;
- көзен бакчаны җыештырып, тычканнар оялардык чүпләрне түгү яки яндыру;
- ризыкларны ачык калдырмау;
- тычканнар йөрүе ихтимал урыннарны җыештырганда авыз-борынны битлек белән томалау;
- тычкан тизәге булган җирдә яланаяк йөрмәү;
- кулга резин перчатка кию;
- кыш кеше яшәмәгән торакларны җыештырганда дезинфекцияләүче препаратлар куллану;
- җыештырып бетергәч яки табигатьтә булып кайкач, кулларны сабын белән юу, авыз-борынны чайкау, битне юып төшерү; киемне алыштыру.



Нәрсәсе белән куркыныч

- **кан тамырлары зарарлана;**
- **эчке органнарга, нигездә, бөерләргә кан сава;**
- **бөерләр сафтан чыга (уремик кома халәте);**
- **организмда инфекцион-токсик шок башлана (кан басымы кискен төшә, пульс әкренәя, һәм кеше аңын югалта);**
- **эчке кан китүләр күзәтелә.**



Материал Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Әлфия Хәсәнова ярдәме белән әзерләнде.

PRESSA

Аджарча хачапури пешерик!



Күбебезгә озак кына вакыт өйдә – үзизоляциядә булырга туры килде. Сезгә тәкъдим итә торган ризыгыбыз менә шул көннәрдә гаилә белән бергә әзерләнгән аджарча хачапури. Аны редакциябез фотографы Анна АРАХАМИЯ әзерләде. Аннаның ире – грузин милләтеннән. Җәйләрне алар Абхазиядә Давидның әнисе янында уздыралар. Аня ул якның халкын да, ризыгын да, табигатен дә ярата.

«Хач» – эремчек, «пури» ипи дигәнне аңлата. Кирәк әйберләрне алыйк та, әйдәгез, без дә өйдәгеләрне грузин милли ризыгы пешереп сыйлыйк әле!

Кирәк

- 500 г он;
- 400 мл сөт;
- 5 г коры чүпрә;
- 1 аш кашыгы сыер мае (камыр өчен);
- 1 аш кашыгы сыер мае (эчлек әзерләү өчен);
- 1 аш кашыгы сыек май;
- 1 чәй кашыгы шикәр;
- ярты чәй кашыгы тоз;
- 500 г сулугуни сыры;
- 3–7 йомырка.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Савытка онны иләп салабыз. Шунда ук чүпрә, тоз, шикәр, май өстибез. Җылы сөт кушып, камырны 5–7 минут әйбәтләп басабыз.

■ Камыр салынган савытның өстен пленка белән томалап ярты сәгатькә калдырабыз.

■ Уылган сырны сыер мае һәм бер йомырка белән катнаштырабыз.

■ Камырны дүрткә бүләбез. Һәр кисәкне овал формасына туры китереп җәябез. Кисәкләрнең кырыйларын «көймә» рәвешендә төрәбез. (Төргәндә сыр кыстырып калдырырга да була. Ул очракта сыр күбрәк кирәк булачак.)

■ Һәр көймәне эчлек белән тутырабыз. Һәм калган ике йомырканың сарысын аерып алып, «көймә»ләрнең кырыйларына ягабыз. Алдан җылытылган табага тезеп, мичкә куябыз.

■ 250 градуста 5–7 минут тирәсе пешерәбез.

■ Аннан, мичтән алып, хачапуриның эчлеген сак кына болгатып җибәрәбез һәм теләгән очракта һәрберсенең өстенә берәр йомырка сытып, кабат 3 минутка мичкә куябыз.

■ Хачапури өстәлгә кайнар килеш бирелә. Кырыйларын сындырып, уртадагы эчлеккә манып ашыйбыз. Тәмле булсын! Көннәрегез матур һәм күңелле узсын, кадерле укучыларыбыз!



«Барысы да табигый, бер генә ясалма продукт та юк!» Кибеттән сатып алган баллы тәм-том, печеньелар турында шулай дип ышандырып әйтә алыр идегезме? Ә менә үзебез пешергәне хакында авыз тутырып әйтә алабыз: ул тәмле дә, файдалы да! Дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА өйдә булган иң гади ризыклардан эремчек һәм кокостан печенье әзерләргә тәкъдим итә. Эремчекнең файдасы хакында әйтеп тору кирәкме икән?! Ул – иң элек кальций һәм аксым чыганагы. Солының файдасы турында да билгеле: аның составында А һәм Е витамины, бакыр, магний, кальций, фосфор, тимер бар. Ә иң мөһиме: аны глютенсыз диета тотучылар да куллана ала. Кокос чикләвеге исә көчле афродизиак булып санала, организмның чирләргә каршы торучанлыгын арттыра.



Тәм-том яратучыларга

Эремчекле печенье



Кирәк

- 250 г йомшак эремчек;
- 30 г йөзем;
- уртача 1 алма;
- 100 г солы лавачы;
- 2 йомырка;
- берәр төрле шикәр алыштыргыч (алар турында алдагы саннарда сүз булды);
- 1 аш кашыгы көрпәле он (ансыз да була).

Эш барышы

■ Йөземне юып, 10 минутка кайнар суга салып куябыз.

■ Алманы чистартып, вак шакмаклап турыйбыз.

■ Эремчеккә 2 йомырканы сытып, солы лавачы, шикәр алыштыргыч, алма һәм йөземне дә кушып, яхшылап туглыйбыз.

■ Эремчекле массаны төбенә пергамент кәгазе җәелгән табага кашык белән салып чыгабыз.

■ Печеньелар 180 градус кызулыктагы мичтә 20 минут чамасы пешә.

■ Йөзем урынына үзегез яраткан башка төрле кипкән җиләк-җимеш куллана аласыз.

Кокослы печенье – «кокосанка»



Фото: www.pixabay.com

Кирәк

- 2 зур гына йомырканың агы;
- 100 г кокос йомычкасы;
- түменчә шикәр алыштыргыч;
- бер чеметем тоз.

Эш барышы

■ Йомырка агына бер чеметем тоз салып, чәнечке белән күпертәбез (блендер белән түгел!).

■ Шикәр алыштыргыч өстәп, күпертүне дәвам итәбез.

■ Кокос йомычкасын өстәп, яхшылап туглыйбыз. Масса куе, формасын сакларлык булырга тиеш. Кокос йомычкасы бераз бүртеп китсен өчен 2-3 минут көтәбез.

■ Булачак печеньеларны, юеш кул яки кондитер шприцы белән пирамидкалар рәвешенә китереп, төбенә пергамент кәгазе җәелгән табага тезәбез.

■ Алдан ук 150 градуска кадәр кыздырып куйган мичтә 20–30 минут пешерәбез (өсте алланганчы). Мичтән алып суытабыз да чәй табынына чыгарабыз!

Кучкар. Бу айда карьера буенча уңай үзгәрешләр булачак. Зур эшләргә тотынудан курыкмагыз, кулыгыздан киләчәк! Саллы нәтиҗәләргә ирешерсез. Сәламәтлегегезне ныгыту җае килеп чыкса, баш тартмагыз.

Үгезбозау. Үҗәт, эшлекле, максатларын төгәл белүче Үгезбозаулар өчен июнь аенда барлык мөмкинлекләр дә ачылачак. Тик ай ахырында эш белән шәхси мөнәсәбәтләр арасында кытыршылыклар килеп чыгарга мөмкин.

Игезәкләр. Артык эшкә бирелдең, дип, якыннарыгыз үпкәләргә мөмкин. Эш белән генә яшәүдән туктап, игътибарыгызны гаиләгә күчерегез әле. Тәмле ризыклар белән сөендерегез, яратуыгызны күрсәтегез.

Кысла. Июнь сезне яңа тәэсирләр, идеяләр белән сөендерәчәк. Кешеләр белән бик тиз уртак тел таба белүегез нәтиҗәсендә, кирәк вакытта ярдәм кулы сузардай танышларыгыз артачак.

Арыслан. Эштә, хезмәттәшләрегез югалып калган бер мәлдә, кыю адымнар ясап, өстенлекләрегезне күрсәтә алачаксыз. Үз дигәнегезгә ирешә, оештыра белү сыйфатлары сездә күзгә күренеп үсәчәк.

Кыз. Ял итәргә барыгыз. Яңа кешеләр белән танышырга уңайсызланмагыз. Мәхәббәт өлкәсендәге хыялларыгыз күккә очарга мөмкин, җир кешесе булыр вакыт җитте. Үзегезгә ял бирегез.

Үлчәү. Уңыш сезнең дөньяга үзе ыргылып килеп керәчәк! Ел башыннан ук борчып торган проблемалар юкка чыгачак. Очы-кырые күренмәс кебек тоелган эшләрегез җайга салыныр. Тормышыгызны үзгәртүдән курыкмагыз!

Чаян. Кайбер Чаяннар байлык артынан куып, булганыннан колак кагулары бар. Акча мәсьәләсендә сак булырга кирәк. Мәхәббәт өлкәсендә кыюрак булыгыз, сөйгәнегез сездән беренче адым ясауны көтә.

Укчы. Бу айда тормышыгызда җитди адымнар һәм үзгәрешләр планлаштырмагыз. Иҗади һөнәр ияләре зур үрләр яуларга мөмкин. Акчагызны үзегезгә кирәкле әйберләр сатып алыр өчен тотыгыз.

Кәҗәмөгез. Мәхәббәтегезне ерактан эзләп йөрмәгез, ул якында гына. Гомерлек ярыгыз бергә эшләгән хезмәттәшегез дә, бергә укыган төркемдәшегез дә булырга мөмкин. Сәламәтлегегезне ныгытыгыз, иртән йөгерә башлау файдага булыр.

Сукояр. Буш вакытыгызны күңелегезгә якын кешеләргә багышлагыз. Гаиләле Сукоярларның тормышына шәп кенә яңалыклар үтеп керәчәк, балалар белән бәйле матур вакыйгалар булыр. Ялгызлар үзләренең насыйп ярларын очратыр.

Балык. Кайбер проблемаларны хәл иткәндә үзегезнең тормыш тәҗрибәсенә таяныгыз. Якыннарыгыздан артык күпне көтмәгез. Кайбер эшләрне үзегез генә башкарып чыгу отышлырак булачак, башкаларга артык ышанмагыз.

СЕЗ – ЭКСТРАВЕРТМЫ, ӘЛЛӘ ИНТРОВЕРТМЫ?

Экстравертлар – ачык, аралашучан, җәмгать тормышында кайнап яшәргә яратучы кешеләр. Ә интровертлар – тынычлыкны, ялгызлыкны үз итүчеләр. Бу начар да, яхшы да түгел. Бары тик үзеңнең нинди тип кеше икәнлегеңне белеп яшәү мөһим. Түбәндәге сорауларга җавап биреп, үзегезнең психологик типны билгеләп карагыз әле!

Әгәр экстраверт икәнсез, сез:

1. Бер көндә ике кино, концерт карап чыга аласыз. Бер үк көнгә әллә ничә очрашу билгеләп, шуның берсенә генә бара алсагыз да – сөенәсез.

2. Телефоныгыз сүнгән булса – үзегезне дөньядан аерылган, ялгыз кеше дип хис итә башлыйсыз.

3. Формулаларны – авыр, ә кеше йөзләрен, биография, төрле вакыйгаларны җиңел истә калдырасыз.

4. Тәмле итеп ашарга, компания белән шау-гөр килеп аралашырга яратасыз. Ялгыз кешеләрдән качасыз, аралашучан кешеләргә тартыласыз.

5. Мәзәкләр, кызык хәлләр сөйләргә яратасыз.

6. Сез – компаниянең иң актив кешесе, матур тостлар әйтү остасы.

7. Кайчан нәрсә эшләргә кирәклеген һәрвакыт әйбәт беләсез.

8. Авыр хәлләрдән җиңел генә чыгу юлын беләсез, таныш түгел кешеләр белән уртак телне тиз табасыз.

9. Ситуациягә карап эш йөртә беләсез.

10. Барысын да чынга ашырып бетерә алмасагыз да – башыгыз һәрвакыт идея, планнар, максатлар белән тулы.

11. Бертуктаусыз сәламәтлегеннән зарланган кешеләрне аңламыйсыз.

12. Башкаларда нинди фикер тудыруыгыз турында кызыксынасыз.

Әгәр интроверт икәнсез, сез:

1. Кечкенә генә вакыйга аркасында да алдан кабул иткән карарыгызны үзгәртә аласыз.

2. Зур чараларга йөрергә яратмыйсыз.

3. Үткәннәр турында уйланырга яратасыз.

4. Күп кешеләр белән аралашырга яратмыйсыз.

5. Күп мәгълүмат белән эшләгәндә бутала башлыйсыз. Сезгә аз һәм конкрет информация белән эшләү уңайлы.

6. Тавышлануны, шау-шулы компанияне үз итмисез.

7. Үзегезгә ятышлы уңайлы кием киярга яратасыз.

8. Фотога төшү – яраткан шөгылегез.

9. Өйдә, үзегез генә, уңайлы шартларда утырып тамак ялгауны хуп күрәсез.

10. Сез – принципиаль кеше. Үз принципларыгызга һәрвакыт тугры калырга тырышасыз.

11. Сәламәтлегегезгә бик игътибарлы. Дару эчеп дәвалanганчы, аны кисәтү хәерлерәк дигән фикердә яшисез.

12. Еш кына үзегезгә карата: «Тормышка җиңелрәк карарга кирәк», – дигән киңәш ишетәсез.

(Үзегезнең типны билгеләгәннән соң сораулар туса, языгыз. Бу темага сөйләшүне психолог катнашында дәвам итәрбез.)

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

PRESSA





КОРЫЧ ХОЛЫКЛЫЛАР

Хамид Савкуев – олуг шөһрәт казанган иҗатчы. Рәссам 1964 елның 20 июлендә Джамбулда туган. Сәнгать буенча беренче белемнәрен рәссам-монументалист А. Сундуков остаханәсендә туплаган. Карачаевск шәһәренең педагогика институтын тәмамлаган. Санкт-Петербугның И. Е. Репин исемендәге дәүләт сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтында белем алганнан соң, менә инде күп еллар буе шушы дәрәҗәле институтта укыта.

Ул – Кабардин-Балкар Республикасының халык рәссамы. Россия сынлы сәнгать академиясе академигы. Хамид Савкуевның иҗаты югары бәяләнә: рәссамның картиналары Россиядә, Испаниядә, Нидерландта, Германиядә, Франциядә, Кытайда саклана.
Бер әсәре Каталония Президенты сарае өчен махсус сайлап алынды. Рус дәүләт музее да аның әсәрләрен үз тупланмаларына бик теләп кабул итте. Пекинның заманча сынлы сәнгать музее: «Киләчәктә бу асыл зат нинди яңа әсәрләр язса да, без аларны кабул итәчәкбез», – дип белдерә. Рәссамның шәхси күргәзмәләре илебезнең һәм башка дәүләтләрнең күргәзмә залларында зур уңыш белән уза.

Хамид Владимир улы картиналарында кабардин халкының көнкүреше, тереклек итүләре белән бәйле кырыс табигать, авырлыклар, бу халыктагы рухи куәт, тырышлык һәм холыкларындагы ныклык чагыла. Әсәрләрен ул һәрчак үз халкы белән горурланып яза. Картиналары һәрвакыт халкының архаик-этник кыйммәтләрен яктырта. Һәрбер картинасындагы композиция тирәнтен фәлсәфи чишелеше, гармония кануннарына туры китерелгән төсләре, кыю ракурслары белән таң калдыра. Алар гаять катлаулы да. Киндерләрдәге йөзләрдә – җитдилек, күп фигуралы образлар – үзенчәлекле, алардагы сыгылмалылык гаять төгәллек һәм җыйнаклык белән җиткерелгән.

Аның «Солдатлар» сериясе дә мәшһүр әсәрләр рәтендә. Сериянең сәнгати эчтәлегендә: яралар, ачлык, мизгел эчендә үлем, ә солдатларыбыз кыю, батыр, бербересенә карата гаять мәрхәмәтле. Шул ук вакытта алар сугыш мәхшәре белән тиреләрдән сыдырылган тере нервларны да хәтерләтәләр.

Академик үз студентларына еш кына: «Иң мөһиме – киндерләрегездә игелек сурәтләгез!» – дип кабатлый.


Хамид Савкуевның зур күләмле дивар паннолары да бар. Нальчикның этнография институтында, Кабардин-Балкар хөкүмәте бинасында – ул язган әсәрләр, әмма ул әлеге сәнгать юнәлешен үз иҗатында алга сөрми. Ул – искиткеч оста график та, сәләтле скульптор да. Бронзадан иҗат ителгән сыннары – югары сәнгати дәрәҗәләрдә.


Чиксез талантлы рәссамнан шул хакта сорадым: «Үз язу рәвешегезгә килү өчен сынчылыкны өзелеп ярату таләп ителгәндер?» Хамид Владимир улы: «Әйе, кешелек тарафыннан бик күп гасырлар буе иҗат ителгән скульптураларны өйрәндем, ә аннан соң скульптура ясаудагы белемнәремне сынлы сәнгатьтә кулландым. Талантым өчен һәр көн Бөек Затка рәхмәтлемен!» – диде. Рәссамның җан халәте аның эшләрендә чагыла. Менә аның «Дога» дип аталучы графика әсәрендә – намаз кылучы солдат. Сугыш тәмам, ул исән калган, рәхмәтләре дә – Аллаһы Тәгаләгә! Сугыш темасына чиксез күп рәсемнәр, картиналар иҗат ителгән. Шулар арасында әлеге «Дога» әсәре үзенең кабатланмас булуы белән аерылып тора. Кайчан карасаң да, күңелләргә бер дәрәҗәдә көчле тәэсир итә ул.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА











ХАМИД САВКУЕВ

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020



Илшат НУРИЕВ,
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль район башлыгы

Бөек Тукай Ватаны – Арча районының тырыш-уңган, әдәбият-сәнгатькә гашыйк халкыннан кайнар сәлам сезгә, хөрмәтле дуслар! Арча – милләтебезгә Курсави, Култәси, Мәрҗани кебек бөек мәгърифәтчеләрне, йөзләгән әдипләрне, моң ияләрен, фронт һәм хезмәт батырларын, галимнәрне, җитәкчеләрне биргән данлы төбәк ул! Халкыбызның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә районыбыз көннән-көн матурая, төзекләнә бара. ТАССРның – 100, Бөек Җиңүнең – 75, районыбызның 90 еллык юбилейларын күркәм эшләр белән каршылыйбыз. Бөек Җиңүне якынайтуга гомерләрен дә кызганмаган, сугыш һәм сугыштан соңгы авыр елларда хезмәт батырлыклары күрсәткән якташларыбыз белән чиксез горурланабыз.

Арча ягы – музейлар ягы. Дөньядагы бердәнбер Әлифба музее, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның Яңа Кырлайдагы мемориаль музей комплексы, Кушлавычтагы Тукаевлар гаиләсенең музей йорты, «Казан арты» тарих-этнография музее, Әдәбият һәм сәнгать музее, Гөберчәктәге Мөхәммәт Мәһдиев музее... Болар барысы да данлы Татарстаныбызның тарихын барлау үзәкләре.

Олы юбилейлар елы мөбарәк булсын, Республикабыз тагын да яңа үрләр яуласын! Кунакчыл Арчабызга рәхим итегез!

